www.madanizhomga.ru

Мәдәни җомга

1995 елның июленнән башлап чыга

Татарстанда язылу индексы – П2355.

№ 38 (1403) 30 сентябрь 2022 ел

БЕЗ СОЦИАЛЬ ЧЕЛТӘРЛӘРДӘ:

madani_zhomga madanizhomga

madani_zhomga

12

Рәссам Илдар Сафин эшләрендәге эчке җылылык, детальләргә игътибар балачактагы, тарихтагы мизгелләргә карата рәхәт сагыш уята.


14

Милләтпәрвәр Фәһим Җиһаншинның кызыклы шөгыле төрле илләрнең, халыкларның омтылыш-теләкләрен гимн аша өйрәнергә юл ача.


16

Күңелдә калган зур үкенеч – олы шагыйрь, якын дустымның соңгы үтенечен үти алмадым...

Хан кызының фатихасы белән Кердек быел иҗат фасылына!

БЕР ҖӨМЛӘ БЕЛӘН...

- Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов Третьяков галереясы генераль директоры Зөлфирә Трегулова белән очрашып, галерея музейларында Татарстан экспозицияләрен күрсәтү турында фикер алышты.
- Ш.Биктимеров исемендәге Саба мәдәният йортында Татарстанның атказанган артисты Әлфия Хәсәнованың юбилей кичәсе узды.
- Мәскәүдә, колачлы төзекләндерү эшләреннән соң, тантаналы рәвештә Ислам институты ачылды.
- Татарстанның 24 рәссамы, пленэр оештырып, Чирмешән районы авыллары күренешләрен сурәткә төшерде.
- Казанның «Хәзинә» галереясында күренекле төрек рәссамы Ялчын Гөкчәбагның «Үткәннәр озакка сузыла» дип исемләнгән күргәзмәсе ачылды.
- Башкортстанның З.Вәлиди исемендәге Милли китапханәсендә каһарман очучының тууына 100 ел тулу уңаеннан оештырылган «Безнең герой – Муса Гәрәев» конкурсы җиңүчеләрен бүләкләделәр.
- Бүген Г.Кариев театры «Яралу» музыкаль-хореографик перформансы һәм «Йосыф» спектакле белән 35 нче театр сезонын ача.
- «Снег Медиа» проекты авторы Равил Мукменов Бөтенроссия конкурсында 2022 елгы иң яхшы журналистлык әсәрләре номинациясендә җиңүчеләр исемлегенә керде.
- Казан шәһәре Башкарма комитеты хезмәткәрләре өчен атнага ике тапкыр бушлай татар теле курслары уздырыла башлады.
- «Созвездие-Йолдызлык» арт-резиденциясе труппасы республика буйлап гастрольләр кысаларында Арча, Норлат, Әлмәттә чыгыш ясаячак.
- Татарстан Диния нәзарәтендә мөселман яшьләре өчен «MuslimQuiz» акыл уеннарының яңа сезоны ачылды.

ӘЙТКӘН СҮЗ – АТКАН УК

Хафиз МИРГАЛИМОВ, Дәүләт Советы депутаты:

«Совет чорында шырпыдан алып космик корабка кадәр үзебез ясый идек. 70 нче елларда Уренгой – Помары – Ужгород юнәлешенә газ торбаларын салдылар, мин әле университетта укый идем. Шунда безгә Германия торбалар бирмәде, ул торбаларны алар гына җитештерә иде. Безнең заводларыбыз шул вакытта тырышлык күрсәтеп, әлеге торбаларны үзләре чыгарды. Товарның барысын да үзебездә җитештерү кирәкмидер дә, «халыкара бүленеш» дигән төшенчә дә бар. Тик тарих кабатлана, андагы хаталарны онытырга ярамый».

СЫНАМЫШЛАР

1 октябрьдә кыр казлары китсә, Покрауда (14 октябрьдә) кар ятар ● 6 октябрьгә яфраклар саргайса, әмма коелмаса, көн тиз генә суытмый әле ● Октябрьдә шөпшә һәм төклетуралар күренсә, кыш суык булыр ● Чия яфрагы коелып бетмичә, кар ятмый.

КОЯШ СӘГАТЕ

Бүген кояш **5 сәгать 43 минутта** чыкты, һәм ул **17 сәгать 22 минутта** офык артына күмеләчәк. Көн озынлыгы – **11 сәгать 39 минут.** Алдагы җиде көн дәвамында тәүлекнең якты вакыты **32 минутка кыскарачак** һәм киләсе җомгада, ягъни **7 октябрьдә 11 сәгать 07 минут** тәшкил итәчәк.

БЕЛЕП ТОРЫГЫЗ

30 сентябрь – филология фәннәре докторы, профессор, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре Хәлил Хәлим улы Сәлимовның тууына 75 ел (1947–2006);

– опера һәм эстрада җырчысы, Татарстанның һәм Россиянең атказанган артисты Аида Эмиль кызы Гарифуллинага 35 яшь (1987).

1 октябрь – язучы Рафис Хәсән улы Сәлимҗановка 70 яшь (1952).

6 октябрь – театр тәнкыйтьчесе, сәнгать фәннәре докторы, профессор, Татарстан Фәннәр академиясенең мөхбир-әгъзасы, Татарстанның атказанган фән эшлеклесе Гали (Мөхәммәтгали) Гыйльмегали улы Арслановка 75 яшь (1947).

СӘЛАМӘТЛЕК КӨН ДӘ КИРӘК

Октябрьнең магнитлы авыр көннәрендә хезмәттәшләрегез, якыннарыгыз сәламәтлегенә һәм, әлбәттә, үз-үзегезгә аеруча игътибарлы булыгыз. **Бу атнада андый магнитлы көн юк.**

* * *

Гадәттә, айның беренче чирегеннән тулы айга кадәр **(3-9 октябрь)** организм киңәюгә бара. Мондый көннәрдә организмны, бигрәк тә бавырны чистартуга бәйле процедуралар үткәрү файдалы.

Шунысын да онытмагыз: **14 августтан 24 октябрьгә кадәр** үпкә һәм юан эчәклек актив булучан. Шушы вакыт аралыгында аларны ныгыту һәм дәвалау уңай нәтиҗәләргә китерә.

ҺИҖРИ БУЕНЧА 1444 ЕЛ

Бүген рабигүл әүвәл аеның 4 нче көне

КӨН КАДАГЫНА

ЯҢА ФЕДЕРАЛЬ СТАНДАРТЛАР:

татар теле сәгатьләре ике тапкыр кимергә мөмкин

Бу уку елыннан Россия мәктәпләре яңартылган федераль стандартлар (ФГОС) нигезендә белем ала башлады. Татарстан түрәләре «дәүләт теле буларак, балалар татар телен дә өйрәнә алачак» дип тәкрарласа да, чынлыкта яңа укыту программалары нигезендә туган тел дәресләре (шуның кысаларында укытылачак республика теле дә) ике тапкыр диярлек кими. Кайбер укыту вариантларында туган телне өйрәтү бөтенләй каралмаган. Татарстанда аерым мәктәпләр моны үзләрендә татый башлады инде. Кайбер белем йортлары узган елгы тәртиптә укытуын дәвам итә.

tetushi.tatarstan.ru/

Быелдан мәктәпләрдә 1 һәм 5 сыйныфлар яңа федераль стандартлар нигезендә белем алачак. 2023 елда ул 1-7 сыйныфлар, 2024 елда – 1-9 сыйныфлар өчен гамәлгә керергә тиеш. Шул ук вакытта Россия Мәгариф министрлыгы 1-9 сыйныфлар өчен яңа үрнәк укыту программалары төзеде. Аларда, узган елныкы белән чагыштырганда, туган тел һәм әдәбият дәресләре ике тапкыр кими. Шул сәбәпле Татарстан мәктәпләрендә туган телне ничек укыту мәсьәләсе килеп басты. Кемдер искечә, ә кемдер яңа программалар нигезендә белем бирә.

Яңа федераль стандартлар нигезендә туган тел сәгатьләре кимиячәге элегрәк тә әйтелеп килде. Әмма түрәләр дәресләр саны кимемәячәк дип күзгә төтен җибәреп яшәде.

– Уку планнарының аерым вариантларында «Туган тел» һәм «Туган әдәбият» фәне булмавы, дәресләр саны кыскару борчу тудырды. Мәктәпләрдә туган телне саклау максатыннан Президент Р.Миңнеханов, республика җитәкчелеге, депутатлар тарафыннан федераль үзәк, Россия Мәгариф министрлыгы белән эшлекле очрашулар узды. Нәтиҗәдә, яңартылган стандартларда уку планнарында дәресләр санын арттыру турында үзгәрешләр кертелде. Бу безнең өчен көтеп алынган мәгълүмат, – дип сөйләгән иде Татарстан мәгариф һәм фән министры урынбасары Минзәлия Закирова 16 августта узган җыелышта. Соңрак министрның икенче урынбасары Рәмис Мөҗипов та мәктәпләрдә туган телләр укыту дәресләре кимемәячәк дип белдерде.

Ә җәмәгатьчелектә күп сораулар туды. Яңартылган үрнәк укыту программалары үзгәртелгән икән, ни өчен алар һаман рәсми сайтка эленмәде? Мондый шөбһәдән соң татар җәмәгатьчелеге, мәктәпләрдә туган тел сәгатьләре кимүгә ризасызлык белдереп, Россия мәгариф министры Сергей Кравцовка дәресләр санын саклап калуны сорап мөрәҗәгать итте. Әлеге хатта туган тел укыту тамырдан үзгәртелү, Россия кануннарының бозылуы турында төгәл әйтелә. Мөрәҗәгатьне 21 иҗтимагый оешма җитәкчесе, шул исәптән Татарстан язучылар берлеге рәисе Ркаил Зәйдулла имзалаган.

Россия Мәгариф министрлыгының үрнәк укыту программаларының махсус сайтында яңартылган укыту программасы вариантлары белән танышырга мөмкин. Кайбер белем бирү вариантларында «Туган тел» сәгатьләренә бөтенләй урын табылмаган. Яңартылган программаларда биш көнлек укытуга күчә бару, «Туган тел» кысаларында дәүләт теле буларак татар телен укыту һәм иң мөһиме туган тел сәгатьләре саны кимүе күзәтелә.

Иске федераль стандартлар белән чагыштырганда, 1-4 нче сыйныфларда урыс телендә белем алучылар арасында «Туган тел» дәресләрен – 42 процентка, туган телдә белем алучыларда - 52 процентка азрак укыячаклар. Урыс мәктәпләренең 5-9 нчы сыйныфларында ул – 33 процентка, милли мәктәпләрдә – 48 процентка кадәр кимегән. Һәр вариантта да туган тел дәресләренә, чит телләргә караганда, азрак вакыт бирелгән.

1-4 сыйныфлар өчен барлыгы 5 укыту программасы варианты каралган. Беренче һәм икенче вариант биш көнлек укытуны күздә тота.

• Беренче вариант. Программада «Туган тел» дәресен укыту каралмаган. Ул урыс мәктәпләре өчен атнасына биш көн укуны күздә тота.

• Икенче вариант. «Туган тел» һәм «Туган әдәбият» яисә «Республика дәүләт телен» уку мөмкинлеге бар. 1-3 сыйныфлар атнасына 2 сәгать, 4 сыйныфлар – 1 сәгать сайлап укый ала. Атнасына биш көн укыту каралган.

• Өченче вариант. Программада «Туган тел» сәгатьләре бүленмәгән.

• Дүртенче вариант. «Туган тел» (яисә «Республика дәүләт теле») дәресен укучылар 1-3 сыйныфларда атнасына – 2 сәгать, 4 сыйныфта – 1 сәгать сайлап укый ала.

• Бишенче вариант. Рус булмаган телдә белем бирүче, безнең очракта, татар мәктәпләре өчен төзелгән вариант. Бу «Туган тел» (яисә «Республика дәүләт теле») дәресе иң күп укытыла торган программа. 1 нче сыйныфлар атнасына – 2 сәгать, 2-3 сыйныфлар – 3 сәгать, 4 сыйныфта 2 сәгать өйрәтү каралган. Шулай да милли мәктәпләр өчен әзерләнгән программада да төп игътибар рус теле һәм әдәбиятына юнәлгән – атнасына 7 сәгать укыту.

5-9 сыйныфлар өчен барлыгы 6 укыту программасы варианты төзелгән, шуларның өчесендә туган тел укыту каралмаган. Беренче һәм икенче вариант биш көнлек укытуны күздә тота.

• Беренче вариант. Урыс мәктәпләре өчен әзерләнгән программада «Туган тел» дәресенә аерым сәгатьләр бүленмәгән.

• Икенче вариант. «Туган тел» һәм «Туган әдәбият» яисә «Республика дәүләт телен» уку каралган. 5-8 сыйныфлар атнасына – 2 сәгать, 9 сыйныфлар – 1 сәгать укый ала.

• Өченче һәм дүртенче вариант. Әлеге укыту программаларында «Туган тел» укыту каралмаган.

• Бишенче вариант. Һәр сыйныфта атнасына 2 шәр сәгать «Туган тел» һәм «Туган әдәбият» яисә «Республика дәүләт телен» өйрәнә ала.

• Алтынчы вариант. Бу укыту программасы милли телләрдә белем бирүче мәктәпләр өчен юнәлгән. Аның кысаларында, «Туган тел» яисә «Республика дәүләт телен» укыту 5-6 сыйныфлар өчен 3 сәгать күләмендә, 7-9 сыйныфларда 2 сәгать укыту каралган.

(Дәвамы 5 нче биттә).

Җидеген
вакыйгалар
хәбәрләр
яңалыклар

Югары дәрәҗә атналыгы

БМО Генераль Ассамблеясенең (ГА) 77 нче сессиясендә 20-26 сентябрь көннәрендә «югары дәрәҗә атналыгы» үткәрелде. Ә аның алдыннан, бүгенге хәтәр хәлләр белән бәйле рәвештә, шактый гына ишарәле вакыйгалар да булып алды (алар рәтендә: күптән түгел Сәмәркандта үткән ШОС саммиты; Мәскәү эмиссарының махсус йомыш белән шыпырт кына Пекинга барып кайтуы; Россиядә Җинаять кодексына тиз арада «мобилизация», «военное время», «военное положение» кебек төшенчәләр һәм үзенчәлекле кайбер башка үзгәрешләр кертелүе; Россия Президентының ватандашларга мөрәҗәгать белән чыгуы һәм өлешчә мобилизация дә игълан итүе һ.б.). Дәүләт җитәкчеләре һәм башка рәсми затлар «югары дәрәҗә атналыгы»нда ясаган чыгышларында үз фикерләрен, әлбәттә инде, әлеге вакыйгаларны да күздә тотып һәм хәтта аларга бәя дә биреп ирештерде.

Чыгышларның кайберләренә аерым да тукталып үтик. БМО Генераль секретаре А.Гутерриш үзенең кереш сүзендә дөньяга зур куркыныч янавы турында әйткән. Аныңча, инсаниятнә конфликтлар һәм климат фаҗигаләре, ышанычсызлык һәм бүленешләр, фәкыйрьлек, тигезсезлек вә дискриминация, шулай ук азык-төлек һәм электр энергиясенә бәяләр артуы, эшсезлек вә керемнәр кимүе, колачлы миграция вә глобаль пандемия яный. Ул халыкара дипломатиянең глобаль кризиска керүе, ә дөнья җәмгатьчелегенең бүген Украинадагы сугыш, гадәттән тыш климатик вәзгыять яисә үсеп килүче илләрнең мөшкел финанс хәле кебек фаҗигале проблемаларны хәл итә алмавы турында сөйләгән һәм бөтен дөньяны бу юнәлешләрдә нәтиҗәлерәк эшли башларга, планетаны коткарырга өндәгән. Литва президенты Г.Науседа Украинага теләктәшлек күрсәткән һәм Россияне империячел мин-минлектә һәм дөньякүләм тәртипләрне бозуда гаепләгән. Төркия лидеры Р.Эрдоган исә низагларны тыныч сөйләшүләр юлы белән хәл итәргә, ә Украинада моны аның территориаль бөтенлеген һәм суверенлыгын да яклап хәл кылырга чакырган.

Иң кызыклы чыгыш, мөгаен, АКШ президенты Джо Байденныкы булгандыр. Россиянең өлешчә мобилизация игълан итүен ул БМО уставының төп принципларын бозу буларак бәяләгән. Аныңча, Россия президенты В.Путин Аурупага ачыктан-ачык атом-төш коралы белән янап һәм бу коралны таратмау режимы белән исәпләшмичә чыгыш ясаган. Байден үзе исә, атом-төш сугышында җиңеп булмый, шуңа ул бервакытта да башланырга тиеш түгел, дип белдергән. АКШ лидеры, Россиягә беркем дә һөҗүм итәргә җыенмый, ә Украинадагы конфликт гадел шартларда тәмамланырга тиеш, дип тә әйткән. Байден шулай ук БМО Куркынычсызлык Шурасын (КШ) реформалау, анда әгъзалар санын арттыру тәкъдиме белән чыккан. Ул көнне сессиядә, видеоязма аша, Украина президенты В.Зеленский да чыгыш ясаган. Анда ул Көнбатыштан Украинаны яңа (ераккарак ата торган) сугыш кораллары белән тәэмин итүен сораган һәм тынычлык урнаштыруның 5 шартын (агрессорны җавапка тарту; Украинага хәрби, финанс һәм разведка ярдәме күрсәтү; илнең территориаль бөтенлеген торгызу; аңа куркынычсызлык гарантияләре бирү; башка илләрнең дә Украинага карата ярдәмчел булуы) бәян иткән.

Әлбәттә, ГА сессиясендә РФ тышкы эшләр министры С.Лавров та чыгыш ясаган. Яңа дөньяви тәртип хакында ул Россиянең, шантаж һәм куркытуларсыз, неонацизм һәм неоколониализмсыз, гадел вә демократик юлны сайлавы турында әйткән, Көнбатышны исә халыкара институтларга ышанычны хокук вә гаделлек гарантиясе органнары буларак какшатуда гаепләгән. Лавров БМО КШ составын киңәйтүгә дә каршы чыккан. Ул бүгенге вәзгыятьтә Россиянең Көнбатыш белән диалогта адымны беренче булып ясамаячагы турында әйткән. Шул ук вакытта, әгәр партнерлардан, беркем дә белмәслек итеп, шыпырт кына очрашу турында тәкъдим булса, Россия каршы булмаячак, дип искәрткән. Ул АКШ һәм аның союздашларын тарих тәгәрмәчен туктатырга азаплануда, үзләрен исә Җирдә Хак Тәгалә илчесе итеп тоюда гаепләгән, моңа кадәр Көнбатышка хезмәт иткән бер полярлы үсеш моделенең үткәндә калуы турында да сөйләгән.

Фоат УРАЗАЙ.

Хезмәтенә күрә хөрмәте

Татар әдәбиятын үстерүгә зур өлеш кертүе һәм күпьеллык иҗади эшчәнлеге өчен шагыйрь, Татарстан Республикасының «Татарстан китап нәшрияты» дәүләт унитар предприятиесе матур әдәбият редакциясе мөдире, «Татарстан Республикасы Язучылар берлеге» иҗтимагый оешмасы әгъзасы **МОРАТОВ Газинур Васикъ улына (Газинур Моратка)** Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов указы белән «Татарстан Республикасының Халык шагыйре» дигән мактаулы исем бирелде.

Әдәби бәйге

Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Татар телен һәм Татарстан Республикасында яшәүче халыкларның туган телләрен саклау, үстерү мәсьәләләре комиссиясе ярдәме белән Язучылар берлеге 2022 елның 1 октябреннән татар телендәге әдәби әсәрләргә яңа бәйге игълан итә.

Бәйгедә катнашучыларның исеме билгеле булырга тиеш түгел. Әсәр псевдоним белән имзалана, автор турында мәгълүмат (фамилиясе, исеме, әтисенең исеме, туган елы, адресы һәм телефоны) ябык конвертларда җибәрелә.

Бәйгедә катнашу өчен әдәби әсәрләр «Казан утлары» журналы редакциясенә (420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2 йорт) кәгазь һәм электрон вариантта (флешкада) җибәрелә.

Романнар 2023 елның 1 декабренә, башка номинацияләрдәге әсәрләр 2023 елның 1 сентябренә кадәр кабул ителә.

Җиңүчеләргә бүләк фонды салымнарсыз 3 млн 895 мең сум тәшкил итә.

Театр яңалыклары

Камал театры Санкт-Петербургта узган «Александринский» Халыкара театр фестивалендә катнашты. Фестиваль программасы кысаларында баш режиссер Фәрит Бикчәнтәев белән иҗади очрашу булды. Анда режиссерның 60 яшьлек юбилеена чыккан китап һәм документаль фильм тәкъдим ителде.

Сентябрь аенда «Пушкин картасы» буенча Камал театры спектакльләренә билет сатып алучыларга икенче спектакльгә бер чакыру билеты бүләк ителде.

К.Тинчурин театры яшьләрне театрга җәлеп итү максатыннан яңа акция башлап җибәрде. «Пушкин картасы» белән билет алган мәктәп укучылары һәм студентлар авиабилет, телефон, смарт-сәгать һәм пылесос ота алачак. Моның өчен исем-фамилия, телефон номеры язылган билетны театр фойесындагы махсус тартмага салырга кирәк.

Түбән Кама театры бу атнада Казан тамашачысын сөендерде. «Московский», «Сәйдәш» мәдәни үзәкләрендә Туфан Миңнуллин әсәре буенча «Гөргөри кызын бирә» спектакле тәкъдим ителде. Башкаланың 23 нче лицеенда артистлар нәни тамашачыларга «Һау-һау-һау» спектаклен уйнады. 3 октябрьдә түбән камалылар театр каршында эшләп килгән «Бишегем» балалар театрына сайлап алу бәйгесе уздыра.

Минзәлә театры 7 октябрьдә Заһир Бигиев әсәре буенча сәхнәләштерелә торган «Өлүф, яки Гүзәл кыз Хәдичә» спектакленең премьерасы белән рәсми рәвештә яңа иҗат фасылын ачарга әзерләнә.

Троицкида – Рәсүлев укулары

Троицкида «Рәсүлев укулары: Россия тарихында һәм хәзерге тормышында ислам» Халыкара фәнни-гамәли конференциясе узды.

Конференция эше пленар утырыштан башланды. Кунакларга сәламләү сүзе белән Чиләбе өлкәсе губернаторы Алексей Текслер мөрәҗәгать итте. Чарада Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты җитәкчесе Данис Шакиров та катнашты. Ачылыш вакытында Татарстан Президенты Рөстәм Миңнехановның котлау сүзләре җиткерелде.

Конференция ачылышында Россия мөселманнарының Үзәк Диния нәзарәте рәисе, Россиянең югары мөфтие Тәлгать Таҗетдин һәм Урал федераль округы мөфтие Ринат хәзрәт Раев та чыгыш ясады.

Быел конференция конфессияара һәм милләтара диалогны ныгыту, дини экстремизмны кисәтү, хакимият органнарының, мәгариф учреждениеләренең, дини һәм милли-мәдәни берләшмәләрнең хезмәттәшлеген үстерү, Зәйнулла Рәсүлевнең рухи мирасына игътибар җәлеп итү, исламның тарихи-мәдәни мирасын саклау бурычларын куя.

Халык шагыйрен котладылар

Г.Камал театрында I-V чакырылыш Татарстан Дәүләт Советы депутаты, Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, Татарстанның халык шагыйре Разил Вәлиевкә 75 яшь тулуга багышланган бәйрәм кичәсе узды. Республика җитәкчелеге исеменнән юбилярны Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин котлады.

Фәрит Мөхәммәтшин котлавында Р. Вәлиевнең Татарстанның мәдәни үсешенә зур өлеш кертүен һәм республикада парламентаризмны ныгытудагы казанышларын билгеләп үтте: «Без бүген чын мәгънәсендә татар халкының күренекле вәкилен, кыю депутатны, талантлы язучыны хөрмәтлибез, – диде ул. – Әдәбиятчы-сәясәтчеләр арасында Разил Исмәгыйль улы үзенең тәвәккәллеге, үткен теле, тормышка, кешеләргә, үз республикасына булган мөнәсәбәте белән аерылып тора».

Парламент җитәкчесе сүзләренә караганда, Разил Вәлиев Дәүләт Советында ил һәм республика өчен бик катлаулы вакытта комитет рәисе сыйфатында эшли башлаган. «Советлар Союзы таркалганнан соң халыкларның милли үзаңы яңадан уяна башлады, – дип искә алды Ф.Мөхәммәтшин. – Кешеләр Ирек мәйданына республикага суверенитет таләбе белән чыкты. Бу авыр вакытта Разил Вәлиев, Туфан Миңнуллин, Роберт Миңнуллин кебек кешеләр республика җитәкчелеге өчен таяныч булды. Алар Россиядән чыгуны таләп итмәде, ә Татарстанның статусын күтәрү идеясен якладылар. Һәм, әлбәттә, халык депутатлары сыйфатында парламентта да, митингка чыккан кешеләр арасында Ирек мәйданында да барлык вакыйгаларның үзәгендә булды».

Фәрит Мөхәммәтшин юбилярның татар телен үстерү һәм пропагандалау буенча эшчәнлеге турында искә төшерде. «Мин үзем дә аның шигырьләре һәм чыгышлары белән туган телгә якынайдым», – диде парламент рәисе.

Бәйрәм кичәсендә Дәүләт Советы депутатлары, министрлыклар һәм ведомстволар, район-шәһәрләр, иҗади оешмалар җитәкчеләре һәм вәкилләре катнашты.

1 нче биттә – К.Тинчурин театрында Карло Гоццының «Турандот» әсәре нигезендә Кәрим Тинчуринның иреклe тәрҗемәсе буенча куелган «Хан кызы Турандык» спектакле премьерасыннан күренеш.

Ялчыгол укулары

Зәйдә тугызынчы тапкыр Тажетдин Ялчыгол укулары республика фәнни-гамәли конференциясе үтте. Танылган татар галиме, мәгърифәтче, табиб, язучы Тажетдин Ялчыгол истәлегенә багышланган конференция быел «Ялчыгол мирасы – халкыбыз хәзинәсе» исеме астында узды. Чараны төзекләндерелгән Куш-Елга авылындагы «Хәзрәт чишмәсе»н караудан башладылар.

Узган ел Татарстан Президенты аппараты җитәкчесе, тамырлары белән Куш-Елга авылыннан булган Әсгать Сәфәров чишмәне төзекләндерү идеясе белән чыга. Район башлыгы әлеге идеяне хуплап, төзекләндерү эшләре башланып китә.

Район башлыгы Разиф Кәримов авыл халкына, килгән кунакларга үзенең сәламләү сүзләрен җиткерде. «Хәзрәт чишмәсе» территориясен төзекләндерү эшләрен сыйфатлы, вакытында башкарган подрядчы оешма җитәкчесе Хәлим Мостафин һәм аның хезмәткәрләренә Рәхмәт хатлары тапшырды. Укуларда катнашучылар Куш-Елга авылы зиратында булды, Ялчыгол нәселеннән булган Баһаветдин улы Фәхретдин, Фәхретдин улы Фәйзулла рухларына дога кылдылар.

Аннан соң Имәнлебаш авылында Тажетдин Ялчыгол кабере зиярәт кылынды, мәчеттә җомга намазы укылды. Укуларда катнашучылар район мәдәният йорты оештырган күргәзмәләрне карады. Биредә шифалы үләннәр, татар халкының милли баш киемнәре, намазлыклар, сандыклар күргәзмәсе эшләде. Иң борынгы тарихлы, иң иске сандыкны Югары Баграж авылы мәдәният йорты директоры Гөлшат Хрипунова алып килгән. Аның тарихы XIX гасырга тоташа. Гөлшатның бабасының әтисе аны Чиләбедән алып кайткан. Менә күп еллар инде бу сандык буыннан-буынга тапшырылып килә. Гөлшат бишенче буын сандык хуҗасы. Сандык бүген авыл мәдәният йорты музееның иң кадерле ядкәре.

Китапханә хезмәткәрләре Тажетдин Ялчыголның тормышына һәм иҗатына багышланган экспозиция белән таныштырды. Утырышның пленар өлеше мәдәният йортында үтте. Аны район башлыгы Разиф Кәримов ачты, ул зәйлеләрнең Ялчыгол мирасын өйрәнү, саклау һәм популярлаштыру буенча зур эше хакында сөйләде.

Татар халкы тормышында Тажетдин Ялчыголның роле һәм аның фәнни хезмәтләрен популярлаштыру турында төп докладлар белән профессор, филология фәннәре докторы Хатыйп Миңнегулов, Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү институты директоры, тарих фәннәре докторы Искәндәр Гыйләҗев, археолог, Татарстан Фәннәр академиясе мөхбир әгъзасы Фаяз Хуҗин, Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институты өлкән фәнни хезмәткәре Айдар Гайнетдинов, язучы, Санкт-Петербург Фәннәр һәм сәнгать академиясе мөхбир әгъзасы Марсель Гарипов чыгыш ясады.

Көй-моңнар галимәсе

Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының сәнгать белеме бүлеге хезмәткәрләре күренекле музыка белгече Гүзәл Фәйзрахман кызы Юнысованы матур гомер бәйрәме белән тәбрик итте. Гүзәл ханым Казан дәүләт консерваториясен тәмамлаганнан соң, музыка училищесында – мөгаллим, «Татарстан» радиосында – музыкаль тапшырулар редакторы, «Leitmotiv» журналында – редактор урынбасары булып эшләде. Ун еллап Г.Ибраһимов институтында хезмәт итә. Кайда гына эшләсә дә, Г.Юнысова профессиональ музыкабызны, республиканың музыкаль мәдәниятен армый-талмый халыкка таныту һәм бүген дә бу эшне дәвам итә. Галимә иң авыр, әмма иң кызык өлкәдә – фольклорда, бигрәк тә балалар фольклорында, аеруча бишек җырлары буенча эзләнде. Йөздән артык мәкаләсе, радиотапшырулары сәнгать сөючеләрдә генә түгел, киң катлам газета-журнал укучыларында, радио тыңлаучыларда зур кызыксыну уятты, чөнки галимә фәнни табышларын, кызыклы гомумиләштерүләрен, гади тел белән, боргаламыйча-сыргаламыйча, махсус әзерлеге булмаган һәркемгә кызыклы итеп җиткерә белә.

Шул ук вакытта Г.Юнысованың хезмәтләре зур фәнни кыйммәткә ия, галимә берәүне дә кабатламыйча, фәндә үз юлын сала. Мәсәлән, шундый бәһасез хезмәтләренең берсе – Г.Ибраһимов институты фондлары нигезендә әзерләнгән «Саратов татарлары фольклоры» китабы. Әлеге хезмәте өчен автор 2018 елда «Гуманитар фәннәр» номинациясендә иң яхшы фәнни китап Бөтенроссия бәйгесендә лауреат булган.

Музыка белгечен котларга аның шәкертләре – Казан дәүләт консерваториясенең татар музыкасы кафедрасы деканы Лилия Сәрвәрова, консерватория һәм Казан федераль университет мөгаллиме Лилия Сафиуллина һ.б. килгән иде. Саратов татарлары фольклоры турында китап очрашу буе телләреннән төшмәде. Әлеге китап музыка белгечләре өчен генә түгел, тел, әдәбият галимнәре, тарихчылар, туган якны өйрәнүчеләр, архив серләрен төшенүчеләргә бердәй кыйммәтле, андый киң мәгълүматны үзендә туплаган фольклор буенча китаплар сирәк чыга.

Г.Юнысова әзерләгән «Татар музыкаль мәдәнияте хрестоматиясе» һәм «Татар халык музыкаль иҗаты» программасын музыка һәм сәнгать училищеларында, балалар музыка мәктәпләрендә кулланалар. Казан музыка көллиятенең 100 еллыгы уңаеннан әлеге уку йортының тарихын үз эченә алган музей оештыруы да саллы хезмәтләр рәтендә. Р.Вәлитов белән бергә эшләнгән «Татар музыкаль фольклоры» мультимедиа дискы фәнни җәмәгатьчелектә зур кызыксыну уятты, Мәскәүдә халыкара конференциядә тәкъдим ителде.

Музыка белгечен котларга Милли китапханә, республикабызның опера сөючеләр клубыннан да вәкилләр килгән иде. 2000 елдан башлап милли китапханәнең видеосалонында төрле юбилейлар уңаеннан музыкаль очрашулар үткәрелә. Милли китапханә җитәкчелеге Гүзәл ханымга бу кичәләрне оештыруда актив катнашканы, башкалабыз халкын китапханәгә җәлеп иткәне өчен рәхмәтле. Видеосалонны аеруча опера сөючеләр клубы үз итә, чөнки байтак очрашулар М.Җәлил исемендәге опера һәм балет театры премьералары алдыннан үткәрелә. Г.Юнысова спектакльләрнең тарихы белән таныштырып кына калмый, төрле илләрдә ничек куелганы, анда кемнәр җырлаганы турында бай мәгълүмат бирә. Шәһәребезнең бүтән җәмәгать оешмаларына да, әйтик, С.Сәйдәшев, Н.Җиһанов, М.Горький һәм Ф.Шаляпин музейларына да музыка белгече һәм лектор Г.Юнысованы тыңларга яратып йөриләр.

Институтта туган көн җырлар, төрле уен коралларында башкарылган музыкаль әсәрләр белән үрелеп барды. Галимәнең хезмәтләреннән күргәзмә оештырылган иде.

Миләүшә ГАЛИУЛЛИНА.

Тәҗрибә уртаклашу

Сочида узган «Бөтен Россия – 2022» медиафорумында оештырылган түгәрәк өстәлдә «Татмедиа» акционерлык җәмгыяте генераль директоры Шамил Садыйков медиахолдингтагы социаль юнәлештәге видеопроектлар белән таныштырды.

«Видеопроектлар мәгълүматны актуальләштерә», – диде Шамил Садыйков, түгәрәк өстәлдә катнашучыларын видеоформатта эшләргә өндәп.

«Төбәк массакүләм мәгълүмат чаралары өчен яңа юнәлешләр» дип аталган түгәрәк өстәлне Россия Цифрлы үсеш, элемтә һәм массакүләм мәгълүмат чаралары коммуникацияләре министрлыгының басма матбугат һәм китап индустриясенә дәүләт ярдәме департаменты директоры Светлана Дзюбинская алып барды.

Шамил Садыйков «Татмедиа» медиахолдингы белән таныштырды, дәүләт тарафыннан булышлык өчен департамент директорына рәхмәтен әйтте: «Без былтыр 200 дән артык грант бирдек. Аларның йөзе яклау тапты», – диде. Шамил Садыйков уңышлы проект мисалы – журналист Равил Мукменовның «Снег Медиа» проекты белән таныштырды. Бу – Идел буе федераль округы мәгълүмат чаралары арасында видео форматындагы бердәнбер сторителлинг. Р.Мукменовның даун синдромлы баланы тәрбияләгән ана, «фил чире» дип аталган сирәк авыру белән авырган кеше турында видеороликлары укучыларда зур популярлык казанды.

«Кешеләр бу видеоларны караганда елыйбыз дип әйтә. Әмма мин моны кешеләрне елату максатыннан эшләмим. Минем максат – кешеләргә арабызда шушындый көчле рухлы каһарманнар бар икәнен күрсәтү», – диде Равил Мукменов.

Шамил Садыйков район газеталарындагы кайбер социаль проектлар белән таныштырды. Мәсәлән, «Мин – дөньяның бер өлеше», «Яхшылык марафоны», «Яучы» кебек уңышлы проектлар бар.

Россия Журналистлар берлеге секретаре Роман Серебряный, проектларның кызык булуын әйтеп, башка төбәкләрдәге журналистларны бу тәҗрибәдән файдаланырга өндәде.

Рәмис ЛАТЫЙПОВ.

● Хәзер Җирдә барлыгы 7,95 миллиард кеше яши. 2020 елда планета халкының 59,5 % Азиядә, 17,2 % Африкада, 9,6 % Европада, 8,4 % Латин Америкасында, 4,7 % - Төньяк Америкада, 0,5 % Океаниядә яшәгән. БМО мәгълүматлары буенча, 2050 елда җиһан халкының 55,8 % Азиядә, 26,3% Африкада, 8,0 % Латин Америкасында, 7,5 % Европада, 4,5% Төньяк Америкада, 0,6 % Океаниядә яшәячәк, дип фаразлана.

● Дөньяда һәр сәгать саен 17 мең (көн саен 427000) бәби туа, 6 мең (тәүлегенә 167000) кеше үлә, димәк, планета халкы көн саен якынча 260000 кешегә ишәя.

● 9 ай эчендә кеше яралгысының авырлыгы якынча 2 миллиард 400 миллион тапкырга арта.

ЯҢА ФЕДЕРАЛЬ СТАНДАРТЛАР:

татар теле сәгатьләре ике тапкыр кимергә мөмкин

(Ахыры. Башы 2 нче биттә).

Мәгариф белгече аңлатмасы: «Мәгариф» берләшмәсе президенты Марат Лотфуллин туган телләрнең кимүен санитар кагыйдәләр (СанПин) үзгәрү һәм федераль үзәкнең туган телләрне укытмас өчен максатчан эш алып баруы белән бәйле дип аңлатты.

– Россия Мәгариф министрлыгы төзегән укыту программаларында туган тел укытылмый торган вариантлар Россия кануннарына каршы килә. Без бу хакта Россия Мәгариф министрлыгына яздык. Алар бу программаларны төзәтмәсә, прокуратурага мөрәҗәгать итәчәкбез. Анда Россия Мәгариф министрлыгының ничек туган телләрне сайламаска дигән киңәшләре дә бар.

Үрнәк укыту программаларында СанПинның рөхсәт ителгән сәгатьләр саны бирелә. Дәресләр санын кыскарттылар, шуңа туган тел бер-ике сәгатькә калды. Әгәр дә ата-аналар биш көнлек укыту программасын сайласа, анда туган тел укыту булган программаны кулланып булмый. Туган телләр азрак укытылсын дип максатчан эшләнгән эш, – ди ул.

Татарстанда мәктәпләрнең нинди укыту программалары нигезендә белем бирәчәге октябрь башында гына билгеле булачак, ди ул. Шул вакытта хисап тапшырылачак. Аның сүзләренчә, мәктәпләр Россия министрлыгы тәкъдим иткән үрнәкләрне үзләре мөстәкыйль рәвештә сайлый. Моңа җыелыш ясап торырга кирәкми.

– Россия кануннары нигезендә Татарстан Мәгариф министрлыгы, мәгариф идарәләренең мәктәпнең укыту программаларына берниндн катнашы юк. Алар гомумән мәгариф системасыннан читләштерелгән. Мәктәпләр белән хәзер турыдан-туры Россия Мәгариф министрлыгы һәм прокуратура идарә итә, – ди Лотфуллин.

Белем бирү программасы ике өлештән тора: мәҗбүри өлеш һәм мәктәп белән ата-аналар катнашында төзелгән өлеш. Бу очракта татар телен өстәмә рәвештә дә укытып буламы?

– Бу өлешендә фәннәрне ата-аналар һәм мәктәп үзе сайлый. «Туган тел» укыту программасының мәҗбүри өлешенә керә. Икенче өлештә дә туган телне укытып була, әмма мәҗбүри өлешен өйрәтергә дә вакыт юк бит, сәгатьләр җитми. Хәзер иң зур куркыныч – ата-аналар биш көнлек укыту программасын кертергә тырыша. Моны гамәлгә ашырганда туган телгә бөтенләй урын калмый, чөнки сәгать җитмәячәк. СанПинның рөхсәт иткән сәгатьләр саннары бар, – дип сөйләде мәгариф белгече.

tatar-congress.org/

Федераль стандартларның төп яңалыгы – татар телен дәүләт теле буларак укытырга мөмкинлек бирүе. Шулай да укыту планнарында ул мөстәкыйль фән буларак каралмый, ә бары «Туган тел» кысаларында өйрәтелүче дәрес буларак күрсәтелә. Ата-аналарга ике юлның берсен сайларга туры киләчәк: йә туган тел буларак үзе теләгән телне, йә аның урынына дәүләт теле буларак татар телен.

Әлеге мәсьәләгә Татарстан Мәгариф министрлыгы ачыклык кертергә тырышкан иде. Түрәләр татар телен өч программа нигезендә оештырылачак диде.

• Туган (татар) тел – татар телендә белем бирүче мәктәпләр өчен;

• Туган (татар) тел – рус телендә белем бирүче мәктәпләр өчен;

• Татарстанның дәүләт теле буларак татар теле – рус телендә белем бирүче мәктәпләр өчен.

Марат Лотфуллин моны урыслар өчен татар телен укырга бер мөмкинлек бирү дип кенә атый.

– Дәүләт телен дә мәктәп һәм ата-аналар сайлавы белән генә өйрәнеп була. Аерым методика буламы? Бу аерым фән түгел. Шул ук татар теле, чөнки дәүләт теле ул телнең статусы гына. Аңа карап тел дә, грамматика да, сүзләре дә үзгәрми. Кайбер сыйныфларда туган тел буларак, кайберләрендә дәүләт теле итеп укытырга була. Монда аның аермасы юк. Шулай да дәүләт статусында булган татар телен урысларга укырга җиңелрәк булачак, – ди ул.

Яңа үзгәрешләр кайбер мәктәпләргә үтеп керә башлады, шул ук вакытта элеккечә укытучы белем йортлары күбрәк булып кала. Әлегә мәктәп сайтларында яңа укыту программалары күрсәтелмәгәнлектән, Татарстанда туган телләрнең ни рәвешле укытылуын төгәл әйтеп булмый. Шулай да искәрмә рәвешендә Казанның 19 нчы гимназиясе сайтында бу уку елы өчен расланган программа чыгарган. Анда 1-11 сыйныфларга атнасына 2 сәгать туган тел һәм әдәбият укыту каралган. Бу нигездә яңа федераль стандартлар нигезендә эшләнгән программага туры килә.

Татар ата-аналары хәрәкәте координаторы Илсөя Әхмәтгалиева мәктәпләрдә татар теле дәресләре якынча бер сәгатькә кимүе турында хәбәр килеп ирешүен сөйләде.

– Уку планнарында туган телләр якынча бер сәгатькә кыскарды. Өч сәгать укытылган булса, ике сәгатькә кыскарды. Әмма программаның беренче һәм өченче вариантында туган тел дәресе бөтенләй юк. Аның бөтен куркынычы шул. Бәлки, кайбер мәктәпләр туган тел булмаган вариантка күчкәндер. Тагын бер хәбәр бар, имеш, Татарстан беренче һәм өченче укыту программалары нигезендә укытмый.

Без берничә ата-ана һәм мәктәп мөдирләре белән сөйләштек. Анонимлыкны саклау шарты белән, аларның фикерләрен җиткерәбез.

Казанның данлыклы 2 нче татар гимназиясендә татар теле дәресе 5 сәгать урынына 3 сәгатькә калган. Әлеге мәгълүматны берьюлы ике ата-ана раслады. Татар теле рус теле хисабына киметелгән дип аңлатканнар мәктәптә.

Казанның Яңа Савин районында рус-татар мәктәбе мөдире сөйләвенчә, укыту әлегә былтыргы программа нигезендә алып барыла. Балалар атнасына уртача 3 сәгать туган тел һәм әдәбият укый. Ә менә дәүләт теле буларак татар теле дәресе әлегә кертелмәгән.

Казанның 149 нчы татар лицеенда ата-аналар сәгатьләр кимемәвен әйтә, ләкин зарлары җитәрлек.

– Әлегә вакытлыча элекке программа нигезендә атнасына 4 сәгать татар теле һәм 2 сәгать әдәбият укыячаклар дип әйттеләр. Шулай да без башка фәннәрнең дә татарча укытуын теләр идек. Мәктәп мөдире белән дә сөйләштек, ләкин аның теләге булмады. Татар теле көннән-көн бетеп бара. Укытучылар да, балалар да русча сөйләшә. Җыелышларны гына татар телендә алып барырга тырышалар.

«Солнце» мәктәбе мөдире Павел Шмаков узган елдагыча укытабыз, дип раслый.

– Хәзер бер укытучыбыз китте, яңасын эзлибез. Бездә татар теле дәүләт теле буларак һәр укучыга укытыла, – диде ул.

Районнарда да үзгәрешләр керә башлаган. Байлар Сабасында бер ата-ана татар теле дәресләре бер сәгатькә кимүен раслады. Мәсәлән, 7 нче сыйныфлар быел 4 сәгать урынына 3 дәрес кенә үзләштерәчәк. Мәктәптәге бер укытучы сүзләренчә, кайбер сыйныфларда татар телен өстәмә дәрес буларак, ләкин мәҗбүри төстә кертәләр. Әйтик, 10 нчы сыйныфлар өчен татар теле һәм әдәбиятын атнасына дүрт сәгать укыталар, дип сөйләде ул.

Атнаның сәяси мизгелләре

ХОКУК НОРМАЛАРЫН ХӘКАРӘТЛӘҮ

Атнаның төп сәяси вакыйгалары, әлбәттә, Украинаның 4 төбәген Россиягә кушу буенча үткәрелгән «референдум»нар белән бәйле булды. Дөрес, бу хакта сүзләр Мәскәү тарафыннан элегрәк тә ишетелгәләде: әүвәл аларны, «бердәм тавыш бирү көне»нә туры китереп, 11 сентябрьдә үткәрергә теләсәләр, Украина һөҗүмгә күчкәч, 4 ноябрьгә күчерү турында да тәкъдимнәр булган иде. Тик төбәк хакимиятләре, кинәт кенә (әйтерсең лә әмер буенча), «референдум»нарның барысын да 23-27 сентябрь көннәрендә үткәрергә карар кылды һәм, демократик нормалар буенча айларга сузылырга тиешле эшне (чөнки закон базасы булдыру, әзерлек чоры һәм демократик процедураны оештыру өчен вакыт таләп ителә) бер атна дигәндә башкарып та чыкты. Әлбәттә, ошбу гамәл нәтиҗәләрен, аны башкаручы һәм заказ бирүчеләреннән тыш, юридик яктан әлегә беркем дә (хәтта Сербия һәм Төркия кебек илләр дә) танымады.

Башка сәяси вакыйгалардан игътибарны Россия президентының ватандашларга мөрәҗәгать белән чыгуы һәм 21 сентябрьдән илдә өлешчә мобилизация игълан ителүе җәлеп итә. Соңгысы кайбер кала вә салаларда протест акцияләре башлануына, ә хәрби чакыру яшендәгеләрнең чит илләргә күпләп качып китә башлавына да китерде. Россия президентының атом-төш коралы турында әйткән сүзләре дә җавапсыз калмады. НАТО башлыгы Й.Столтенберг аны хәтәр риторика дип бәяләде һәм, атом-төш сугышында җиңүчеләр була алмый, ә Россия өчен аның нәтиҗәләре моңарчы күрелмәгәнчә булачак, дип искәртте. Ак Йортта да, Россиянең атом-төш коралы куллануы аның өчен авыр нәтиҗәләргә һәм дөнья аренасында «изгой»га әверелүенә китерәчәге хакында кисәттеләр. Охшаш кисәтүләр Көнбатышның башка лидерларыннан да ишетелде. Ә бу атна башында янә бер шомлы хәбәр – «Төньяк агымы» һәм «Төньяк агымы-2» газ үткәргечләренең Дания өлешендә бер үк көндә (26 сентябрьдә) өч торбага да зыян салынуы һәм аларда газ басымы түбәнәюе мәгълүм булды. Дания хөкүмәте аны махсус салынган зыян дип саный. Мәскәүдә исә моның диверсия нәтиҗәсе булу мөмкинлеген дә әйтәләр.

Фоат УРАЗАЙ.

«Ибн Фадлан» уңышы

Татарстанда төшерелгән «Ибн Фадлан» фильмы Казан мөселман киносы фестиваленең ачышы дип танылды. Аның авторларына «Вакыйганың тарихи әһәмиятен гәүдәләндергән өчен» номинацияле бүләк тапшырылды.

«Ибн Фадлан» фильмы өстәмә өч залда күрсәтелде. Социаль челтәрләрдә киноны карау өчен зур чиратлар җыелуын күрергә була иде.

Документаль-нәфис фильм Ибн Фадланның сәяхәтнамәсе нигезендә төшерелгән. Анда Багдад хәлифәте илчесенең Идел буе Болгар дәүләтенә сәфәр кылуы, 922 елда Болгарда ислам дине кабул ителү тасвирлана. Кинода нәфис фильм күренешләре белән документаль өлешләр үрелеп бирелгән. X гасырдагы вакыйгалар турында Татарстанның беренче президенты Минтимер Шәймиев, Россия Дәүләт Эрмитажы мөдире Михаил Пиотровский, Тарих институты мөдире Радик Салихов, тарихчы Фаяз Хуҗин сөйли.

Фильмны «Хозур» нәшрият йорты төшергән. Режиссерлары – Айназ Мөхәммәтҗанов һәм Рәмис Нәҗмиев.

Фильмга карата тамашачылар тарафыннан туган сорауларга режиссер Айназ МӨХӘММӘТҖАНОВ җавап бирде.

– «Ибн Фадлан» фильмына мондый кызыксынуны нәрсә белән аңлатасыз?

– Мондый ажиотаж сәбәбе – халкыбызда тарихи һәм дини фильмнарга зур ихтыяҗ булуында. Кызганыч, бездә тарихи фильмнар бик аз. Тарихка тирән кереп күрсәткән кинолар гомумән булмады. Элегрәк «Исә Болгар җилләре» фильмы төшерелгән иде, ул тамашачыга барып җитмәде. Шул вакыттан бирле кино төшерүнең технологиясе шактый үзгәрде. Бүгенге кинематография теле белән төшерелгән тарихи фильмнар юк. Кызыксынуның тагын бер сәбәбе – Идел Болгарының ислам динен кабул итүенең 1100 еллыгын билгеләп үтүебездә. Һәр яктан бу тема яңгырап тора. Шуңа күрә бу вакыйгага багышлап төшерелгән фильмга игътибар булу табигый хәл.

– Татар театрларында тарихи катлаулы темаларга ихтыяҗ зур түгел диләр.

– Мин театрал түгел. Аның кануннарын, мантыйгын тасвирлый алмыйм. Бәлки театр һәм кино тамашачысы аерыладыр.

– Кинофестивальгә нигездә татар кешеләре йөри. Әмма фильм рус телендә генә эшләнде. Ни өчен татарча булмады?

– Фестивальгә татар кешесе генә түгел, башка милләт вәкилләре дә йөри, татарча белмәгән татар кешеләре дә бик күп. Шулай да фильмның рус телендә эшләнүенең төп сәбәбе – «Россия – ислам дөньясы» стратегик төркеме һәм Мәскәүдәге ислам мәдәниятенә ярдәм итү фонды кушуы белән төшерелүендә. Безгә фильмны рус телендә эшләргә кушылды. Әгәр аны Татарстан төшерсә, ул татар телендә эшләү таләбе куяр иде. Минемчә, фильм татар теленә тәрҗемә ителсә, тарихчыларны да татарча сөйләтсәк, бу бик уңай күренеш булачак. Бүген татар телендә мондый контент җитми.

Әлеге фильмның аудиториясе татарлар һәм Татарстан белән генә чикләнми. Гомумән, без аны Россиядәге мөселманнар өчен төшердек. Мәскәү, Башкортстан, Төньяк Кавказ республикалары да бу фильмны күрер. Гарәп илләре дә фильм белән кызыксынмый калмас. Алар Ибн Фадланны белә, аның турында интернетта лекцияләр шактый. Бәлки, фильм киләчәктә гарәп һәм инглиз теленә дә тәрҗемә ителер. Һәрхәлдә, субтитрлар ярдәмендә булса да эшләргә мөмкин.

– Фильмның форматы – документаль-нәфис фильм. Ни өчен мондый форматка тукталдыгыз? Нәфис фильм буларак кына төшереп була идеме?

– Дөньяда мондый формат фәнни-популяр фильмнарга хас. Ләкин Татарстанда бу рәвешле төшерелгән кинолар аз. Безнең фильм үзенең тарихка тирән керүе белән уникаль. Нәфис фильм гына төшереп була идеме? Була иде. Әмма чикләүләр күп булды: аеруча финанс һәм кинематографистларның тәҗрибәсе җитмәде. Фильмны эшләп чыгару өчен бер ел бар иде. Бу вакыт эчендә сценарий язу, әзерлек эшләре, кием тегү, локация табу, кастинг үткәрү, репетицияләр уздыру, фильмны төшерү, аннан соң постпродакшн, компьютер графикасын ясап өлгерергә кирәк иде. Тулы метражлы тарихи фильмны бер ел эчендә генә эшләп булмый. Шуңа күрә аңа документаль өлешен өстәдек. Аның үз кыенлыклары булса да, җитештерү ягыннан ул җиңелрәк. Ә без фильмны 20 майга өлгертергә тиеш идек.

– Фильм концепциясенә басым, нәтиҗәдә тарихтан тайпылу булмадымы? Мәскәүдә төшерелгән тарихи фильмнарда татарлар кыргый итеп, милли тарих пычратып күрсәтелә бит.

– Гомумән, тарихтан тайпылу юк. Фильмны төшерттерүчеләрдән аерым басым, директивалар да булмады. Без экспертлар белән киңәшләшеп эш иттек. Сәхнәләштерелгән нәфис өлешендә ниндидер уйлап табылган эпизодлар керттек. Аларның берсе дә Ибн Фадлан рисаләсенә каршы килми, ягъни без уйлап тапкан детальләр, яңа персонажлар Ибн Фадлан язмасына хилафлык китерми.

– Тарихчылар моны ничек бәяләде? Фильм ни кадәр фәнни чынбарлыкка туры килә?

– Тарихчылар югары бәяләде, нәфис фильм өлешенә дә үз фикерләрен әйтте. Илтабар Алмыш белән Ибн Фадлан образларын бик ошатты, үзләре дә аларны шул рәвешле күзаллаган. Бу бик киң тема. Ибн Фадланның үз сәяхәте, аның Болгар җирендә күргән вакыйгалары, чынбарлык бер фильмга гына сыеп бетә алмый. Без игътибарны күбрәк Болгар дәүләтенең рәсми рәвештә Болгар хәлифәтенә һәм ислам цивилизациясенә керүенә юнәлттек. Әмма фәнни яктан да, иҗади яктан да әле тагын күп эшләр башкарып булыр иде.

– Башкортстан мөфтие Айнур Биргалин фильм Башкортстанда да төшерелергә тиеш дигән иде. Ул Ибн Фадлан сәяхәтнамәсендә башкорт факторына игътибар итә. Фильмда башкортлар да бармы?

– Без бу хакта ишеттек, әмма эшебез башланган иде инде. Без үз концепциябезне дәвам иттек. Фильмга башкортлар, угызлар һәм Ибн Фадланның тагын кайбер сәяхәт өлеше кермәде. Әлбәттә, алар керсә, тагын да кызыграк, тулырак булыр иде. Без, беренче чиратта, болгарлар тормышына игътибар бирергә тырыштык. Әгәр дә сәяхәтне тулысынча күрсәтсәк, бер ел гына вакыт җитмәс иде. Монда бит киемнәр, локацияләр булдырырга кирәк.

– Белгечләрне кайдан чакырдыгыз? Татарстан кинематографиясенең зур проектка алынырдай көче бармы?

– Татарстанда белгечләр юк дип әйтә алмыйм, әмма зур проектларга алынырга тәҗрибә җитми. Булган белгечләр дә аз. Һәрберсенең көчле яклары бар. Без читтән белгечләрне чакырмадык диярлек. Kazan Expo павильонында компьютер графикасы белән төшергәндә, хәлифәнең хатын уку күренеше өчен Мәскәүдән ут куючылар килде. Ут кую бригадиры нижгар татары иде. Башка белгечләргә килгәндә, булганнары белән эшләдек. Алар зур тәҗрибә алды. Ә читтән чакыруга килсәк, Мәскәү белгечләренең ихтыяҗларын, сораган гонорарларын безнең фильм бюджеты тәэмин итә алмый.

Минемчә, Татарстан кинематографиясе зур фильмнар төшерергә әзер, ләкин моңа дәүләт тарафыннан да игътибар булырга тиеш. Мондый проектлар шәхси оешмалар белән генә эшләнми. Дәүләт ягыннан аңлау, ярдәм кирәк. Бу үзебезне дөньяга таныту өчен зур һәм көчле ресурс була алыр иде. Татарстанда җитмәгән белгечләрне Мәскәүдән генә түгел, Үзбәкстаннан да җәлеп иттек. Без фильмның бер өлешен анда төшердек. Эш гонорарлар мәсьәләсендә генә түгел, үзбәк белгечләренең менталитеты безгә якынрак булуда. Алар динне, тарихны аңлый. Киләчәктә мондый проектлар булса, мин Үзбәкстан һәм Казахстан белгечләре белән эшләр идем. Аларның тарихи фильмнарны төшерүдә тәҗрибәсе дә бар.

Әгәр дә Татарстан кинематографиясе кластер буларак оештырылса, ул республикага финанс яктан да файда китерерлек бер өлкә була ала. Кинематография – ул бизнес, индустрия. Дәүләт аңа шулай караса, икътисадка да файдалы булачак.

– Алга таба бу фильм прокатка чыгачакмы? Россия шәһәрләрендә, Татарстан районнарында күрсәтү нияте бармы?

– Бу фильмның хокуклары «Хозур» нәшриятында. Хәзер прокатка чыгару, яисә интернет һәм телевидение аша халыкка җиткерү турында фикер алышу бара. Прокатчылар тарафыннан кызыксыну артты. Билет сатып фильмны күрсәтеп булыр микән, дигән сорау күтәрелде. Россиянең башка шәһәрләреннән дә мөрәҗәгатьләр килә.

– Фильмның дәвамын сез ничек күрәсез?

– Безгә тамашачылар килеп, бу фильмның дәвамын күрергә телибез дип белдерде. Без, бигрәк тә сценаристлар, бу турыда уйлый башладык. Буламы, юкмы – бездән генә тормый. Бүген ике юлны күрәбез. Беренчесе – Spin-off, ягъни аерым бер персонажның кыйссасын сөйләү. Бу вакытта Ибн Фадлан, Алмыш хан фон булып кына калачак. Ул тулы метражлы нәфис фильм да була ала. Икенче юл – мини-сериал төшерү. Бу проектта төшерелгән сәхнәләр тулысынча сериалга кереп китә, документаль өлешләре урынына уен сәхнәләре пәйда булачак.

– Бүген Россиядә Алтын Урда һаман дошман дәүләт буларак тасвирлана. Бу темага алынырга теләгегез бармы?

– Алтын Урда темасы бик кызык. Бүген Россиядә бу тарихка багышланган фильмнар татар тамашачысын да, Алтын Урдадан чыккан башка халыкларны да канәгатьләндерми. Алтын Урданың чынбарлыгын төшергән фильм яисә мини-сериал эшләнсә яхшы булыр иде. Аны турыдан-туры Алтын Урда турында түгел, шул чорның чынбарлыгын күрсәтеп төшерергә була. Ниндидер шәхси драма турында сөйләргә, экшен да өстәргә мөмкин. Алтын Урда чорындагы кыйссаларны төшерү өчен минем дә уйлап куйган сюжетларым бар. Мәсәлән, Казан һәм Кырым ханлыклары арасындагы бер сәяхәт турында сценарий яза башлаган идем. Әмма «Ибн Фадлан» башлангач, ул эш туктап калды.

– Украинадагы вакыйгалардан соң Россиядән көнбатыш кинолары китеп барды. Моның белән беррәттән фильм төшерү технологияләрен кулланучыга, фикер алмашуга юллар ябыла. Бу татар киносына нинди кыенлыклар тудыра?

– Татар киносының кыенлыклары дөньядагы процесслардан шактый ерак. Монда күбрәк эчке проблемаларны хәл итәргә кирәк. Киң дөньяга чыгу, көнбатыш кинолары белән бәйле мәсьәләләр әлегә безгә турыдан-туры кагылмый. Бәлки кинотеатрларда кытлык булу безнең фильмнарны киңрәк күрсәтүгә китерер. Әмма прокат мәсьәләсе – ул башка тармак.

Татар киносының киләчәге көнбатыш белән түгел, ә көнчыгыш – Урта Азия, Иран белән булырга тиеш. Алар белән хезмәттәшлек итәргә кирәк. Татарстанда мөмкинлек булса, ниндидер яңалыклар булдырырга мөмкин. Кытайның да шактый алга киткән технологияләре бар. Әмма шуны аңларга кирәк, Голливудтан да, Болливудтан да, Кытайдан да безнең эшне беркем килеп эшләмәячәк. Үзебез генә эшләсәк, фильмнар төшереп була.

Сирень ЯКУПОВА

Берәм-берәм таралыштык, Сагынып кайтыр өчен...

* * *

Китәргә җыенган кошлар
Туган илләрдән,
Канат сыный кабат-кабат,
Салып җилләргә.

Китмәүчеләр дә кушыла,
Кирәк ул сынау.
Илдә булсын, читтә булсын,
Иң мөһиме –
Канатың сынмау!

СӨЙЛӘШҮ

Син кайларда, кызым? Ни эшлисең?
Шәһәр буйлыйм.
Шундый рәхәт бүген урамда!

Хәзер, хәзер
Тәрәзәгә киләм...
Йа Алла!
Күз ачкысыз буран ласа тышта!
Юл-сукмакны ничек табасың?

Синме соң ул бу сорауны биргән?..
Күпме еллар «тукып» киләсең ич:
Үз сукмагың үзең саласы!
Ярый, ярый... Җилгә каршы атлап
(Ә мин белөм шулай икәнен),
Йөз-кулыңны өшетә күрмә, зинһар,
Чамалар чак (!)
Яман, әй лә, заман-җилнең каян искәнен…
Муеныңда җылы шәльяулыкмы?
Тулмасын кар, куеныңа кереп.
Йөрәгеңне сакла, бәгърене,
Бәгърең, димен, бозланмасын берүк!
Ишетәсеңме, кызым!

Әй лә, әни! Сине аңлар өчен сүзлек кирәк.
Аңлатмалы!
Монда – урам, ә урамда – буран!
Һәм дә суык... кул катмалы...

Әһә! Рәхәт, дигән идең...
Бияләй кигән идем...
Шылтыраттың... Салдым...

Рәхмәт... телефоның алдың...
Бар да яхшы булыр,
Синең белән җаным...

* * *

Уем – үрмә җил.
Кинәттән бөтереп ала да
Мизгел эчендә илтеп суга сала.
Һәм... шундук тынып кала...
Мин дә калам инде... салган җирдә –
Суда...
Батам-чумам, көчкә чыгам,
Шөкер,
Исән бу юлыга...

Күңелем – үрмә гөл...
Үрелә-үрмәли биеккә,
Яктыга, кояшка тартыла,
Ачыла...
Аннан... яна, көя,
тилмереп тамчыга...
Ярый,
бер болыт табыла!
Шифалы яңгырын
Җаныма яудыра.
Шөкер,
Бу юлы да
Исән калына...

Йөрәгем – утлы көл...
Туктаусыз көйри...
Гел!
Кабына тыннан да,
Ялганнан, чыннан да
Тотына дөрләргә,
Күкләргә үрләргә.
Ә күктә – яшеннәр,
Йолдызлар сугышы...
Тау кадәр йөрәктән
Кала тик кыйпылчык...
Соңгысы...

Үрмә җил, үрмә гөл,
Утлы көл –
Шагыйрьләр булмышы!

* * *

Тәүге күкрәү җир күкрәген
тетрәндергән саен,
хәтер урамында тәгәрәп лә ауный
балачагым...
Әнә,
маңгай чәчен төзәтә-төзәтә,
оялчан елмаеп,
аны яшьлегем күзәтә...
Бер салып, бер киеп күзлеген,
кульяулыгын йомарлаган бүгенгем
сиздермичә генә
яшен сөртә... бугай...
Нәкъ шулай!..

Кайттык-киттек, киттек-кайттык –
Гомер юлда үтте.
Ә әниләр, җан әрнетеп,
Кайтмас җиргә китте...

Ятим нигез, ятим урам,
Ятим авыл-бәгырь.
Мичне сүттек, илне сүттек,
Тере утсыз дәвер...

* * *

Кайчан бакма, ул балконда керләр кибә...
Һәм бер картлач пәйда була ара-тирә.
Әллә карчык?..
Күзләр хәзер начар күрә...
Кыскасы,
Арык кына җан иясе
Арлы-бирле йөри.
Кайчак, туктап,
Тәрәзәдән җирне күзли,
Кер аралап.
Җен ачуым килә шулчак!

Әйе,
ел саен яз белән җәй очрашкан мизгел
җан күгемне бизи.
Ел саен йөрәк түзми,
кабалана-кабатлана,
шигъри сүз эзли...
Иң-иңен, тәүге күкрәүләргә тиңен!

Аһ,
Быел яз да табылмады…
Алда язлар тагын бармы?!
Бармы тагын?!
Белүче – Ул.
Иң-иң сүз дә… бәлки –
Ярлыкагыл, ярлыкагыл...

ХӘБӘР

Аккошлар төште?!
Безнең күлгә дә?!
Һай, ышанмасны, зинһар, сөйләмә!
Дөрес булса да...
Булса да дөрес...
Аккошлар йөзә
Унлап пар, имеш...

Үзең күрдеңме?!
Бардыңмы якын?!
Бу бит могҗиза!
И кошкайларым!
Беренче тапкыр!

Минем кайтканны
Көтәрләр микән?
Юлга кузгалам
Хәзер! Юк, иртән...
Иртән дә булмый...
Бәлки, кич... Соңрак...
Җай чыкмас, ахры...
Ял көннәрендә
Килермен урап?!.

Аһ, канатсызлык
Өзә үзәкне!..
Телә тышаулар
Бәгырьнең итен...

Шәһәр. Бүлмә. Төн.
Күземне йомам.
Аккошлы күлем
Төшемә керсен...

* * *

Ефәк түгел, парча түгел,
Ситсы алдым сатып.
Булмасмы, дип, хет бер җәйгә,
Балачакка кайтып...

Ак җирлектә вак чәчәкләр:
Алсу, зәңгәр, сары...
Аклары да бардыр, беләм,
Күренмиләр бары...

Акта ак ничек күренсен?!
Балачак та шулай...
Ул аклыкны, ул шатлыкны
Ситса-бүзгә төрелгәнче
Сагынырмын бугай...

* * *

Болын булып калды өйләр,
Сүткәч мич-морҗаны.
"Күр әле син, алып торган
Бу пич ярты ызбаны!" –

Диеп сөйләнгәнем истә,
Мич урынында басып...
Ялт иттердек өйне, юып –
Долой, корым, балчык!

Моңсу гына карап торгач,
Безнең "кыланмыш"ка,
Әйтте әни, авыр сулап:
"Ничек яшәр икән авыл
Тере уттан башка?

Сүнгән учак тирәсендә
Юанмассыз озак.
Җылы эзләп китәрсез лә
Якты дөнья буйлап..."

Шулай диде мичче әни,
"Мастирогын" сыйпап.
Керфек очы чылганганын
Кая күрү ул чак!

Кая аңлау мичче күңелен,
Тере утның көчен?!
Берәм-берәм таралыштык,
Сагынып кайтыр өчен...

Сыпырып ла и атасы иде,
Нинди бетмәс чүпрәк-чапрак!
Кем соң элә?
Көн дә бит, көн дә!
Юкса белә,
Нинди газап җирне
Балкон тәрәзеннән генә күзләве...
Хәлсез бармаклар белән
Этәреп керләрне,
Элпә каплаган күзләрнең
Көн яктысын эзләве...
Иң газабы –
Күңелнең соңгы өзек кылын
Кер бавына... юк ла,
Өмет бавына бәйләве-төйнәве...

Кайчан бакма, ул балконда
 керләр кибә...
Ә мин менә
бүгеннән керләремне балконга элмим!
Тәрәз пәрдәләрен тутырып ачам!
Иң газабы –
Күңелне, йөрәкне кемгә ачыйм?!
Белмим...

ТУГАН ТӨНДӘ...

Август җиле
Иңнәремнән коча...
Исергәнме алма исеннән?
Куеныма кермәк була, күрче,
Йолдыз яңгырында чыланган да
Күшеккәндер, брамат, өшегән...

Август җиле
Чәчләремә кагыла...
Улмы, минме моңсу көрсенгән?..
Билләремә төшкән толымлы чак
Чыкмый бугай һаман исеннән...
Чыкмый ла шул һаман исемнән...

Август җиле
Нидер сөйли, көйли...
Җил теленә кем соң төшенгән?..
Алай дисәм, тыңлый-тыңлый,
Күз алдыннан тулы гомер үтте:
Бәхет үпте, җанны сагыш өтте,
Бакча өсте алма төшеннән...

Яшәү-сергә мин ул төшенгән...

Чаллы.

Рамил КУРАМШИН: «Мин хәзер дә сәхнәгә чыгып уйнарлык хәлдә идем»

● Аталы-уллы Курамшиннар триосы. 1950 ел.

70 яшьлек юбилеен зурлап үткәргәннән соң, атаклы баянчыбыз Рамил Курамшин сәхнәләрдә күренми башлады. Бүген Рамил абый тыныч кына тормыш белән үзенең Казандагы фатирында яшәп ята. Алдан билгеләнгән вакытта безне Рамил абыйның хатыны Рузалия апа көтеп тора иде инде.

Рамил абый сәхнәдә башка баянчылардан төз басып уйнавы белән аерылып тора иде. Аның моннан 5 ел элек булып узган юбилей концертындагы чыгышын үз күзләрем белән күреп, исем-акылым китеп тыңлап торган идем. Нәкъ шундый мәгърур булып, баянын күтәргән килеш исемдә калган Рамил абый.

Кызганыч, соңгы елларда сәламәтлеге бераз какшап киткән икән, аның бүлмәсенә кергәч, каушап калдым: мин сәхнәдә күреп гадәтләнгән Рамил абый бераз үзгәргән, шулай да ул минем белән бик теләп әңгәмә корырга риза булды.

Караваты янына терәлеп торган өстәлгә күз төште, анда нәрсә генә юк! Рамил абыйның берсеннән-берсе матур фотолары, дисклары, кассеталары, китаплары. Ә өстәл астында – Рамил абыйның гомерлек «дуслары», без телевизордан күреп үскән легендар баяннары. Үзләре зур, үзләре авыр: «10-15 килограмм!» – ди Рамил абый.

Рузалия апа фотоальбом тартып чыгарды. Ә анда Рамил абыйның шәхси фотолары – кадерле тарихи фотосурәтләр! Һәр фотога озаклап карап тордым. Әйтерсең алдымда шул мизгел: Илһам абый бригадасының концерт куюы, артистларның грим бүлмәсе, союзның төрле шәһәрләре буйлап гастрольләр һәм... яшь, чибәр, дәрте, көче ташып торган мөлаем егет – Рамил абый. Рамил абыйның фотосурәтләрен карагач, ижатына гына түгел, үзенә дә гашыйк буласың, чын.

Шушы халәттән арына алмыйча, Интернеттан Рамил абыйга үзенең чыгышларын, видеоязмаларын, концертларын ачып күрсәттем. Рамил абый исе китеп карап торды. Күзен алмыйча. Әле бер, әле икенче язмасын куям, кешеләр язып калдырган соклану, мактау сүзләрен укыйм, ә ул элекке формасына кайткандай була: «Күрәсеңме, ничек төгәл, ничек төгәл уйныйм! Хәзер шундый виртуозны эзләп карасаң да таба алмассың», – дип, үзенең чыгышын иләк аркылы үткәргәндәй бәяли ул.

Менә аның 70 яшьлек юбилее. Әле 5 ел элек кенә булган. Монда да әле Рамил абый сәхнәләрне гөрләтерлек хәлдә: әнә Хәмдүнә апага, Зөһрә апа Шәрифуллиналарга йөгерек бармаклары белән татар көйләрен сиптереп, тәп-төз итеп басып, сәхнәдә баянда уйный. Шушы язмаларны караганда, бервакыт, Рамил абый кулъяулыгы белән битен сөртеп алды. Күзләренә яшь тә килде бугай, шулчак үзен бик тә, бик тә жәлләп куйдым. Йөрәгем әрнеде. «Нинди чакларыгыз бар иде бит, эх, Рамил абый!»

– Рамил абый, татарда баянны сездән башка күз алдына китереп булмый.

– Ә җитәр бер заман – атаклы татар баянчыларының берсен дә белмәсләр. Әлеге яшь буын баянчылар руслардан күреп уйный, ә чын милли, татар моңының асылын күрсәтә торган бормалы көйләрне белмиләр, чөнки тыңлап үсмиләр. Ә мин тыңлап үстем, җанга сеңеп калган. Авылда да: «Әнә, Сөләйман абыйның кече малае баянда сиптерә!» – дип әйтәләр иде. Абыем Рафаил белән чиратлашып уйный идек.

● Курамшиннар гаиләсе. Рамил абыйсы Рафаил һәм әти-әнисе белән. 11 гыйнвар, 1949 ел.

Абыем Рафаил Курамшин 1972-1976 елларда Габдулла Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясендә Габдулла Рәхимкулов һәм Флера Сөләймановаларның концерт бригадасында эшләде. Шулай булгач, урта мәктәпне тәмамлаганда, минем алда: «Кая барырга, кем булырга?» – дигән сорау тумады. Баянда уйный башлаган елларда ук кыйблам Казанга юнәлгән иде. «Авыл малаен музыка училищесына кабул итәрләр микән?» – дигән уйлар белән мин Казанга киттем.

– Нәкъ Казанда Сез артист буларак формалашкансыз.

– Мин килгәндә, музыка училищесына кабул иту имтиханнары тәмамланган иде. Миңа педагогика институтының музыка факультетына укырга керергә киңәш иттеләр. Имтиханнарны уңышлы гына тапшырып, студент булдым. Ел ярым укыганнан соң, профессиональ баянчы булу теләге миңа тынгылык бирмәде һәм мин музыка училищесына күчтем.

Училищеның 2 курсын тәмамлаганда, радиодан чыгышлар ясый башладым. Баян өчен үзем язган пьесаларны, татар халык көйләрен эшкәртеп уйнадым: «Баян өчен пьеса», «Шаяру», «Концерт пьесасы», «Төймә», «Карабай», «Җыен көе». Укыган елларда ук миңа төрле концертларда Фәхри Насретдинов, Идеал Ишбүләков, Рәйсә Билалова, Венера Шәрипова, Хәдичә Гыйниятова, Әлфия Галимова, Габдулла Рәхимкулов, Зифа Басыйрова кебек күренекле җырчыларга да уйнарга туры килде.

– Туган ягыгыз – Нижгар якларына кайтып йөргәнсездер?

– Укыганда атна саен кайта идем. Казаннан Сергачка поезд йөри иде, транспорт ягыннан проблема булмады. Минем өчен авылга кайту зур вакыйга була иде.

– Туганнарыгыз?

– Гөлзар һәм Гөлсем исемле ике сеңлем бар, алар Мәскәүдә яши. Әйтеп үткәнемчә, Рафаил исемле абыем бар. Ул миннән ике яшькә олы, берничә көн элек бакыйлыкка күчте. Казанда яши иде. Абый бик әйбәт, ачык кеше иде, кызганыч, иртәрәк китте.

Безнең якта 35ләп татар авылы бар. Шуларга укытучылар әзерләү өчен, педучилище ачтылар. Алга китеп әйтим: Урыс Пожарыннан килгән рус малайлары яхшы булмаган гамәлләр кыла башлагач, педучилищены тараттылар. Әтием 70 яшенә кадәр рәсем һәм музыка дәресләре дә укытты. Баян, домбра, аккордеонда уйнады. Шунда балалар хоры оештырган иде. Балаларны татарча җырлатты. Берзаман, смотрга шул хорын алып китте, балаларны татарча җырлатып, беренче урын алып кайттылар. Ул вакыт өчен бу – зур дәрәҗә иде.

Әнием башлангыч сыйныф укучыларын укытты. Мин балачактан ук музыка дөньясына кереп киттем. Әле хәзер дә кайбер баянчылар: «Сөләйман абыйда укыдым», – дип горурланып әйтә. Әтием йомшак күңелле, әйбәт кеше иде.

Казанга килгәч, телевидениедә күренә башлагач, абый-апалар: «Менә бит, Сөләйман абыйның улы бит инде бу!» – дип мине таныганнар. Алар авылда, ә мине Казаннан – Татарстанның башкаласыннан телевидениедән күрсәтәләр. Әтигә дә, әнигә дә минем телевидениегә чыгуым зур горурлык булган.

Казанда музыка училищесында укыганда, Рафаэль абый Ильясов «Татарстан» радиосында тапшыру алып бара башлады. Ул мине ишетеп алгач, үзе белән концертларга да ала иде, чөнки мин бөтен җырларны уйный белә идем. Алар опера театрыннан берничә җырчы концертлар куеп йөрде. Мин үзенә күрә бер мәктәп үттем. Баштан Татар дәүләт җыр һәм бию ансамблендә бер ел уйнадым, аннары Татар дәүләт филармониясенә эшкә урнаштым. Филармониягә мин әзер баянчы булып килдем.

– Сез татарча белем алып югалып калмагансыз...

– Нинди югалып калу? Мине кешеләр белә: мин – лидер, мин – патриот. Мин, мәсәлән, татар мәктәбендә укыдым, шуннан нәрсә? Руслардан яхшырак, грамоталырак язам. Татарларны урыс ясау – коточкыч хәл. Сөйләшүләрен карыйм – ташка үлчим. Русча да, татарча да яхшы сөйли белмиләр.

– Татар халкының моңы – тальян гармунда, диләр. Моңа ничек карыйсыз?

– Бу мәсьәләгә берьяклы гына карамыйм. Мин үзем баянчы буларак, баянны бик шәп беләм. Бездә тальян гармунга кирәгеннән артык өстенлек бирәләр. Тальян – «итальян» дигән сүздән бит ул. Италиядән кергән уен коралы. Мин аның тавышына «аһ» итмим.

Мәсәлән, баянда әллә нинди бормаларны уйнап була, баянда ярым тоннар күбрәк. Мөхтәр абый белән Рокыя апа баянга күчкәч, моны ошатмаучылар да булган. Алай дисәң, аккордеон да татар музыкасы өчен әйбәт, регистрларын да алмаштырып була. Әмма баян – аерым бер дөнья. Менә хәзер музыка училищесы яки консерваториядә уйнатып кара. Гармун-баяннарда татар моңын чыгара алмыйлар, чөнки күңелләрендә юк. «Формально» уйнаса да, йөрәгеннән, күңеленнән агылып чыкмый. Күңелеңдә булдымы – бармакларыңнан саркып чыгарга тиеш.

Радио-телевидение бар, «элек шулайрак уйныйлар иде» дип, пропагандаларга тырышырга кирәк. Ә тырышучылар бар, шөкер. Элекке уйнаучыларны, җырчыларны тыңлап, шуңа ияреп эшләсәләр, татар моңын яшәтергә була.

– Ни өчен татар халкында тальян гармун башка уен коралларын кысрыклап чыгара алган дип әйтеп була?

– Кысрыклап чыгарган, димәс идем. Гармуннарның да төрлесе бар. Кайсы әче телле, яңгырашы ягыннан татарга килешми торганнары бар. Хәзер тальянга берьяклы авыштылар. Мәсәлән, мин бары тик баянда гына уйнар идем. Анда мин ничек телим, шулай уйный алам. Баян миңа мин теләгәнне бирә.

Тальян ярлырак. Ул күбрәк әйлән-бәйлән, туй-мәҗлескә бара. Тальянны бөтенләй инкяр итмим, шул ук вакытта мөкиббән дә китмим. «Тальянда гына моң» диючеләр белән килешеп бетмим, ә менә баянда нинди генә бормалар чыгармыйсың – татар моңын тулысынча баянда күрсәтеп була. Кемдер тальян гармунда яратып уйный икән, уйнасын. Бер сүзем юк. Ләкин татарча булсын. Төрле кешенең төрлечә була инде ул. Аларны үзешчән түгәрәкләрдә эшкәртергә, пропагандаларга була.

Ике рәтле гармуннар тальян гармуннардан әйбәтрәк. Ике рәтле гармуннарда мөмкинлекләр күбрәк. Шәп итеп уйный алсаң – бер хәл, бөтен кеше дә оста итеп уйный алмый бит. Тальян гармуннарда да, «Саратов» гармунында да, шырпы тартмасы кебек гармуннарда да уйнаучылар уйнасын, әйбәт, сыйфатлы гына уйнасыннар иде, диясе килә.

Радиодан тыңлаштыргалыйм, матур итеп уйнаучылар да бар. Карасаң – гади халык вәкиле! Каядыр укымаганнар да үзләре. Төрлечә булырга тиеш. Букет та бит төрле чәчәкләр булганга гына матур. Бер ромашка гына кызык булмас иде. Җырчыларны әйткән дә юк, анда йөзләгән җырчы чыга, күпчелеге аның бер балык башы инде...

– Хәзер эстрадада гармунда уйнау кимеп бара...

– Кимеде, дип әйтмәс идем, радио-телевидениене ачып карасаң, анда һәрчак гармунда, баянда уйныйлар. Ул «Алмагачлар»ны гына да тальянда күпме уйнарга мөмкин икән? Аны баянда да бик шәп уйнап була, фантазияңне генә эшкә җигәргә кирәк.

– Сез сәхнәдә үз-үзегезне тотышыгыз белән аерылып торасыз. Сезнең гәүдәгез һәрчак төз, туп-туры, гармун баулары да асылынып тормый...

– Дөрес әйттең. Миңа гади кешеләр дә, баянчылар да: «Рамил, син шәм кебек төптөз басып торасың», – диләр. Берниди артык хәрәкәт юк. Ә баян 10-15 килограмм. Концерт 3әр сәгать бара. Көненә 2 концерт булса, 6 сәгать дигән сүз. Мин артык таза кеше түгел бит. Җыйнак кына гәүдәм белән баянны тотып та тора идем, уйный да идем. Героизмнар куйдым инде... Аны миңа, хәсрәтемне уртаклашкандай, килеп-килеп әйтүчеләр була иде. Уйнарга бүтән баянчы юк бит, кая барасың.

Бу – үз-үземә куйган таләп. Күз алдыңа китер: синең яныңда бөек Илһам Шакиров җырлап тора, ә син кырлы-мырлы басып уйнап торсаң, аннары ни булыр? Илһам абыйның статусына нәкъ менә шулай «академик»ларча басып тору кирәк иде. Алайса кайберәүләр хәзер сәхнәгә чыга да, аякларын теләсә ничек куеп, артыгын кыланып җибәрә. Мин икеләтә культура мәктәбен үттем, дисәң була. Ул шулкадәр көчле мәктәп булды.

– Сез сәхнәгә аяк басканда, баянчылар инде басып уйный идеме?

– Әйе, басып уйный башлаганнар иде. Ә менә мин кечкенә вакытта, безгә филармония артистлары килгәндә, баянчылар утырып уйный иде. Мин сәхнәгә килер алдыннан басып уйнау модасы башланды. Ул егетләр миннән тазарак, озынрак буйлы иде. Мин шул «басып уйнау модасы»на эләктем инде. Авыр ул. Бер як җилкә асылынып төшә, умыртка баганасы да авыртып ала, түзәргә туры килә иде. Илһам абый бит ул кырыс та булып алгалый иде...

– Рамил абый, Сез үзегез дә искитмәле җырлыйсыз бит әле. Сезнең сулышыгыз шундый киң! Илһам абый мәктәбе сизелә... Миңа калса, Сез – аның дәвамчысыдыр.

– Моның сәбәбе бер генә: мин 20 елдан артык бөек Илһам Шакировка уйнап йөрдем бит. Мин аның бөтен репертуарын яттан җырлап бирә алам. Моны нииндидер коры охшарга тырышу (подражание) дип түгел, ә аның моңнарының минем күңелгә сеңүе һәм башкару алымнарын (мәктәбен) җентекләп үзләштерү нәтиҗәсе дип кенә аңларга кирәк.

Төрле концертларда булырга туры килде. Шунда башка «пешмәгән» артистлар да җырлый. Менә шуларны ишетәсең дә, ачу чыга. Тыңлап-тыңлап тора идем дә, соң, болай гына мин дә җырлый алам бит, дия идем. Авылга кайткач, тау башына менә идем дә шуннан кычкырып җырлый идем. Өйдә әти янында алай җырлап торып булмый бит инде.

Бервакыт филармониядә җырлаганымны ишетеп алдылар. «Син җырлыйсыңмыни?» – диләр. Шуннан соң китте... Рамил җырлый икән, дип, Илһам абыйга да әйткәннәр. Ул да җырлатты. Ә Илһам абый янында җырларга куркалар иде. Мин курыкмадым, чөнки без гел бергә гастрольләрдә йөрдек. Мин уйныйм, ул җырлый. Туганлашып беттек.

Илһам абый белән эшләмәсәм, бәлкем, авызымны да ачмаган булыр идем... Аның тәэсире зур булды. Аннан соң, Илһам абый өч тиенлек җырлар җырламады. «Менә дигән» тавыш белән җырларга кирәкле җырларны гына башкара иде. Кайвакыт хатирәләргә бирелеп, уйланып-уйланып торам да, аннан соң «кылт» итеп Илһам абыйның юклыгы искә төшә. Йөрәк әрнеп китә. Ул исән булса, янына барып, күрешеп килер идем. Ул вафат булганда мин авырдым, кызганыч. Телевизордан карадым, анда бөтен халык елады. Ничек еламыйсың, ди. Әле аның «Мәңгелеккә китеп барам» дигән җырын куйдылар. Үзе турында үзе җырлап китте ул.

Ул бит, чыннан да, бөек кеше иде. Илһам абый белән эшләү минем өчен зур этәргеч булды. Аңа аннан-моннан гына уйный алмыйсың. Аның янына чыгып уйнап җибәрү – үзе бер горурлык иде.

Мәскәүдән, тикшерергә дип, филармониягә төрле комиссияләр килә иде. Безнең Илһам Шакиров бригадасына кермиләр иде, чөнки Илһам Шакировны беләләр. Комиссия безне җентекләп карамады.

Илһам абый Нәби Дәүлинең «Татарстан — минем республикам Россиянең матур җирендә» дигән җырын җырлады. Безнекеләр «Россиянең» дигән сүзне «илебезнең» сүзенә төзәттерде. «Нигә Россиядә? Россиядә түгел, үз җиребездә бит», – диделәр. Төрле хәлләр булды инде. Анысы да үтте дә китте...

– Илһам абый кебек бөек җырчы булу өчен көчле тавыш кына җитәме?

– Юк, чөнки чын сәнгать әсәрен тудыру өчен, табигый таланттан тыш, үз телеңне камил белү, милләтпәрвәрлек, халкыңның тарихын, гореф-гадәтләрен, әдәбият-сәнгатен һәм башка якларын тирәнтен үзләштерү зарур. Ә Илһам абый – шушы сыйфатларның барысына ия җырчы һәм зур эрудицияле шәхес иде. Шуңа күрә дә аның җыр сәнгате халкыбызның бөтен тарихи байлыгын гәүдәләндерүче илаһи сәнгать үрнәге булып тора.

Гастрольләрдә йөргәндә, Илһам абый белән безнең сөйләшүләребезнең төп темасы йә җыр-моң турында, йә шул алда санап киткән темалар тирәсендә бара торган иде. Шундый җырчыга баянда уйнап йөрүләре бер бәхет булса, искиткеч тирән акыллы абый белән сөйләшеп, фикер алышулары минем өчен икенче бер бәхет иде.

Габдулла Тукай язган һәм халкыбызның гимнына әйләнгән «Туган тел»нең дүртенче куплетын халкыбыз әле 1980 еллар азагында гына ишетеп белә һәм җырлый башлады. Ә бит Илһам абый аны 1960 елларда ук инде сәхнәләрдән җырлап йөри иде. Аның белән даими эшли башлаган беренче гастрольдә үк (1969 ел, май ае) ул бу җырны концертта җырлагач, мин: «Ә нигә соң ул дүртенче куплет мәктәп дәреслекләрендә юк?» – дип сорадым. Ул исә: «Диннән аерылган коммунистлар аны «догам» һәм «Ходам» дигән сүзләре өчен тыйганнар», – дип җаваплады.

Илһам абый үзеннән өлкән буын җырчылар, композиторлар турында ихтирам белән искә ала иде. Мәсәлән, аның миңа берничә мәртәбә: «Энекәш, әгәр дә Гөлсем апа (сүз җырчы Гөлсем Сөләйманова турында бара) булмаса, мин дә булмый идем», – дип әйткәне хәтердә. Булуын, бәлки, булыр иде дә, тик аның бу сүзләрендә тирән мәгънә ята...

Бүгенге көндә үзем дә: «Илһам абый белән бергә эшләргә туры килмәсә, «Кара урман»нарны җырлау түгел, гомумән, җырлыйм дип, авызымны да ачып карамаган булыр идем», – дип әйтә алам. Мәшһүр җырчы Рәшит Ваһапов турында да: «Ул – бөек җырчы иде», – дип, беренче булып әйтергә җөрьәт итүче Илһам абый иде.

Исегезгә төшерегез әле, мәшһүр Сәйдәшнең җырларын соңгы елларда концертларда еш ишетәсезме? Тәгәрәк әйтсәк, ишеткәнегез бармы? Менә шул шул!.. Ә Илһам абыйның концерт программасында һәрдаим Сәйдәш җырлары яңгырап торды. Илһам абыйның таләбе буенча, без баянчылар концертны Сәйдәшнең «Наемщик» музыкаль драмасына кереш музыкасы белән ачып җибәрә идек.

Илһам абыйның тагын бер асыл сыйфаты турында әйтәсем килә. Ул беркайчан да, заман һәм мода агымнарына яраклашып, арзан, зәвыксыз, мәгънәсез, үзе әйтмешли «шырдыйбырдый» җырлар җырламады. Аның репертуары тирән мәгънәгә ия, уйландыра, күңелләрне сафландыра, матурлыкка, иманга өнди һәм милли горурлык хисе уята торган җырлардан гына гыйбарәт булды. Аңа бит күп композиторлар (профессионаллары да, һәвәскәрләре дә) үз җырларын тәкъдим итә иде, әмма ул аларның алда әйтелгән таләпләргә туры килә торганнарын гына сайлап ала иде.

(Дәвамы киләсе санда).

Зилә МӨБӘРӘКШИНА.
intertat.tatar

Мәгариф өлкәсендә

● РФ Президенты Владимир Путин мәктәпләрдә Бердәм гомумбелем программалары кертү һәм Россия Мәгариф министрлыгына уку йортлары өчен дәреслекләр һәм пособиеләр эшләү буенча Дәүләт заказларын бирү буенча вәкаләтләр бирү турындагы Федераль законга кул куйды. Мәктәпләр өчен бердәм федераль гомуми белем бирү программалары эшләнәчәк һәм мәгариф министрлыгы тарафыннан расланачак. Мәктәпләр 2023 елның сентябреннән үк эшли алсын өчен, аларны 2023 елның 1 гыйнварына кадәр расларга тиеш.

Моннан тыш, башлангыч мәктәптә «рус теле», «әдәби уку», «әйләнә-тирә дөнья», «рус теле», «әдәбият», «тарих», «җәмгыять белеме», «география», «тормыш иминлеге нигезләре» кебек фәннәрнең федераль эш программалары мәҗбүри булырга тиеш.

● Мәгариф һәм фән өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәт җитәкчесе Анзор Музаев 19 октябрьдә ел саен үткәрелә торган традицион Бөтенроссия ата-аналары белән очрашачак.

Очрашу барышында Анзор Музаев һәм ведомство белгечләре БДИ һәм ДИА-9, Бөтенроссия тикшерү эшләре, белем бирү сыйфатын тикшерү, белем бирү оешмаларын лицензияләү һәм аккредитацияләү, башка актуаль темаларга кагылышлы сорауларга җавап бирәчәкләр.

Анзор Музаевка сорауларны алдан ук «ВКонтакте» социаль челтәрендәге Рособрнадзор битендә бирергә мөмкин. Очрашуны туры эфирда Рособрнадзорның «ВКонтакте» социаль челтәрендәге һәм Rutube платформасында карап булачак.

● «Авыл укытучысы» федераль программасы буенча Татарстан авыл мәктәпләренә өч ел эчендә 32 педагог килде. Бу хакта Дәүләт Советының 34 нче утырышында республиканың мәгариф һәм фән министры Илсур Һадиуллин хәбәр итте.

Программада катнашучылар-урта һөнәри яки югары белемле, авыл торак пунктларында, шәһәр тибындагы бистәләрдә яки 50 мең кешегә кадәр булган шәһәрләрдә урнашкан белем бирү оешмалары белән кимендә биш елга хезмәт килешүе төзегән укытучылар.

Программага эләккән һәм сайлап алынган эш урынына күчеп килгән укытучылар дәүләттән 1 әр миллион сум акча ала.

(Ахыры. Башы 37 нче санда).

Алма дисәң дә алалар... көрәкне!

Миңлебикәнең кайнатасына килсәк, ул гаилә мөнәсәбәтләрендә бөтенләй катнаша алмый, мәрхүм. Югыйсә, хикмәтләләр арасында иң авыр хикмәтлесе булган ул. Хикмәте шунда ки, сугыш башлангач та, Ватан таләп итә дип аны, алтмыш яшенә чак кына җитмәстән, хезмәт армиясенә алып киткәннәр һәм ул шул китүеннән кайтмаган. Менә кайда кансыз хикмәт! «Гомерем булып, таш басмаса, ташламам, җан кисәгем», – дип җырларга яраткан таш салу остасы Әмирҗанның гүя әйткәне юш килгән: Эстәрлетамакның Шихан тауларында аны ак сода ташы басып үтергән. Менә бит ничек килеп чыга тормышта!

Килен кеше иренең хикмәтле, атаклы «Лапаты не яблыкы» хикәятен уйлап тапкан сирәк кеше икәнлеген белә. Моның белән хәтта эченнән генә горурлана да. Ничек горурланмассың: Биктимерне исеме белән дә атамыйлар бит– яратып «Лапаты» гына диләр. Шул хикәятне аның үзеннән бик тә сөйләтәсе килә Миңлебикәнең. Нинди чаралар, нинди юллар гына эзләп карамады ул иренең авызын ачтыру өчен. Юк, булмады. Әмма юкка гына «Бирәсе килгән колына чыгарып куяр юлына» димәгәннәрдер. Менә бит, көтмәгәндә бу тарихны сөйләтүнең иң үтемле, иң кыска юлын тапты Миңлебикә. Дөресрәге, Аллаһы Тәгалә үзе табып бирде.

Эш болай булды. Көннәрдән бер көнне, кояш баткач, бар кешелек йокыга талгач, Биктимер Миңлебикәдән гомердә күрелмәгән үҗәтлек белән бәби таптыра, хәтта ирләргә хас кырыслык белән, аяк терәп, диик микән – бала таләп итә башлады. Гарьлеге килдеме? Миңлебикәгә баш астындагы түшәге йөзләгән энә белән чәнчелгәндәй итте. Хатынкай түшәгеннән күтәрелә биреп торып утырды һәм ир таләбен ярым-ярты шаяруга борып, үзе дә киная белән җавап кайтарды:

– Бәби минем җиз карынымда сине көтә-көтә алтынга әйләнде инде, җаныкаем!.. Теге «Лапаты не яблыкы»ны үз авызыңнан ишеткәч тә, ул үзе безнең янга сикереп төшәчәк!.. Алла боерса!.. Күр дә тор!.. Чынлап әйтәм, Биктимер!..

– Уф... Алай булса!. Һм... – диде Биктимер уфырып. Һәм үзе дә җәһәт кенә Миңлебикәсенең янәшәсенә торып утырды. – Мин бит күптән бала телим... Әйткәнем генә юк иде... Ә теге... лапаты-яблыкыга килсәк... Ул, хатын, ни...

Сөйләргә тотынудан алда аның чигәләрендә кан юллары бүртеп чыкты. Баш түбәсендә лепкәсе йөри башлады. Биктимер трахтыры астына кереп күтәргәндәй көчәнеп, сузып сулыш алды һәм һәр сүзен сытып чыгаргандай сызланды...

– Йә соң... алай булгач... Бисмиллаһ!..

Түшәктә һәм бүлмәдә икәүдәнікәү генә булсалар да, бу мизгелдә аларны гүя бар дөнья, бар галәм, бар җиһан, шулар арасында генералиссимус Сталин һәм Кызыл Мәйдан үзе тыңлый иде...

– Һм... 1940 елның язында... Безне күрше авыл егете Фазыл белән Днипрәгис дигән камсамул-яшьләр төзелешенә... Җир чокырга алып киттеләр. Дабравалис итеп алып киттеләр, дисәң, дөрестер. Авылдан ары чыгып, читкә киткәнем, хәтта күрше авылны да күргәнем юк. Урысча белмим!.. Фазыл да шул чама. Ул, миннән аеры, «хлеб-соль»ләрне шартлатып әйтеп сала башлаган иде...

Китереп бушаттылар безне шул Днипер дигән мәһабәт елга ярларына. Ага гына малай! Җимертеп ага!.. Камсамул-яшьләрне өерләре белән китереп ташларга булдырсалар да, көрәк урынына буш авызларын гына күтәреп килгән шул кызыл камсамулларны куллырына тотып эшләргә нәкъ әнә шул кара көрәк белән тәэмин итә алмаганнар иде. Сугышта сугышырга мылтык җитешмәгәндәй, төзелештә җир казырга көрәк җитешми... Менә гаҗәп!.. Әлбәттә, Фазыл белән минем авылдан сапларын үзебезнең төкерек шомарткан көрәкләребез бар-барлыкка, әмма... сак кыйлан!.. Кытлык тамак саттыра, дигәндәй, мондый шартларда бер-береңнән көрәк чәлдерү гадәте таралды бит!... Карап кына тор, югыйсә күрәгенне... күз ачып йомганчы шудыралар!.. Шулай бер тапкыр төшлеккә туктадык. Күрәм, бер симез ботлы сары маржа кызы минем җиргә кадап куйган көрәгемне каз канаты кебек култык астына сыпырып кына алды да... китеп тә барды!.. «Тукта! – дип кычкырам. – Алма минем көрәкне!» Юк, туктамый бу. Чаба! Җилдерә генә!.. Инде мин аның артыннан ике кулымны тезләремә чәбәкәйләп тамак ертам: «Түткәй, тукта!.. Калдыр көрәкне!» Кая ди туктау, сыпыртып кына ята!.. Урысчалатып чәпәр идем, аларча мин телсез тек телсез. Шул чак гарьлегем котырды. Юк, мин әйтәм, телле мин!.. Ничек кенә телле әле!.. Минем урысча белгән сүзләрем дә байтак бит! Файдалан! Тондыр үзләренә күчтәнәч итеп!.. Көрәк – лапаты, алма – яблыкы, «не» дигәннәре «юк, ярамый» дигәнне аңлата сымак. Нигә ярып салмаска?! Мин куанычтан канатланып, бар белемемне җигеп, шартлар хәлгә җитеп бакырам тегеңә:

– Лап-па-аты не яб-лы-кы!.. Лап-па-ты не яб-лы-кы!..

Җитте бездән көләргә! «Татар акылы төштән соң», имеш! Төштән соң түгел, нәкъ сәгатендә!– дип уйлаган булам мин кычкыра-кычкыра үземчә горурланып. Юк, мин кычкырганга да туктамый бу, каһәрең. Әллә ишетми–һаман чаба гына! Куркудан һәм артык көчәнүдән өнем йотыла, сүзләрем тимергә кыршылган калай шикелле тамак төбемнән зәңгәрле-яшелле төсләр белән күгәреп чыга:

– Ла-па-ты не яб-лы-кы! Ла-паты не-е-е яб-лы-кы-ы-ы!..

Шул чак Биктимер сөйләгән мәзәк хәлнең асылы Миңлебикәгә дә барып җитте. Ул терсәк очы белән каты итеп иренең касыгына төртте дә, пырхылдап көлеп җибәрде. Туктады дигәндә, тыела алмыйча тагын көлде. Тагын көлде.

– Соң, лапатының не яблыкы икәнлеген дә белми идеңмени, Биктимер үскәнем?

– Һы, белерсең сиңа! Утыртып куйсалар!.. – диде Биктимер үзе дә Миңлебикәнең касыгына төртеп. – Заманы нинди иде бит! Белгән өчен бер, белмәгән өчен ике елга тыгалар. Һәм эчен тутырып тын алды да, сүзен дәвам итте:

– Шул мизгелдә безнең Днипрәгис төзелеше бер тынга сагаеп, шым булды? Кем болай тамак ярып кычкыра? Ни сәбәпле? Беренче булып янәшәмдә урысча миннән яхшырак сукалаган бердәнбер кешем – авылдашым Фазыл хәлне аңлап алды. Башта шаркылдап, аннан утырган урынында авып китеп, аннан тәгәрәп, аннан ауный-ауный көлә иде ул. Халык та айныды!..

– Лапаты не яблыкы!.. Ха-хаха! Лапаты не яблыкы!.. –дип бөтерелә иде үләндә Фазыл һәм аның тирәсендәге халык эчен тотып. – Көрәк алма түгел, кәнишне!.. Без бит борынгы каторжниклар нәселеннән. Моны гына беләбез!.. Ха-ха-ха!.. Лапаты... не яблыкы... Егылып үләрсең!..

Гүя бар кешелек Днипер ярында бер көрәк хакына кулга-кул тотынышып бии иде. Шул чак теге маржа кызы да, каяндыр почмактан ягтырып, миңа көрәгемне китереп бирде. Аның исеме чынлап та Мария булып чыкты.

Төзелешкә китерелгән яшьләрнең шактый өлеше татар булганлыктан, әүвәлдән бар төзелеш гавамы колактан колакка капланып көлеште. Аннан бу котылгысыз көлеш бер даирәдән икенче, икенче даирәдән өченчегә таралып, офыкларга барып ишелде. Соңыннан аңлашылганча, мин яблыкыны ашый торган алма түгел, ә бәлки кагылма, алма, тимә мәгънәсендә файдалана алам дип уйлап, татар телендәге охшаш сүзләрне кулланып, грамматик ачыш ясаганмын икән. «Лапаты не яблыкы» шул заманда СССРда исән-сау яшәп яткан ике йөз илле милләтнең, халыкның, кабиләнең барысының да вәкилләре булган камсамул-яшьләр төзелешенең канатлы сүзенә, ә мин исә, һич теләмәсәм дә, аның сәбәпчесенә әйләнгән булып чыктым. Әлбәттә, әгәр дә туган якларыбызга кайткач, якташым Фазыл авылдашларга сөйләмәгән булса, бу кәмитне бүген беркем дә белмәс һәм мине кап-кара трахтыр киемемдә дә «Лапаты не яблыкы» дип йөртмәс иде...

Ир белән хатын кара төн уртасында үткән яшьлекләрен искә төшереп, тагын да бер тапкыр елмаештылар.

– Ятыйк инде... – диде хикмәтле Миңлебикә түшәккә башын салып. – Иртәгә бәйрәм түгел...

– Безнең өчен бәйрәм, – диде хикмәтле Биктимер хатынына караңгыда да күз кысып. – Без бит бәби көтәбез. Шулай бит, җаныкаем?

Һәм алар башларын башка тәңгәл китереп түшәккә аудылар.

Айдар ХӘЛИМ

Евразиядә татарлар...

Бу көннәрдә Казахстанның Семей-Җидепулат шәһәрендә милләт тарихы һәм татар тормышы белән бәйле гаять мөһим фәнни-мәдәни чаралар булып үтте – халыкара конференция һәм фестиваль, Татар сәнгать мәктәбенең яңа бинасын ачу, Иртыш буенда беренче халыкара Сабан туе... Шулар арасында «Иртыш буе татарлары: тарих һәм хәзерге заман», дип аталган халыкара фәнни-гамәли конференция аерата зур әһәмияткә ия. Бу конференция Казахстандагы һәм Себердәге татарларның татар һәм казах халыклары тарихына керткән өлешен барлау максатын куйган иде, ул аны өлешчә башкарып чыкты. Бу тема бик зур, киң колачлы, аны бер конференция кысаларында гына ачып бетерү мөмкин түгел. Шуңа күрә җыенның резолюциясенә «Казахстанда мондый фәнни конференцияләрне даими рәвештә уздырырга, бу теманы Евразия киңлекләре контекстында өйрәнергә», дигән тәкъдим кертелде. 2016 елны шушы ук Семей шәһәрендә «Евразия киңлекләрендә ислам динен таратуда татарларның роле» дип аталган фәнни конференция булган иде инде, анда да Татарстан галимнәре эзләнүләрне шушы юнәлештә дәвам итәргә киңәш иткән иде.

Ә инде «Иртыш буе татарлары: тарих һәм хәзерге заман», дип аталган җыенга килгәндә, анда Татарстан һәм Казахстаннан, Себердән галимнәр һәм төбәк тарихын өйрәнүчеләр катнашты. Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты галимнәре моннан берничә ел элек Семейда һәм ул тирәдәге татар авылларында булып, 2017 елда, «Милли-мәдәни мирасыбыз» сериясеннән «Казахстан татарлары. Семей» дип аталган җыентык чыгарган иде, конференциядә аның презентациясе булды. Институт галимнәре Илһам Гомәров һәм Азат Ахунов Семей татарларының кыскача тарихы, тел үзенчәлекләре, халык иҗаты, күренекле шәхесләре турында сөйләде. «Туган җир» журналы баш редакторы, тарих фәннәре докторы Дамир Исхаковның чыгышы тагын да борынгырак заманга – Иртыш буенда монголларга хәтле чорга һәм анда яшәгән төрки халыкларның этник тарихына багышланган иде. Язучы, тарих фәннәре кандидаты Фәүзия Бәйрәмова исә «Семей шәһәрендә Чыңгыз Айтматовның татар тамырлары» дигән темага чыгыш ясады, ул танылган язучының әбисе Газизәбануның шушы шәһәрдән булуын билгеләде, аның турында яңа һәм кызыклы мәгълүматлар җиткерде. Бөтендөнья татар конгрессының татар төбәкчеләре белән эшләү комитеты җитәкчесе, галим Альберт Борһанов Көнбатыш Казахстан, Себер һәм Иртыш буе төбәге тарихын өйрәнү, бу нисбәттән татар краеведлары алдында торган бурычларга тукталды. Семей татарларының рухи һәм мәгънәви лидеры, Семейда Татар сәнгать мәктәбе ачып, шуны 30 ел буе җитәкләгән, анда йөзләгән милли сәнгать белгече әзерләп чыгарган, «Иртыш моңнары» дип аталган татар җыр һәм бию ансамблен оештырган һәм аңа хәзер дә җитәкчелек иткән, дистәләгән халыкара фестивальләр уздырган Габделхак Ахунҗанов Семей татарларының тарихи-мәдәни мирасы турында сөйләде, анда эшмәкәрлек тә, мәгариф, дин, үзенчәлекле архитектура да чагылыш тапты. «Казан утлары» журналының баш редакторы Рөстәм Галиуллин казах әдәбияты классигы Абай Кунанбаевның бай иҗаты, әсәрләренең татар теленә тәрҗемәсе, татар-казах әдәбиятларының багланышы турында кызыклы чыгыш ясады.

Җирле краеведларның, Татарстан һәм Себердән килгән татар төбәк тарихын өйрәнүчеләрнең чыгышлары да бай мәгълүматлы булды. Динә Мөхәммәтхан (Алмата), Равилә Шәйдуллина (Казан), Кайрат Сабырбаев (Семей), Әнвәр Аширов (Новокузнецк, Кемерово өлкәсе), Гөлшат Сатышева (Тара, Омск өлкәсе), Гөлназ Самочкина (Пенза), Гөлшат Таштимерова (Тара), Әлфирә Декет (Тара), Зәлифә Рахмангулова (Омск), Рауза Максимова (Омск) һ.б. чыгышлары истә калырлык булды. Конференция икегә бүленеп эшләде, Татар сәнгать мәктәбенең 30 еллыгына багышланган секцияне Казахстан татарлары һәм башкортлары оешмасы рәисе Тәүфик Кәримов алып барды.

Галимнәрдә дә, төбәк тарихын өйрәнүчеләрдә дә үткәннәр белән кызыксыну зур. Семейның махсус өйрәнерлек зур тарихы да бар, һәм ул татарлар белән бәйле. Тарихчылар бу төбәктә татарларның Алтын Урда чорларыннан ук дәүләт тотып яшәүләрен яза, алар Евразиянең төп халкы була, ә Европа карталарында бу җирләр ул вакытларда ук «Татар даласы», дип күрсәтелгән. Миллер һәм Паллас кебек күренекле галимнәрнең язуынча, Җидепулат-Семипалатинск атамасы да «Таш мәчетләр», «Татар-Монгол йортлары» дигәнне аңлаткан. Семейга да татар сәүдәгәр-купецлары нигез салган, узган гасыр башында биредә 13 мәчет, 7 мәдрәсә эшләгән, мәчетләрнең уникесен, мәдрәсәләрнең барысын да татарлар тоткан. Сан ягыннан казахларны да уздырып, татарлар күпчелекне тәшкил иткән. Җидепулат каласы Җидесу (Семиречье) төбәгенең дин, мәгърифәт һәм сәүдә үзәге булган.

Узган гасырларда Семейда яшәгән бертуган Мусиннар үз исемнәрен шәһәр тарихына чын мәгънәсендә ташлар белән язганнар – биредә алар төзеп калдырган таш мәчетләр һәм йортлар һаман халыкка хезмәт итә, Садыйк Мусин салдырган пар тегермәне бинасы бүген завод ролен үти. Заманында Мусиннарның Иртыш елгасын тутырып пароходлары, баржалары йөзгән, алар биредә елга флотилиясенә нигез салган. Семейда ачык һавадагы музейны хәтерләткән Татар бистәсе бар, мондагы таш һәм карагай йортларга кимендә 150 ел, урамнарның берсе бертуган Мусиннар исемен йөртә. Кызганыч, Семейның татар тарихы хәзергә бик аз өйрәнелгән, шуңа күрә, мондый фәнни конференцияләр бик мөһим.

«Тарихи-мәдәни мирас» фондының матбугат үзәге.

АКВАРЕЛЬГӘ

Рәссам Илдар Сафин 1965 елда Әлмәттә туган. «Әти-әнием рәссамнар түгел, гади хезмәттә иде. Әтием Фоат югары разрядлы газ-электр белән эретеп ябыштыручы булды, әнием Гөлсинә – товаровед һөнәрен иярләде. Апам Гөлчәчәк рәсемнәрне бик яхшы ясый белсә дә, музыка өлкәсен сайлады, ул музыка укыта. Ә мин 4-5 яшемнән үк рәсем ясадым. Әтиемнең ир туганы машинасы килеп туктавы була, мин аның бар килеш-килбәтен кәгазь битенә күчерә башлыйм... Әти-әни әлеге сәләтемне үстерергә теләп, мине балалар сынлы сәнгать мәктәбенә бирде, – дип искә алды рәссам. – Сигезенче сыйныфтан соң Казан сынлы сәнгать училищесында укый башладым. 1984 елда аны тәмамлагач, Казан төзелеш-инженерлык институтына кердем, тик бу уку йортында укымаячагымны тиз аңладым. Бер елдан соң Ленинградтагы В.И.Мухина исемендәге Югары сәнәгать-сәнгать училищесы студенты идем инде. Анда интерьер проектлау белгечлегенә укыдым. Гыйлем туплау өчен гел китапханәбезгә йөрдем. Борынгы шәһәр дә, аның катлаулы архитектурасы да күңелемә хуш килде. Ленинград мине рәссам буларак та, шәхес буларак та формалаштырды. Анда матурлыкка сиземләрәк була бардым, холкым да шунда ныгыды. Каникулга кайткач, кичкырын портретлар ясадым, бу хезмәтем көндәлек чыгымнарны каплады».

Илдар студент чорында ук гаиләле булган. Ә бу 1990 еллар башы. «Тормышны алып бару өчен укудан соң калган буш вакытымда картиналар ясап сата башладым. Нигездә, акварель буяулар белән ясалганнарын... Гаҗәеп хәлләр дә килеп чыккалады. Әнием 1989 елда вафат булды... Ул миңа болай дип әйтә иде: «Улым, сәдака бирәсең килсә, урамдагы кошларны ашат». Әниемнең туган көне җитте, ул инде бер ел дөньяда юк иде... Сатарга куелган картиналарны дусларыма калдырып тордым да, ике зур ләвәш күтәреп, Грибоедов каналына төштем, күгәрченнәрне ашаттым. Бераздан янә сату урыныбызга килсәм... ни күрим, шул вакыт эчендә бар картиналарым да сатылып беткән, ә бит моңа кадәр алар ике ай буе сатылмаган иде...»

Югары уку йортыннан соң Илдар Сафин башта Санкт-Петербургта эшләп калган. Дуслары белән яңа картина галереясын ачкан. Алар анда үз әсәрләрен дә һәм студент рәссамнарның эшләрен дә саткан. Сәүдә барса да, бу – әлеге каладагы мохитнең куркынычрак була барган еллары. Галерея да үз вакыты белән ябылган. Каланың климаты сәламәтлеге өчен килешмәвен төшенгәч, рәссам гаиләсе белән Казанга кайткан. 1998 елда Татарстан Рәссамнар берлегенә кабул ителгән, күп кенә күргәзмәләрдә, шул исәптән 1986, 2014 елда төбәкара «Зур Идел» күргәзмәсендә дә катнашкан. Шәхси күргәзмәләрен дә теләп ачкан: 1995 елда – Казанда, 1996 елда – Түбән Камада, Чаллыда. 2005 елда Татарстан дәүләт сынлы сәнгать музеенда күргәзмәсе оештырыла. 2016 елда исә Татарстан Рәссамнар берлегенең 80 еллык юбилеена багышланган күмәк күргәзмәдә аның хезмәтләре дә экспозицияләнгән.

Илдар бу елларда Казан тамашачыларын берничә тапкыр куандырды: 2017 елда «Хәзинә» милли сәнгать галереясында «В атласной тапочке, на пробке» дип аталган шәхси күргәзмәсен ачты, ә 2019 елда шул ук галерея залларында Л.Толстойның тууына 190 ел тулу уңаеннан дәүләт сынлы сәнгать музее белән берлектә «Лев Толстой. Казан хронологиясе. 1841-1847 еллар» дип аталган күмәк проектны тормышка ашырды. Әлеге язучының Казанда укыган чоры сурәтләнгән берничә дистә әсәрен соңрак Татарстан Мәдәният министрлыгы музейлар өчен сатып та алды. Илдар 2016 елда, С.Насекин һәм А.Мещеряков белән берлектә, «ТР тарихи һәйкәлләрен һәм мәдәниятен торгызу фонды» заказын үтәп, иллюстрацияле календарь да нәшер итте.

Рәссам балет темасын күп еллар элек үк сайлап алган. Аның дус рәссамы Казан опера һәм балет театрында эшләгәнгә һәм балет артистлары арасында да дуслары булганга күрә, әлеге сәнгатьне ул якыннан белә. «Бу тема һәрчак янәшәмдә була килде, – дип сөйләде Илдар. – Балет сәнгате ул акварельгә хас җиңеллек, хисчәнлек, нәфислек белән авазлаш та бит әле». Әлеге сериягә оста Рудольф Нуриевның ике портретын да керткән, аларның беренчесендә – Р.Нуриев скрипкада уйный, бу сурәт – балет артисты катнашкан бер кинофильм күренешеннән. Ә икенчесендә биюче күнекмәләр ясау мәлендә тасвирланган. Әйе, Р.Нуриевның чиксез уңышлы да, фаҗигале дә язмышына Ги де Мопассан аңлатмасы аеруча туры килә шул: «Даһи – ул Парижда үләр өчен провинциядә туган кеше»...

«Киндерләргә майлы буяулар белән портретлар ясаган чорым да булды. Сәяси лидерларны, төрле шәхесләрне дисеңме, заказлар вакыты... Аннары пейзажлар да, натюрмортлар, хәтта абстракцияләр дә иҗат иттем. Әмма акварель буяулар белән иҗат һәрчак күңелем түрендә. Үземне югары профессионализмга ия рәссам дип саныйм, әгәр дә нинди дә булса әсәр бу көнне тиешенчә килеп чыкмый икән, димәк, иртәгә бу мәсьәләне барыбер хәл итәчәкмен. Оста бары үсештә булырга тиеш», – дип ассызыклады ул.

Рәссам, акварелист 2019 елда Акварелистларның Бөтендөнья ассоциациясенә дә кабул ителгән. Аның хезмәтләре Гонконг һәм Пакыстан дәүләтләрендә, пандемия чорында онлайн фор-

ГАШЫЙК РӘССАМ

матта узган зур халыкара күргәзмәләрдә дә катнашкан.

Рәссамның Истанбулда гомер итүче кызы Лия дә рәсемнәрне бик яхшы ясый. Илдардан иҗатчыга мөһим хисләр, истәлекләр туплау өчен кайларга сәфәр кылуын да сорашам. «Парижны, Праганы ошаттым, – дип җаваплый ул. – Таиландны да күрдем. Моннан 15 еллар элек Һиндстан ашрамнарында булдым, үзем өчен рухи азык җыйдым. Йога һәм медитация күнегүләренә төптән төшенәм. Бу белемнәр үземне яхшырак аңларга, күңел төшенкелегенә бирешмәскә булышлык итте. Казанга әйләнеп кайткач, күпмедер вакыт шушы гыйлемнәремне башкаларга да җиткердем. Дөнья шулхәтле ямьле, шулхәтле матур булса да, кешегә шушы якты Җирдә гомер итү бүләккә бирелсә дә, кайберәүләрнең моның өчен сәламәтлекләре җитми, аларның күңеле тынычлык таба алмый, үзләре белән канәгать булмаучылар күп. Бу – гомуми гыйлем җитмәүдән. Кешеләр бәхетне тышкы факторлар аша эзли, ә аны үз җанын төгәл баланска китергәч кенә таба. Тормыш сынауларсыз бармый, әмма алар кешенең теләкләрен истә тотып та бирелә, баш миендә туган һәрбер уйга бары тик хуҗа була белергә кирәк. Уйларны тәртипкә салырга, ә тискәреләрен үзеңә хуҗа итмәскә. Бәхет – ул кешенең үз эчендә. Ул үз-үзең белән гармониядә булу. Моны аңлаганнарның гына йөзендә һәрчак елмаю балкый... Сәяхәтләр исә илһам өстәү өчен кирәк, билгеле. Әмма рәссамның уңышы – практикада, ул һәр көн даими рәвештә рәсем ясауда, тагын да яхшырак нәтиҗәләргә ирешкәнче иҗат итүдә булырга тиеш. Үз хыялларыңа тугры калу, Аллаһы Тәгаләнең сиңа тапшырылган йөкләмәсен үтәп чыгу да – чын рәссамлык».

И.Сафинның тагын бер үзенчәлекле акварель сериясе мактауга лаек. Аны рәссам ярты ел эчендә иҗат иткән, ул Казан тамашачылары, Татарстан кунаклары күңелендә быел «Дом ART» музей-галереясында ачылган «Минем кинематограф» шәхси күргәзмәсе аша истә калды. «Сынлы сәнгатьтә минем өчен алынмас биеклекләр, текә үрләр юктыр. Техникаларны беләм, камилләштерәм. Яраткан техникама өстенлек биреп, акварель сурәтләрне даими ясыйм. Мин – гомерем буе ирекле рәссам. Чын әсәрләр арзан тормый. Алар бит тупланма хуҗалары өчен генә кадерле... Менә әлеге серия хакында мондый аңлатма бирә алам: һәркем гомере буе нинди дә булса кинофильмнар карый, мин дә карыйм һәм алардагы кайбер мизгелләр аңыма озакка сеңеп кала. Кино сәнгатенә багышланган акварель әсәрләрем «Крёстный отец» фильмыннан башланды, аннары башка шедевр киноәсәрләргә дә тукталдым. Гомумән, кино минем өчен тормыш аналогиясенә тиң. Кино, безнең тормышыбыз кебек үк, башланып китә, дәвам итә һәм тәмамлана. Без киноны тәэсирләнеп карыйбыз, хәтердә дә калдырабыз. Кеше рухы, җаны да күккә ашканда, нәкъ экранга карагандай, барысын да күзәтә булыр... Энергия бит каядыр китә, әмма бөтенләйгә юкка чыкмый, ул трансформацияләнә генә. Һәр кешенең бер өлеше, җаны, рухы Галәмдә кала. Бу инде фән аша да расланды. Минем өчен кино менә шундый өстәмә аналогия булып тора, – ди иҗатчы. – Ничек ясыйм? Әйтик, фильмдагы сюжет сүтелә бара һәм бер мәлдәге кадр аеруча җәлеп итә һәм ул, гадәттә, төп сюжет линиясе, төп персонажларның гамәлләре белән бәйле дә түгел. Ул - шушы фильмда тасвирланган вакытны, нәкъ шушы чор мохитен, шул гасыр атмосферасын сурәтләп бирүемә килеп тоташачак мәл. Гасыр атмосферасын сурәтләп аны үз тамашачыларыма җиткерү идеясе белән бәйле булган теләк. Чагыштыру өчен: әйтик, берәр көй яңгырый, без аны көй арасындагы туктап торулар, тынлык белән бергә, тулаем кабул итәбез. Шул тынлык та безнең өчен бик мөһим... Бу да кинодагы шундый мәлләр хакына туган сериям. Мин тормыш тулылыгы булган, уйланырга мәҗбүр итүче драма, триллер жанрындагы фильмнарны сайладым. Әйе, көлкеле комедияләрне дә карыйлар, рәхәтләнеп көләләр дә, әмма алар тиз онытыла. Игътибарымны фильмда күрсәтелгән табигать күренешенә яисә шәһәр пейзажына яки төп сюжетка кагылышы булмаган кала кешеләренә юнәлттем. Камил балансta яшәргә өйрәнгән иҗатчы буларак, шушы шартлы рәвештә әйткән тынлыкларны кинофильмнар барышында, аларны беренче тапкыр караганда ук үз аңыма кертеп кала идем инде... Аларның кайберләрендә чагылдырылган хисләр яшьлегемдәге хисләрем белән дә тәңгәл, алар бүген дә якын. Әмма мин сайлаган кинокадр төсләр купшылыгында булмаска, монохром булырга мөмкин әле».

– Илдар, сез әлеге сериягездәге чибәркәйләр арасына Мерлин Монроны да керткәнсез. Аны су ерып баручы зат итеп сурәтләгәнсез. Ул рәссамнар өчен бары тик матурлык символы гынамы?

– Монро – үзенең белем дәрәҗәсен арттырырга, яхшы рольләр уйнарга омтылган ханым, тик ул, башкалар ия булмаган матурлык белән мактана алса да, төс-бите җетелеге җуелганчы юкка чыккан трагик язмышка ия...

Яңа экспозицияләргә килгәндә, быел 1 октябрьдә Мәскәүдә ачылачак «Бер сулышта» дип аталган Бөтенроссия рәссам-акварелистлар конкурсы өчен дә Илдарның бер әсәре сайлап алынган. Шунысы да бар: дөньякүләм танылган Россия рәссам-акварелистларыннан тупланган, составына Мәскәүнең баш архитекторы да кергән эксперт советы Россиянең бар төбәкләреннән килгән 800 эштән нибары 180 картинаны гына конкурс кысаларына туры килерлек дип тапкан. Бу нисбәттән, талант иясен дәвамлы уңышы белән янә тәбриклисе килә!

Зилә НИГЪМӘТУЛЛИНА.

ГИМН –

«Мәдәни җомга»ның 36 нчы санында басылган «Фәкать милләткә хезмәткә...» язмасында укучыларыбыз Фәһим Җиһаншинның татар телен саклауга керткән хезмәтләре белән танышкан иде. Бу санда укучылар Фәһим Һади улының өч дистә ел буе шөгыльләнгән тагын бер хоббие белән таныша ала. Ул дөньядагы дәүләт һәм милләт гимннарын татар теленә тәрҗемә итү белән дә мавыга.

Зилә НИГЪМӘТУЛЛИНА.

– Совет заманында, «тимер чаршау» артында чит ил символларын өйрәнү мөмкинлекләре бөтенләй булмады. Ул вакытта төрле чыганаклар аша бары тик ике Алмания (ГДР һәм ГФР) гимннарын һәм «Интернационал»ның татар теленә тәрҗемәсен генә беләидем. Коммунистлар гимнын өч олы әдибебез (Нәкый Исәнбәт, Әхмәт Исхак, Нури Арсланов) татар теленә күчергән, ул ярты гасыр элек басылган җыр китапларында бар. Моннан тыш, «Марсельеза»ның (Франция гимнының), АКШ һәм Кытай гимннарының көйләрен радио аша танып белә идем.

Беренче этәргеч – Татарстан гимны

– Гимннарны ныклап өйрәнү теләге 1993 елда, Татарстан гимны кабул ителгәч туды. Рамазан Байтимеревнең «Туган ягым» шигыре белән рухланып, Рөстәм Яхин язган мәңгелек көйне тагын бер бөек татар сәнгатьчесе Фуат Мансуров идеаль рәвештә гимн музыкасы итеп эшкәрткән. Сәяси сәбәпләр һәм сылтаулар аркасында, бу гимнның озак еллар буе сүзсез калачагы аңлашыла иде. Ләкин күңел моны кабул итмәде: «Бу илаһи гимнга шәхси кулланыш өчен булса да текст язам!» дип сүз бирдем үземә.

Беренче талпынышта ук моның шактый авыр эш булуы ачыкланды. Бер шигырь артыннан икенчесе чүплеккә китеп барды, берсе дә «күңел гимны» түгел иде. Башта бу жанрдагы дөнья мирасын өйрәнергә кирәк икән. Кулга интернет килеп кергәч, җиң сызганып эшкә керештем: дөнья гимннарын татар теленә тәрҗемә итә башладым. Сәяси вәзгыять нинди генә булмасын һәм ул күпмегә генә сузылмасын, баштан ук бәйсез дәүләт гимны тексты иҗат ителергә, ул бөтен Татарстан һәм татар халкына да хезмәт итәргә тиеш, дигән таләп үтәлүен шарт итеп куйдым. Унбер ел үтеп, кырыклап гимн өйрәнелгәч, 2004 елда, бер хезмәттәшем әйтмешли, «икенче сортлы, ләкин брак булмаган» шигырь туды:

КҮҢЕЛ ГИМНЫ
Офыкларың нурлы, газиз Ватан,
Имин булсын юлың, Татарстан!
Язмыш йолдызыбыз – аяз күктә,
Олы кодрәт иңде Гарештән:
Күтәрелде туган җиребездә
Ил-Анабыз яме – Татарстан,
Ата-баба мирас-әманәте,
Ил-көнебез гаме – Татарстан!
Хак гамәлне пакьли изге ният,
Гамәл күркәмлеге – халыктан;
Бердәмлектә терәк, саф Хөррият –
Синдә тормыш тәме, Татарстан,
Саф Хөррият рухы – ил күңелендә,
Байрак төсләреңдә, Татарстан!
Кулга – кул, йөрәккә йөрәк кушып,
Ил-йортыбыз яулый хөрмәт-дан.
Бәхет кояшыннан илһам алып,
Чәчәк ат, сөекле Татарстан!
Туры юлда адым – җан рәхәте,
Имин бул син мәңге, Татарстан!

Өстәмә стимуллар

– Бу шигырь минем шәхси кулланышта 2013 елга кадәр, Дәүләт Шурасы Гэрәй Рәхим язган шигырьне рәсмиләштергәнче булды. Хәер, мин аларны беркемнән дә яшереп тотмадым да. Дус-ишләр, хезмәттәшләр арасында төрле фикерләр булды, барысына да колак салып бардым, текстны берничә мәртәбә төзәткәләп тә алдым. Хәтерлим, берәү мине, «офык, йолдыз, кояш» сүзләрен кулланган өчен... тәңречелектә һәм зәрдөштлектә (зороастризмда) гаепләгән иде. Бәхәсләшеп тормадым: «Менә сиңа Иран Ислам Җөмһүрияте гимнының тәрҗемәсе, анда да шул ук «мәҗүси тайпылыш», – дидем. Бу «кимчелек» дөньяның тагын берничә гимнында бар. Үзәк Америка илләренең испан телле илләре гимннары өчен «el cielo» (күк, күк йөзе), «el sol» (кояш), «el suelo» (җир, туфрак) кебек җиңел рифмалашучы сүзләр бөтенләй диярлек мәҗбүри булып киткән. Аннары, дини гимннар да бар, ләкин гимн жанры, тулаем алганда, теге яки бу дин кысаларына гына сыешып бетми.

Шәхси рухи ихтыяҗның канәгатьләнделәүге гимннар һәвәслегенә киртә булмады. Киресенчә, татарча да җырланырлык итеп тәрҗемә кылынган гимннар санын йөзгә тутыру бурычын куйдым. Моның өчен шактый катлаулы «тәрҗемә итү технологиясен» үзләштерергә кирәк булды. Ялкаулар эше түгел бу. Иң мөһиме – төрле чыганакларны сүзлекләр тотып өйрәнеп, теге яки бу телдәге фикерләү рәвешенә төшенү. Калганын «татарга тылмач кирәкми» дигән хакыйкать хәл итә.

Бу темага саллы диссертацияләр дә язып булыр иде. Ләкин мондый хәсрәт мине борчымый, чөнки фәкыйрегезгә, университетлар тәмамлап, катыргы кәгазьләр артына ышыклану насыйп булмады. Шулай да, гимннар буенча «чимал» әзерләп куюның гаебен күрмим. Әгәр дә без дөнья халыкларының алгы сафында булырга телибез икән, димәк, иң беренче чиратта без бу дөньяны һәрьяклап өйрәнергә, үзебезгә аңларга һәм аңа үзебезне, үз кыйблабызны, халәтебезне, рухи ихтыяҗларыбызны, хыялларыбызны да аңлатырга тиешбез. Аннары, «Нәрсәгә кирәк соң бу?» дигән сорау куеп, ниндидер эштән баш тартасы булсаң, ул эшне үзгә берәү башкарачак, һәм инде синең өчен түгел – үз файдасына. Ни өчен Фоат Уразай язучыларны «дөнья тотучылар» дип мактый. Чөнки алар күп нәрсә белән кызыксына. Әйтик, 1960 елларда формаль бәйсезлек алган Африка илләренең күбесенә гимннарны кем «бүләк итте»? Нәкъ шулар! Нәтиҗәдә «кара кыйтга»да африкача милли дип саналырлык ике-өч гимн бар хәзер. Калганнарыннан «Европа исе» аңкып тора.

Тәкъдир үзгәрешсез, ләкин юллары бихисап

– Гимн язу – озак мөддәтле язмыш сайлауның кеше өлешенә кергән бер гамәле ул. Тәкъдир китабында тормыш юлларының халиткеч һәм контроль тукталышлары гына билгеләнгән. Аларны читләтеп үтеп булмый, ләкин бер пункттан икенчесенә үзең сайлаган сукмактан барасың. Украина мисалында бу бик аермачык күренеп тора. Украина дәүләт гимнының башлангыч тексты 150 еллар элек, Европаны «миллиләштерү» сөреше Россия империясенә килеп җиткәч, барлыкка килгән. Бүген аның беренче куплеты гына гамәлдә, ләкин калган икесе дә ил һәм халык тормышына йогынты ясаудан туктамады. Башлангыч текстның икенче куплетында, әйтик, «Станем, браття, в бій кривавий від Сяну до Дону» дигән сүзләр бар.



1. Бар әле Украинаның ихтыяры һәм даны,

куплеты – ил тарихына, калган юллары – ил терәге һәм кыйбласы дип саналган башка, һәм дөньяви, һәм рухи нигезләргә.

1. Әйт әле, күрәмсең алсу таң атканда, –
Без аны данладык кич кояш батканда?
Зәңгәр күк, йолдызлар – ак-кызыл иңендә, –
Җилфердиме ул байрак кирмәннәр түрендә?
Ракеталар янды, бомбалар шартлады, –
Ә байрак төн буе безнең сафта калды.
Әйт әле, балкыймы ул байрак бүген дә –
Кыюлар җирендә, азатлар илендә?
2. Тәкәбберләр, посып куе томаннарга,
Дөм-караңгылыкта яткан текә ярда –
Капылт җил байрактан куркуны басармы,
Әллә бер яшереп, яңадан ачармы?
Горур балкый анда, шәфәкъ нурларында,
Сурәте чагыла агымсу-алкында, –
Йолдызлы байрак ул, җилфердәсен көн дә
Кыюлар җирендә, азатлар илендә.
3. Кайда соң киберле ант эчкән өерләр? –
Юкка чыкты алар, тар-мар ителделәр,
Канлы эзләрен дә каплый кара туфрак...
Һәм Ил-Ватан безгә гомерлеккә уртак!
Урын юк сыенырга ялчыга һәм колга –

Язмыш ярлыкар әле без украин туганнарны.
Кояш нуры төшкән чыктай, юк булырлар дошманнар,
Туган ягыбызда без дә булырбыз әле паннар.
Азатлыгыбыз хакына булсын җан һәм тән фида,
Көч-куәтне күрсәтербез казак нәселе рухында.

Украина гимнының яңа, хәрби хәрәкәтләр тәмамлангач кабул ителү ихтималы булган тексты да бар. Аны Днепр шәһәре шагыйрәсе Ольга Рекун тәкъдим итте.

Европа кыйммәтләре

– Бу кыйммәтләр, башлыча матдияткә генә кагыла торган булса да, илаһи рухта һәм кешелеклелек калыбында кулланылган очракта, тел-теш тидергесез булыр иде. Фоат Уразай, аларны Урталык җирләренең рухи кыйммәтләре белән баетырга кирәк дип, ике язмасының берсендә һәм хаклы рәвештә фикер иңдереп тора.

АЛМАНИЯ ГИМНЫ
Алманнар җыры
Бердәмлек, Хокук, Хөррият
Алман җирендә хаким.
Изге туганлык хисләрен
Йөртсен күңелендә һәркем.
Бердәмлек, Хокук, Хөррият –
Безнең бәхет солтаны.
Шул бәхеттә чәчәк атсын
Мәңге Алман Ватаны!

АКШ ДӘҮЛӘТ ГИМНЫ

АКШ гимнында уртак кыйммәтләр тагын да тәфсилләбрәк аңлатылган. Беренче куплет һәм һәр куплетның соңгы ике юлы дәүләт байрагына багышланган, тагын бер ярым

Куркып качса качсын кабер шомлыгына.
Йолдызлы байрак ул – дан-шөһрәт иңендә,
Кыюлар җирендә, азатлар илендә!
4. Азатлар барында мәңге шулай булсын.
Сөекле йортыбыз сугыштан арынсын:
Мәдхия – юнәлтеп җиңүле солыхка,
Милләт итеп безне, ярлыкаучы Хакка.
Уңышка омтылыш, гамәлдә ышаныч,
Безнең шигаребез: «Аллага таяныч».
Буй-буй байрак балкыр ул – дан-шөһрәт иңендә,
Кыюлар җирендә, азатлар илендә!

Тугандашлар кыйбласы

– Казахстан, Үзбәкстан һәм Әзәрбайҗан гимннары – төрки илләр төркемендә күңелемә хуш килгән дәүләт символлары. Күптөрлелек туганнар гаиләсенә дә хас. Һәм бу – табигый күренеш. Мин аларны бер үк максатка өч яктан килеп ирешү теләге һәм стратегиясе дип кабул итәм. Кыргызстан, Каракалпакстан, Төркия гимннары да шундый ук. Биредә беренчесе җанга тынычлык һәм тыйнак горурлык иңдерә, икенчесе ватанпәрвәрлеге белән йөрәккә үтеп керә, өченчесе лаеклы киләчәк хакына көрәшкә чакыра:

КАЗАХСТАН ГИМНЫ
1. Алтын көн асманы,
Мул ашлык даласы,
Батырлык дастаны –
Илемә карачы!
Куптәннән ир дигән
Данлыбыз кодрәте,
Намусын бирмәгән
Казагым куәте!
Кушымтасы:
Минем илем, минем илем,
Гөлең булып сибеләмен,
Җырың булып түгеләмен, илем!
Туган җирем минем –
Казакъстаным!

2. Киләчәккә юл ачкан,
Чиксез киң җирем бар.
Берлеге ярашкан
Ирекле илем бар.
Каршы алган вакытны
Мәңгелек дустыдай,
Безнең ил – бәхетле,
Безнең ил – шушындый!
Кушымтасы.

ҮЗБӘКСТАН ГИМНЫ

1. Кояшлы хөр илем,
сиңа бәхет,нәҗат,*
Син үзең дусларга
юлдаш, миһербан,
миһербан!
Гөрләп үссен мәңге
гыйлем, фән, иҗат,
Шөһрәтең нурлансын,
яктырсын җиһан!
Кушымтасы:
Алтын бу үзәннәр – җан Үзбәкстан,
Бабалар мәрданы – мирасың синең!*
Бөеклек кодрәте ирешкән заман,
Галәмне сокландырган газиз илем!
2. Ихласлы үзбәкнең үлемсез иманы,
Ирекле яшь буын – сиңа зур канат,
зур канат!
Бәйсезлек мәшгале саклар дөньяны,*
Намуслы ана йорт, мәңге чәчәк ат!
Кушымтасы.

УДМУРТ ҖӨМҺҮРИЯТЕ ГИМНЫ

1. Кояш нурлый миләш
тәлгәшләрен,
Җир-суны назлый ил
таңы,
Рух тергә – җилферди
Байрагың,
Дан сиңа, дан, Ватаным!
Кушымтасы:
Ярлыка, Бөек Аллабыз,
Нурга күм офыкларны,
Насыйп ит бәхет, азатлык,
Куәтлә канатларны!
2. Юк синең күк сөйкемле дөньяда,
Төкәнмәс егәр-дәрманың,
Сине мактап каңгылдый торналар,
Дан сиңа, дан, Ватаным!
Кушымтасы.
3. Туендыра Чулман-Иделләрен
Саф сулы елгаң һәм чишмәң.
Уртак синең шатлык, кайгы, гамең
Ил белән, Удмуртиям!
Кушымтасы.

ЧУАШ ҖӨМҺҮРИЯТЕ ГИМНЫ

1. Язгы дөнья уянган
чак,
Һәвәс көннәр җылынган
чак,
Җан сөенә, йөрәк
җилкенә,

җәй көне үткәрелә торган Tour de France велосипед ярышларын «Евроспорт» каналы аша караганда күреп тора. Ел саен Kilometroak (Чакрымнар) дип аталган хәрәкәттә меңләгән баск кешесе катнаша. Трассаның һәр чакрымында плакатлар һәм транспарантлар күтәреп торалар.



Күтәрел, Баск Иле!
Күтәрел син, әй, Баск Иле,
мактау-дан бөек
Кодрәт иясе Аллага!
Бискайяда, яр буенда,
изге Синдо күле ярында
имән – борынгы, нык.
Бу имәндә, нурлар сибеп,
изге хач балкый –
өметебез символы.
Җырлыйк «Күтәрел, Баск Иле» дип,
мактау һәм дан
кодрәт иясе Аллага!

Төбәк парламентындагы «Мадрид партиясе» бу гимнга, «артык дини» дип, тәнкыйть уты яудыра. Әмма эш аны тыюга кадәр барып җитә алмый, чөнки баскларның шундый ук куәтле һәм инде «дини тайпылышы» чамалы гына булган тагын бер милли гимны бар – «Герника агачы». Герника агачы – күп гасыр дәвамында диңгез буенда үскән имән. Хәзер ул шәһәр эчендә калган. «Ана агач» корый башласа, аның урынына «баласын»

үсемлекнең татарча атамасы – шайтан таягы. Бу символга безнең киләчәк өчен дә гыйбрәтле булган мәгънә салынган. Тау-таш арасында да гөрләп үсә торган «таяк»ның чәнечкеле сабагы һәм гүзәл чәчәге бу халыкның һәм илнең теләсә нинди шартларда да исән калачагын һәм үз максатларына ирешәчәген гәүдәләндерә. «Шотланд» дип яз, «татар»дип укы.

1. Шотланд Чәчәге,
кайчан кабат
күрербез илнең,
җан фида кылып,
Эдвардны җиңгән
Һилл-Глен кебек
булганын?
Баскынны ул куып
кире кайтарган, –
уйлансын дип.
2. Бу калкулыклар
шыр ялангач,
яфрак коела,
кайчандыр көзен
Эдвардны җиңеп,
югалган ил өстенә.
Баскынны ул куып
кире кайтарган, –
уйлансын дип.
3. Ул көннәр – күптән

ЯЗМЫШНЫ САЙЛАУ

**Нәҗат – котылу, бу сүз Тукай иҗатында бар.*
**Мәрдан – ир-егетлек.*
**Мәшгаль – сигнал учагы яки уты, факел.*

ӘЗӘРБАЙҖАН ГИМНЫ

Кыска вариантта урта өлешен төшереп калдыралар.

Әзәрбайҗан!
Әзәрбайҗан!
Әй, батыр улларыңа
данлы Ватан!
Синең өчен җан бирергә җөмлә
әзер без!
Синең өчен кан түгәргә җөмлә
кадир без!
Өч төс байрак астында имин яшә!
Җирең хәрби мәйдан булды,
Меңләгәннәр корбан булды!
Синең хаклыгыңны яклап,
Барчасы каһарман булды!
Син булсын дип гөлстан,
Сиңа һәрбер җан корбан!
Мең бер мәхәббәт, Ватан,
Йөрәктә тотам мәкян!
Намусыңны керләмәскә,
Байрагыңны кимсетмәскә
Барча яшьләр җан аткан!
Шанлы Ватан! Шанлы Ватан!
Әзәрбайҗан! Әзәрбайҗан!

Күршеләр: бергә җырлыйк!

– Төрле тарафтан Татарстан һәм татарлар белән кулга-кул тотынышкан төбәкләр һәм халыклар «үзеңне үзең үзгәртеп кору» чорында үзләренә нинди юнәлешләр сайлады соң? Мисал өчен, Удмуртиянең һәм Чуашстанның музыкаль символлары. Беренчесе – аталы-уллы Корепановларның «суверенитетлар парады» елларындагы иҗат җимеше. Икенчесе – тәүге кат 1944 елда театр спектаклендә җырланган һәм шуннан соң халык җыры булып киткән әсәр.

Ил турында җырлыйсы килә.
Кушымтасы:
Туган җирем, туган җирем,
Сөйгән илем, изге Анам.
Туган җирем, туган җирем,
Мактау сиңа, дан сиңа, дан!
2. Яшь-җилкенчәк уйный-көлә,
Ата-ана үгет бирә,
Җан сөенә, йөрәк җилкенә,
Әле озак яшисе килә.
Кушымтасы.
3. Туган-кардәш берләшкән чак,
Чуашлар күмәкләшкән чак,
Җан сөенә, йөрәк җилкенә,
Эшчән-уңган буласы килә.
Кушымтасы.

Тиңдәшләр-юлдашлар...

– Безнең өчен гаять әһәмиятле һәм гыйбрәт иңдерерлек бу төркемгә, үз дәүләтчелегенә теләге, ихтыяры һәм хокукы булып та, әлегә башка дәүләтләр карамагында калган төбәкләр һәм халыклар гимннары керә. Төрле тарафларны һәм якын килүләрне күрсәтү өчен, Басклар Иле, Шотландия һәм Румыния составындагы, әмма башлыча мажарлар яшәүче Әрдей (Трансильвания) гимннарын сайлап алдым. Берсе дә рәсмиләштерелмәгән, әмма барлык рәсми һәм рәсми булмаган чараларда башкарыла.

БАСКЛАР ИЛЕ ГИМНЫ

– Басклар иле – Испаниядә диктатор Франко заманында коточкыч изелүгә дучар булган төбәк. Forvo сайты кулланучылары әйтүенчә, элек хәтта кешене урамда баск телендә сөйләшкән өчен дә үтереп ташлау очраклары булган. Бүген баскларның хәләте бермә-бер яхшырды. Милли телдә белем алу мөмкинлеге бар. Әмма басклар яшәгән дүрт провинциянең берсе генә автономиягә ия. Франциядә гомер итүче баскларның хәле элеккечә аяныч. Әмма милләт ихтыяры сынмаган, көрәш дәвам итә. Бөтен дөнья моны күчерәләр. Соңгы буын имәнен 2012 елда утырттылар, Басклар Иленең яңа сайланган хакимнәре, үз вазифаларына керешер алдыннан, бу имән каршына басып, баск телендә ант итә: «Аллаһы Тәгалә хозурында һәм җәмгыять алдында, баск туфрагына баскан килеш, Герника имәне астында ата-бабалар истәлегенә багышлап, халык вәкиле буларак үз вазифаларымны намус белән үтәячәкмен дип ант итәм».

ГЕРНИКА АГАЧЫ

1. Әй, бәхет китерүче Герника агачы,
Баск Иле кешеләре сине бик ярата.
Җимешләреңне бөтен дөньяга
таратчы,
Халык сине кадерли, изге дип җан ата.
Хак Тәгалә сине, диләр, мең еллар элек
Герника туфрагында үсмәккә
бар кылган.
Төз басып тор бүген дә, имән,
үс кинәнеп,
Син авып китсәң, халкың килер
пыран-заран.
2. Син аумассың, кадерле милләт
имәнебез,
Бискайя хакимнәре үзен дөрес тотса.
Дүрт провинция – бер ил булып
берләшербез,
Басклар кавеме яшәр имин
тынычлыкта.
Әйдәгез, барыбыз да сорыйк
Тәңребездән:
Герника агачыбыз – ул яшәсен мәңге.
Сорыйк ихлас күңелдән, баш иеп
йөзтүбән,
Итәр Алла мәңгелек милләтне, имәнне.

ШОТЛАНДИЯ ЧӘЧӘГЕ

«Flower of Scotland» җырында үткән заманнарның истәлекле тарихи вакыйгасы – 1314 елда шотландиялеләрнең инглиз илбасарларын тар-мар итүе чагылыш тапкан.

Шотландия чәчәге дип аталган милли

үткән заман,
без әле кабат
күтәрелә алабыз –
Эдвардны җиңгән
шул кыю милләт булып.
Баскынны ул куып
кире кайтарган, –
уйлансын дип.

ӘРДЕЙ (ТРАНСИЛЬВАНИЯ) ГИМНЫ



1. Язмышлар безне
йөртми кайда гына
Караңгы төндә,
сикәлтә юлда.
Чаба шаһзадә, кайт
кабат халкыңа,
Алып бар аны җиңүгә, уңга.
Кушымтасы:
Ялгыз кыя күк, сикәй басып тора
Халыклар явы барган диңгездә,
Кат-кат калды ул дулкыннар астында;
Яшәү насыйп ит, Ходай, Әрдейгә!
2. Мәҗар телле кавемнәр арасында
Мәңге сынмас безнең көч-рухыбыз,
Дөньяның кайсы җирендә тусак та,
Нинди булса да юл-язмышыбыз.
Кушымтасы.

Көрәш гимннары

– Бу төркемгә керә торган гимннарны гадәттә дөньяның «кайнар нокталары» булган илләрендә һәм төбәкләрендә эзләп табасың. Четерекле теманы ача башлау өчен, Сүриянең, Әфганстанның һәм Үзәк Африка Җөмһүриятенең бүгенге музыкаль символларын тәкъдим итәм. Соңгы ике мең елда нибары ике йөз ел гына тынычлык шартларында яшәгән Вьетнам да үзенең 1945 елда кабул ителгән үтә сугышчан хәрби гимныннан баш тартмый.

Дүрт көрәш гимны – аермалары җир белән күк арасы кебек булган дүрт кыйбла...

(Ахыры киләсе санда).

Фәһим ҖИҺАНШИН.

Керим әле музейларга

Сарапул татар автономиясе җитәкчесе, эшкуар, гармунчы-җырчы, татар халкының тарихына багышланган музей булдыручы... Сарапул шәһәрендә яшәүче милләтпәрвәр шәхес Зөлфәт Арсланов турында бихисап санап китәргә була.

Зөлфәт Арсланов үз көче белән оештырган «Барс» сәүдә үзәгендә урнашкан музейга килеп керү белән күз бөтен стенаны биләп алган авыл фонына төшә. Әнә зәңгәр күк астында – Зөлфәт әфәнденең Татарстанның Актаныш районы Түбән Карач авылында туып-үскән йорты. Бераз түбәнрәк – җиккән ат (агачтан ясалган), арбада әби белән бабай, сандыклар. Янда гына матур кое.

Бераз атласак, татар йортына керәбез. Акшарлаган ап-ак мичтә, учак ялкынында, чуен чүлмәктә нәрсәдер пешә кебек тоела. Әнә кечкенә Зөлфәт гармунда уйнарга өйрәнә. Киләчәктә шәп кенә җырчы-гармунчы буласын әле беркем дә белми. Тагы да стенага күз салсак, пионер, комсомол булган чаклар искә төшә. Яңа Кормаш, Суыксу авыл мәктәбенә йөреп укыган чакларын күзаллый бу атрибутлар.

Музей экспонатларын күптәннән җыя башлый Зөлфәт әфәнде. Ул чакта әле музей ачу турында уйламый да. «Кайда гына барсам да, булсам да, кызыксынып, элекке әйберләрне җыям. Авылларга кайткач та, һәрнәрсәгә игътибар итәм. Кайчакта өлкәннәргә: «Ник сакламадыгыз борынгы әйберләрне, үзегездән соңгы буынга нәрсә калдырасыз?» – дип әйтеп куям.

Бүген биредә меңнән артык экспонат бар. Экскурсияләр, остаханәләр оештырабыз. Музейны оештырырга туганнарым, дусларым, Сарапул шәһәрендәге милләттәшләребез ярдәм итте. Сандыкларда кадерләп сакланган яки ваемсызлыкка очрап, чәчелеп-аунап яткан ядкярләрне эзләп табып, кире халыкка кайтарган, тарихыбызны барлап, милли хәтеребезне яңарткан хәлдә генә без милләт булып сакланып кала алабыз», – диде Зөлфәт әфәнде.

Күп кенә экспонатлар әби-бабаларыннан калган. Аеруча йон тетә торган җайланма турында бик яратып сөйли ул. Аның белән бабасының эшләгәнен үзе күреп үскәч, аның серләрен дә белә, кунакларга аның белән эшләп тә күрсәтә.

Музейда Сарапул шәһәре татарлары, Ислам дине тарихы, Сарапул шәһәренең Татар иҗтимагый үзәген җитәкләгән Нәҗип Камал, аның кызы, популяр җырчы Зөлфия Камалова, Сарапул шәһәре халык драма театры җитәкчесе Рәшит Йосыфҗанов, Сарапул татарларының соңгы еллардагы эшчәнлеге, күренекле язучы, күп еллар Сарапул шәһәрендә яшәгән Ягъсуф Шәфыйков, Ижау шәһәре гармунчысы Фоат Кәримов турындагы стендлар белән танышырга була.

«Әлбәттә, сәүдә итү, дөнья артыннан куу берәр кайчан тукталырга, юкка чыгарга мөмкин. Ә менә мондый музейлар әле бик күп еллар халкыбызга хезмәт итеп, оныкларыбызга мирас булып калачак», – диде ул.

Рәфилә РӘСҮЛЕВА.

Рәхмәт сиңа,

2006 елның октябрь башлары иде. Өйдә телефон шалтырады.

– Алло?

Җавапка бик еракта пышылдап кемдер нәрсәдер әйтте.

– Кем бу? Кем?

– Бу мин, Мөдәррис, Казаннан.

Дуслар шаяртмалар, дип уйлыйм.

– Нәрсә булды, Мөдәррис, кычкырыбрак сөйлә, начар ишетелә.

– Кычкыра алмыйм, Халисә, тавыш юк.

– Суык тидеме, әллә ангинамы? – дим, үзем шул "зәхмәт"тән еш җәфаланганга.

– Авырыйм, ангина түгел, хәтәррәге...

Авыр тынлык урнашты. Бу инде шаяртуга охшамаган иде.

– Тыңла, шигырь укыйм, соңгы язган ике шигырь.

Мөдәррис телефон аша пышылдап кына шигырь укый. Начар ишетелә. Берсен, икенчесен... Хатын-кыз фамилиясе... Кудашева дигән фамилияне аңлыйм. Шигырь тыңлаудан бигрәк Мөдәрриснең хәле баш миен өтә. Мең төрле уй, чыннан да бу шаяртуга тартмый.

– Халисә, күрешеп сөйләшәсе килә. Кил әле Казанга, минем хәл шәптән түгел, – ди.

– Мөдәррис, дәваханәгә бар, дәвалан, медицина көчле хәзер.

– Соң инде, дәваланып булмас.

– Операция ясат, ничаклы иртәрәк эшләтсәң, шулкадәр яхшырак.

– Операция ясатмыйм, аннары, анысына соң бугай инде...

Барысы да аңлашыла болай. Мондый каты авыру белән авырып вафат булган кешеләрне белә идем, тик күңел барыбер ышанырга теләми.

– Ерунда, чир килә дә китә, дәваланырга кирәк, – дип юатам.

– Ярар, – ди Мөдәррис, – үзеңне күрәсе, шигырьләр укып утырасы, сөйләшәсе иде. Нажар ага белән Атнабай киткәннән соң рәхәтләнеп сөйләшеп, шигырь укып утырасы килгән кеше Уфада син генә калдың.

Монысы инде аның арттырыбрак җибәрүе булдымы, әллә яшьтән дуслар булып аралашып яшәгәнгә якын күреп әйтүеме, тавышы Мөдәрриснең үзәкләргә үтәрлек моңсу иде.

– Нәҗибә кайда, дим.

– Ул әле өйдә юк, эш белән йөри, аңа да мәшәкать инде... Юбилейга кил, юк, юбилейга чаклы кил, күрәсе, сөйләшәсе килә...

Икенче көнне Нәҗибәгә шалтыратам. Ул барысын да аңлатып бирде.

– Коткарып булмыймыни, табибләр ни ди соң?

– Соң инде, диләр, кил, аның сине күрәсе килә, – ди Нәҗибә.

Ни кызганыч, икенче атнада ук мин дә операциягә эләгәм. Нигә, ни өчен, нәкъ аңа мондый язмыш?! Ир уртасы чагы, иҗатының чәчәк аткан,

Р.Гаташ, Р.Әхмәтҗан, М.Әгъләм, Зөлфәт, Х.Мөдәррисова.

шигъриятенең канатланган, фикерләренең тирәнәйгән, зиһененең үткенләнгән чагы.

Больницадан тагын Казанга шалтыратам. Нәҗибә белән сөйләшәбез.

– Әле бераз гына дәрт керде, юбилей тантанасына әзерләнү күңелен күтәреп җибәрде, кәефе ярыйсы гына, тик тамагына ашый алмый, кисель шикелле сыек ризыкта гына, – ди.

– Юбилейга бара алмыйм, ләкин больницадан чыгу белән һичшиксез барам, – дим Нәҗибәгә.

Юбилей кичәсе үтү белән тагын шалтыратам: "Хәле ничек?"

– Шәптән түгел, стена ягына карап ята, йоклый шикелле, сөйләшә алмый, – ди Нәҗибә.

Мин хастаханәдән чыгуга, Мөдәррис бакый дөньяга күчкән иде инде. Күңелдә олы үкенеч калды: олы шагыйрь, якын дустымның соңгы үтенечен үти алмадым. Соңгы тапкыр сөйләшеп утыру насыйп булмады, бәлки, әйтәсе килгән сүзләре, җиткерәсе килгән фикерләре, тыңлыйсы яки сөйлисе килгән шигырьләре калгандыр.

Үлем һәрчак үкенечле була. Безнең дуслык студент елларында, 70 нче елларда ук башланган иде. Ул елларда Башкортстан дәүләт университетының мин старостасы булган "Акчарлак", татар һәм башкорт бүлегенең "Шоңкар" әдәби-иҗат түгәрәкләре белән Казан университетының "Әллүки" түгәрәкләре арасындагы дуслыкның чәчәк аткан чагы иде. Тукай, Мәҗит Гафури кичәләре, үзара Уфа–Казан яшь шагыйрьләренең алмаш иҗади очрашулары елына берничә тапкыр үтә. Ике республика арасында һава һәм тимер юлларының регулярлыгы, билет хакының арзан булуы аралашуны җиңеләйтә, ә бәлки очрашасы килүнең, бер-беребезнең иҗаты белән кызыксынуның көчлелеге, бер-беребезгә хөрмәт тә хәлиткеч роль уйнагандыр.

Бу очрашулар ике республика яшь язучыларының иҗатына биниһая әһәмиятле этәргеч, көч һәм илһам бирә, баета иде. Шушы "мәктәп"не тәмамлаган, хәзер инде олпат әдипләр булып танылганнар арасында олырак буыннардан Рәдиф Гаташ, Рим Идиятуллин, Рөстәм Мингалим, Гәрәй Рәхим, яшьләрдән Римзил Вәлиев, Марсель Галиев, Госман Садә, Шәмсия Җиһангирова, Башкортстан әдипләре арасында Факиһә Тугызбаева, Рамил Янбәк, Зөһрә Котлыгилдина һәм, һичшиксез, татар әдәбиятының горурлыгы булган Мөдәррис, Зөлфәт һәм Фәннур Сафин да бар иде.

Күп еллар дәвамында, Казанга килгән вакытта, мине Мөдәррис каршы алды. Пристаньдамы, вокзалмы, редакциягәме, килә-килешкә иң беренче булып Мөдәррис очрый. Хәтта хәбәр бирми килгән очракта да лифт каршында иң беренче аның белән очрашабыз, әйтерсең ул гел көтеп торган кебек.

Казанга бер килгәндә, бар булган йомышларны үтәп китәсе килә. Казан урамнарын яхшы белмәгәч, редакцияләргә, радио, нәшриятларга йөртү дә Мөдәррис җилкәсенә төшә иде.

"Вакыт кысаларыннан иң азат кеше безнең Мөдәррис", – дип, Рәдиф абый Гаташ мине Мөдәррискә "тагып" җибәрә. Ә Мөдәррис мине Казанның иң очсыз транспорты булган трамвайга утыртып, шалтыр-шолтыр шәһәр буйлап алып китә. Мөдәррис билетны миңа гына ала да, үзе куен кесәсеннән кызыл тышлы кенәгәсен "ялт" иттереп кондукторның күзенә теки һәм тиз генә кесәсенә кире тыга. Икенче көнне трамвайга утыргач та шул ук хәл.

– Мөдәррис, нинди шулхәтле "крутой" удостоверение күрсәтәсең соң син, бер кондуктор да сиңа бәйләнергә җөрьәт итми? – дим.

– Язучылар таныклыгы ул, дустым, кайвакыт файдасы тиеп куя аның, аңламаган кешегә, – ди үзе, рәхәтләнеп көлә бе з. Кайвакыт җәяү генә алып китә.

– Әйдә, мин сине турыдан алып чыгам, иске Казанны күрерсең, – дип кеше аягы сирәк баскан караңгы, тар тыкрыклар, бакчалар аша радио редакциясенә, автовокзалга, йә Берлеккә алып чыга. Аның Казанны яхшы белүенә шаккатам. Ул һәр урам, йорт, һәр тыкрыкның дип әйтерлек тарихын, анда яшәгән атаклы кешеләрен, булган вакыйга-

дустым!

“Гасыр капкасы” кардәшлек китап киштәсе сериясендә чыккан китабына гонорар алу өчен, Уфага бара, син аларны каршы алып, урнашырга ярдәм ит инде, шагыйрь халкының хәлен беләсең, кунакларын белә, оста итеп сөйли, мин аның белгәнен тагылып, терек-терек атлап, кызыклы риваятьләрен тыңлап барам.

– Шигырь укы, – дим.

Ул туктап, Казан урамында шигырь укый. Үзенекен, борынгы венгр-татар шагыйрьләрен, Дәрдемәндне, Акмулланы, Тукайны, башка төрки телле шагыйрьләрне.

– Кемнеке? – дип сорый миннән бер өзек китерә дә.

Мин буташтырам, юк, бу шагыйрьне укымаганнан түгел, хәтеренең сыйфатыннан. Тагын укый, тагын... Мөдәрриснең хәтере феноменаль иде. Ул күп вакыйгаларны, әдәби әсәрләрне, авторларның тормыш юлларын, кызыклы хәлләрне бик оста итеп җиткерә, аның фикер сөреме, сөйләү куәсе ышандыру көченә ия иде.

Гади генә киенгән, чандыр гәүдәле, буй да чама белән генә, ләкин Мөдәррис шигырь укый башласа, аннан да баһадиррак, аннан да матуррак, батыррак, аннан да акыллырак кеше булуы мөмкин түгел кебек күренә иде.

Аңа “ялтыраш”лык хас түгел, ул кешегә дә, заманга да яраклашырга, яхшырак күренергә тырышмады, киресенчә, “йортлыксызрак”, дөнья мәшәкатьләреннән ераграк торган шикеллерәк фикер калдыра, гәрчә тирән рухи дөньясы, шәрә нечкә күңел хисләре һәр шигыреннән ярылып ята.

Нәрсә иде бу, аның яшәү рәвешеме, әллә бу заманга протестымы? Хәтердә 1994 елның 29 октябре. Безне, бернича кешене, Язучылар берлегенә кабул итеп алу алдыннан сөйләшүгә чакырдылар.

Бу сәфәргә Уфадан үзебезнең машинада гаилә дусларыбыз белән 4 кеше кузгалдык. Табигать ай буе коры тордытордыларны да иртән үк карлы яңгыр ява башлады. Түбән Камага төнлә күз ачкысыз боз-лы яңгыр ярып килеп кердек, туганнарда кундык, икенче көнне сәгать икедә Берлектә булырга тиеш идек. Иртәниртүк тагын юлга – Казанга кузгалдык. Юл – көзге кебек ялтырап торган бозлавык, үргә күтәрелгән җирләрдә “бөкеләр” – колонна-колонна машиналар тезелгән, юлның ике ягында чакрым саен машиналар аунап ята. Чак-чак күрсәтелгән вакытка барып өлгердек. Безне Берлек капка төбендә үк Мөдәррис белән Зөлфәт каршы алды.

Зөлфәт: “Без сезнең инде исән-имин килеп җитүегезгә өметне өзгән идек, Аллага шөкер, сау-сәламәтсез”, – дип шатланды. Эш беткәннән соң, күп дуслар үзләренә кунакка чакырса да, без Мөдәррис белән Нәҗибәләргә киттек. Зур булмаган пөхтә фатир. Нәҗибә ханым кухня тирәсендә бөтерелә. Мөдәррис мине кош оясы шикелле генә җыйнак эш кабинетына чакырды. Китаплар, китаплар... Өстәл өсте язмалар белән тулы, юлдашларым телевизор карый, ә Мөдәррис миңа шигырьләрен укый. Мин үземнең шигырьләрне укыйм, кич шигырь кичәсенә әверелде.

Юлдашлар тыныч түгел, сизеп торам, борчылалар, чөнки ул елларда машина урлау, йә булмаса, тәгәрмәч салдыру илдә чәчкә аткан күңелсез күренеш иде. Ә Мөдәррис бик ышанычлы итеп: “Шагыйрьнең ишек төбеннән кунакларның машинасын алып китсәләр, Мөдәррис “пегас”ын урлаткан шикелле булыр бу, борчылмагыз”, – ди. Соңыннан белдек: ул төн буе керфек тә какмыйча, тәрәзә каршысына куелган машинаны саклап чыккан...

2002 елның яз айлары. Рәдиф абый Гаташ миңа телефон аша: ”Мөдәррис белән Наис Гамбәр, Мөдәрриснең хатыны Нәҗибә апа белән ханәләрдә бик кыйммәт, берәр торак юнәтеп булмас микән, азрак егетләргә “күз-колак” булу да артык булмас, чит шәһәр, “азатлык хисе” башларына бәрмәсен...” – дигәнрәк үтенеч белдерде.

Мин районнан Дилә Булгаковага шалтыратам. «Ике шәп шагыйрь килә, Дилә апа, каршы ал инде, сыендыр; үзем дә тизрәк килергә тырышырмын».

Мин килеп җиткәндә, изге күңелле Дилә апа җитәкчелегендә Мөдәррис белән Наис бер төркем студентлар арасында шау-гөр килеп, университеттан очрашу кичәсеннән чыгып килә иде. Аннары Башкортстан “Китап” нәшриятына очрашуга юнәлдек. Түгәрәк өстәл артында нәшрият җитәкчеләре, мөхәррирләр, язучылар, шагыйрьләр Сафуан Әлибаев, Факиһә Тугызбаева, Сабир Шәрипов һ.б. Ике республика әдипләре, кызыклы әңгәмә, дуслык табыны, җылы мөнәсәбәтләр. Мөдәрриснең дә, Наисның да күңелләре күтәренке, кәефләре шәп. Янып, ашкынып шигырь укыйлар.

Гонорарны алгач, мин: “Мөдәррис, нишләтәсең бу акчаңны?” – дип шаяртам. Ул: “Яңа фатир бар бит, бупбуш тора, эчендә берни юк, күңелсез. Азрак кешеләрчә мебель-фәлән рәтләргә иде, кыз да, оныклар килеп йөрер иде”, – ди. Мебель алганмы, юкмы, белмим, ләкин кызын, онykларын бик яраткан, аларга карата күңел җылысының никадәр зур икәне ярылып ята иде. Ә икенче җәйдә Казанга баруыбызда, җавап йөзеннәндер инде, Мөдәррис белән Наис Дилә апа белән безне кунакка чакырды. Табынны Наисларда әзерләгәннәр. Наисның хәләл җефете Гөлфирә ханым белән егетләр бөтерелеп безне кунак итә, шигырь уку китә. Гаташ: “Сезнең белән һәр очрашу шигырь кичәсенә әверелә, тик сирәгрәк киләсез”, – ди. Сүз әдәбият, шигърият, аның үткәне, киләчәге турында.

Зөлфәтнең сәламәтлеге барыбызны да борчый. Фирая ханымның бетмәс-төкәнмәс күңел җылылыгы, чын мәгънәсендә шагыйрь хатыны булуына сокланабыз. Мөдәррис: “Зөлфәт - көчле шагыйрь, алай гына биреширгә тиеш түгел, ул әле яшәргә тиеш, аның гомере миннән дә озынрак булачак, менә күрерсез”, – ди, ышанычлы итеп.

И, гомерләр, Наис та, Мөдәррис, Зөлфәт тә юк инде. Мөдәррис дөнья мәшәкатьләренә битараф күренсә дә, тирә-яктагы гаделсезлеккә эче пошып, әрни, зарланып та куйгалый иде.

Тел төбеннән сизелгәнчә, аның гаделсезлекне иң авыр кичергәне “Аккош күлендә”ге “сәламә” генә йортын – тыныч оясын югалтуы, саклап кала алмавы иде. Очрашкан саен, ул ерак алтмышынчы елларда Уфада Черниковка бистәсендә һөнәрчелек училищесында бераз укып, яшәп алуы хакында искә алырга ярата иде.

Мөдәрриснең күңеле бик сак һәм сизгер иде. Ул кешеләр арасындагы иң нечкә тойгыларны да күңеле аша үткәрә, кайсы чакта әңгәмә вакытында төркемнән сиздерми генә югала, үзенең артык булуыннан курыккан шикеллерәк хис калдыра иде. Мөдәррис горур, кайсы чакта бунтарь холыклы да иде. Кешенең кем булуына, дәрәҗәсенә, титулына карамыйча, үзенең хак икәнен белсә, гадел фикерен, үз карашын җиренә җиткереп әйтә белә иде.

Шагыйрь буларак Мөдәррис бары тик талантларны, шәхес буларак гадел, ихлас кешеләрне генә яратты. Соңгы очрашу 2005 елның сентябрь башында булды.

Мөдәррис Дилә апа белән мине Уфага китә торган поездга озата төште. Урамда инде караңгы булса да, “кайт, соңга каласың”, дигәнгә дә карамыйча сумкаларны күтәрешеп, купега чаклы кертеп урнаштырды, тизрәк очрашуны теләп хушлашты, поезд кузгалгач та, кул изәп перронда озатып калды.

Мөдәррис Әгъләмов ике гасыр арасында – социализм, коммунизмны аулау, үзгәртеп кору һәм демократия дигән битлек астында хөкем сөргән авторитаризмнан – хаос, хаосны авторитаризм алыштырган чорда яшәп чынбарлык хисен югалтмаган, заманның ерткыч йөзенә туры карап, аңа яраклашмыйча, үз сүзен кыю әйткән, үзе булып кала алган шәхес һәм шагыйрь булып яшәде.

Ә ул сирәкләр язмышы. Рәхмәт сиңа, дустым!

Халисә МӨДӘРРИСОВА,
шагыйрә.
Уфа.

Айга кырын карама

Халык медицинасы чаралары белән дәвалануга керешкәнче, табиб белән киңәшү зарур!

1 октябрь (шимбә). ***Рабигул әүвәл аеның 5 нче көне. 7 нче Ай тәүлеге. Ай Укчы йолдызлыгында, 13.08 сәгатьтә калка, 19.14 сәгатьтә бата. 1 нче фаза. Көн озынлыгы 11.34 сәгать.***

Һава энергиясенә бәйле көн. Тынгысызланырга, гайбәт сөйләргә ярамый. Ялгыз калып уйлану файдалы. Нерв системасы, үпкә зәгыйфь. Ач тору, ашказанын һәм эчәклекне чистарту уңай нәтиҗә бирә.

Мәтрүшкә

Мәтрүшкә тәнәтмәсе эчәклек атониясе, ашказаны спазмнары, гастрит, бавыр ялкынсынуы, гепатит, коклюш авырулары вакытында, йокысызлык интектергәндә, нервлар какшаганда кулланыла. Төрле тире авырулары, төче авыруы (золотуха) булганда, мәтрүшкәле су белән коену файдалы. Халык медицинасында мәтрүшкә тагын ревматизм, паралич, эпилепсия, аменорея, эчәклек авыруларын дәвалауда кулланыла, тир һәм бәвел кудыргыч чара буларак мәгълүм.

2 октябрь (якшәмбе). ***Рабигул әүвәл аеның 6 нчы көне. 8 нче Ай тәүлеге. Ай Кәҗәмөгез йолдызлыгында, 14.28 сәгатьтә калка, 20.02 сәгатьтә бата. 1 нче фаза. Көн озынлыгы11.29 сәгать.***

Бүген бигрәк тә ут белән эш иткәндә саклык сорала. Ризык җиңел үзләштерелүчән булырга тиеш. Ашказаны, бизләр системасы зәгыйфь, невралгия һәм стенокардияне кисәтү чаралары уңай нәтиҗә бирә. Колак авыртырга мөмкин. Бу атнада күзне саклау мөһим.

Бөтнек

Бөтнек аппетитны ача, ашкайнатуны яхшырта, күңел болгануны баса. Аны үткудыргыч чара буларак, шулай ук өске сулыш юллары ялкынсынганда, бронхит вакытында кулланалар. Бөтнекле ванна нервларны тынычландыра. Бөтнек тәнәтмәсе эч һәм йөрәк авыртканда, ютәлләгәндә, сару кайнаганда файдалы. Яшел яфракларын пешкән урынга яки эренле яраларга куюда нәтиҗәле. Бөтнек чәе авыз кыышлыгын бик әйбәт йогышсызландыра.

3 октябрь (дүшәмбе). ***Рабигул әүвәл аеның 7 нче көне. 9 нчы Ай тәүлеге. Ай Кәҗәмөгез йолдызлыгында,15.26 сәгатьтә калка, 21.14 сәгатьтә бата. 2 нче фаза. Көн озынлыгы 11.25 сәгать.***

Авыр энергетикалы көн, алдашу, ялганга бай. Хәтта сыйфатлы ризык белән дә агулану ихтималы бар. Күп аралашу хупланмый. Фикерләрне тупларга, үзегезне үпкәләткән кешеләрне кичерергә кирәк. Үпкә, ашказаны зәгыйфь. Кан басымы күтәрелергә, йөрәк, арка яки баш авыртырга мөмкин. Мунча керү файдалы.

Кориандр

Кориандр (кинза) гастрит, ашказаны һәм уникеилле эчәк җәрәхәте белән чирләгәндә ашкайнатуны яхшырту өчен кулланыла. Кориандр орлыгы антисептик, үткудыргыч, авыртуны баса торган дарулар составына кертелә. Орлыгы һәм яшел яфракларының кайнатмасы бронхит һәм үпкә ялкынсынуы вакытында какырык куптаргыч чара буларак файдаланыла.

(Дәвамы 18 нче биттә).

Айга карама кырын

Кинзадан алынган линалоол керати һәм конъюнктивитны дәвалауда кулланыла торган цитраль житештерүдә чимал булып тора. Кориандр төнәтмәсе күзән җыюны бетерә, тынычландыра, җәрәхәтләрне җыя, С һәм А витаминнары чыганагы буларак та кулланыла.

4 октябрь (сишәмбе). ***Рабигул әүвәл аеның 8 нче көне. 10 нчы Ай тәүлеге. Ай Сукояр йолдызлыгында, 16.03 сәгатьтә калка, 22.43 сәгатьтә бата. 2 нче фаза. Көн озынлыгы 11.20 сәгать.***

Нәсел, гаилә, гореф-гадәтләр белән бәйле көн. Ял итү, йокы туйдыру, гаиләне ныгыту өчен иң шәп вакыт. Әйләнә-тирәдәгеләргә игътибарлырак булу сорала. Сизү әгъзалары, йөрәк-кан тамырлары системасы, сөякләр зәгыйфь. Ач тору файдалы.

Петрушка

Петрушка тамыры бөер авыртканда һәм эч кипкәндә, орлыгы – бәвел кудыргыч чара буларак, яфраклары ялкынсынуны басу, җәрәхәтләрне җыюда кулланыла. Петрушка орлыгы бизгәк тотканда, мәни бизе ялкынсынганда, күрем күрү бозылганда, эч чәнчегәндә файдалы.

5 октябрь (чәршәмбе). ***Рабигул әүвәл аеның 9 нчы көне. 11 нче Ай тәүлеге. Ай Сукояр йолдызлыгында, 16.25 сәгатьтә калка, 0.18 сәгатьтә бата. 2 нче фаза. Көн озынлыгы 11.16 сәгать.***

Үзгәрү, сафлык, катгыйлык көне. Һәр эштә дә сак һәм игътибарлы булу сорала. Башланган эшне ахырына җиткерергә кирәк. Бу көннең энергетик куәте бик зур, кешедә искиткеч табигый көч уянырга мөмкин. Арып-талганчы эшләргә ярамый. Сизү әгъзалары, йөрәк, умырткалык, үпкә зәгыйфь.

6 октябрь (пәнҗешәмбе). ***Рабигул әүвәл аеның 10 нчы көне.12 нче Ай тәүлеге. Ай Балыклар йолдызлыгында, 16.40 сәгатьтә калка, 1.53 сәгатьтә бата. 2 нче фаза. Көн озынлыгы 11.11сәгать.***

Шәфкать, сабырлык, мәхәббәт энергиясенә бай көн. Сәламәтлеккә игътибарлы булырга, йөрәккә киеренкелек китермәскә кирәк. Ашкайнату әгъзалары, кан әйләнеше системасы зәгыйфь. Дарулар яхшы үзләштерелә.

Укроп

Укропны симергәндә, диабет белән чирләгәндә, тоз утырганда куллану файдалы. Орлыгы стенокардия өянәген, неврозларны кисәтергә сәләтле. Яфрак һәм сабаклары төнәтмәсен гипертония булганда һәм бәвел кудыру өчен эчәләр. Эфир мае яраларны тиз җыя, төрле аллергияләрдән дәвалый.

7 октябрь (җомга). ***Рабигул әүвәл аеның 11 нче көне. 13 нче Ай тәүлеге. Ай Балыклар йолдызлыгында, 16.51 сәгатьтә калка, 3.25 сәгатьтә бата. 2 нче фаза. Көн озынлыгы 11.07 сәгать.***

Үзгәрешләр көне. Үткәннәр турында уйланып, нәтиҗәләр ясау яхшы. Ач торырга ярамый – теләсә нәрсә ашарга була. Аралашу, белем алу өчен уңай вакыт. Йөрәк, тире, кан тамырлары зәгыйфь. Чикләвек ашау файдалы.

Лечо

3 кг помидорны иттарткычтан чыгаралар, 5-6 кишерне кыргычта кыралар, шуңа ярты стакан шикәр, 1 аш кашыгы тоз, 1,5 стакан үсемлек мае, 1-2 аш кашыгы серкә эссенциясе, 1 әче борыч салып, кайнатып чыгаралар. 2-4 өлешкә бүленгән 4-5 кг татлы борыч өстәп, 15-20 минут кайнаталар, стериль банкаларга бүләп, тимер капкач белән каплыйлар.

Төркиядә татар хикәяләре



Төркиядә төрек теленә тәрҗемәдә чыккан (тәрҗемәчесе – Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы Фатих Кутлу) татар хикәяләре антологиясе китабына карата төрек матбугатында беренче фикерләр күренә башлады. Әлеге генә кулыбызга «Яңа шәфәкъ» газетасында басылып чыккан «Татар хикәя табыныннан – әчесеннән, төчесеннән – төрлесеннән тәм-томнар...» дип исемләнгән язма килеп иреште. Аны Ибраһим Демирҗи язган. Язма белән танышкач, төрекләрнең «Гүзәл хикәяләр» дип аталган үз антологияләреннән (алар ике китап) алган үз тәэссоратым яңарды. Ул хикәяләр төрек халкын, аның мохитен тануда зур роль уйнады.

Халыкны дөньяга танытырга тиешле хикәяләр «шаккатыризм» хакына язылган булырга тиеш түгел, дигән фикер дә ныгыды. Билгеле, язучы беренче нәүбәттә үз халкы өчен яза. Хикәя нигезендә ниндидер гаҗәеп берәр вакыйга ятарга тиеш, башкача ничек укучыны кызыксындырмак кирәк, дип язылган булса, хикәя оттыра. Чын хикәя ул тормышның, яшәешнең үз эченнән, халыкның холык-фигыле, уй-фикере, эш-гамәлләреннән үрелә. Әсәр шунда гына көч һәм кыйммәт казана, халыкны тануда да ялгыш юлларга алып керми. Күз алдында урыны-урыны белән фильмдагы кебек кадрлар барлыкка китермәгән әсәрне көчле дип булмый. Хикәя осталарының әсәрләрен укыганда, андагы сурәтләр этәлек һәм төп фикер белән бер үк дәрәҗәдә истә кала. «Гүзәл хикәяләр»дә дә төрек тормышының тоткасы булган яшәү рәвеше – кулыңнан килгән эшне эшләп көн күрү, үзара ярдәмләшеп яшәү, кардәш-туган мөнәсәбәтләренең ныклыгы, Ислам диненең төп кагыйдәләренең берсе – булганына канәгатьлек тойгысының көче һ.б.лар бик ачык чагыла. Тамырлары белән безгә уртак, холкы белән охшаш, дине белән бер булган халыкның бүгенге көндә бездән аермалы яклары да хикәяләрендә ачык күзаллана. Дәүләтендә социализм корып маташмаган, халыкны дин кануннары буенча, кешелеклелек юлында эзләп табарга тырышып яшәгән милләт белән үзебезне чагыштырганда, соңгы гасырда ниләр табып, ниләр югалтканыбыз да төсмерләнә кебек. Бу тәэссорат Төркиядә «Татар хикәяләре антологиясе» тудырачак уй-фикерләрнең кыйммәтен дә ачык күзалларга ярдәм итә.

Ибраһим Демирҗинең бу язмасын укыганнан соң, сөенеп: «Китапның укучысы күп булачак, шөкер!» – дим. «Хәзерге татар хикәяләре антологиясе» турында язылган беренче язманы төрекчәдән тәрҗемә итеп тәкъдим итәм.

Асия РӘХИМОВА.

Татар хикәя табыныннан тәм-томнар...

«Хәзерге татар хикәясе. XXI гасыр» исемле китапка 1938-1989 еллар арасында туган язучыларның сайланма хикәяләре кергән. «Һәҗә» нәшрияты басмасы булган әлеге китап үз укучыларын бүгенге татар тормышы белән таныштырга чакыра.

«Һәҗә» нәшрияты хәзерге татар хикәяләре антологиясен үзенең 675 нче китабы итеп, 2022 елның июль аенда укучысына тәкъдим итте. Редакторы – Али Улви Темел. 376 биттән торган бу җыентыкны телебезгә Фатих Кутлу тәрҗемә иткән. Китапның кереш битенә «Бу җыентык Татарстан Язучылар берлеге катнашында әзерләнде» дигән язма да куелган. Тәрҗемәченең «Бу хезмәтемне, чит җирләр үз ватаннарына, ватаннары исә чит җиргә әйләнгән Төркия татарларына багышлыйм» дигән сүзләре дә татар язмышы мажарасының инде бер читен яктыртып җибәргән кебек була. Кутлу үзенең «Тәрҗемәче сүзе»ндә китапның оешу тарихын да сөйләп биргән.

Татарстан Язучылар берлеге рәисе, Татарстан Дәүләт Советы вәкиле Ркаил Зәйдулла «Хикәянең дәвамы бар» исемле кереш мәкаләсендә татар әдәбиятында хикәя жанры турындагы фикерләре белән уртаклашкан. Җыентыкта, иң олы яшьтәгесе – 1938, иң кече яшьтәгесе 1989 елгы булган утыз татар язучысының берәр хикәясенә урын бирелгән. 1948 елда туган ике язучының берсе Әхәт Гаффарның җыентык төзелгән вакытта «вафат булуын» әйтеп, Зәйдулла болай ди: «Ләкин без, кагыйдәгә хилафлык килсә дә, антологиянең әчтәлеген шул килеш калдыру дөрес булыр, дигән нәтиҗәгә килдек. Әлеге хезмәт мәрхүмнең рухына дога булып та барсын». Болай эшләп бик дөрес иткәннәр. Чөнки китаптагы иң кыска хикәя булган «Карачкылар»да Әхәт Гаффар күңел кылларын чиртә торган «яшерен сөю» темасын нечкә хисләр, нәфис сүзләр белән, оста итеп үреп биргән. Аннары, язучының вафат булуы әле аның «исән язучы» булуына чик куя алмый.

«Хәзерге татар хикәясе»ндәге әсәрләрне укыганда, Казан татарларының көндәлек тормышы, мәдәнияте, кешеләре арасындагы мөнәсәбәт, мәктәпләре, гореф-гадәтләре, табигатьләре, йорт-бакчалары, мал-туарлары, рус халкы белән аралары, рус теленә, мәдәниятенә булган мөнәсәбәтләре – һәрберсе хакында бик озаклап сөйләргә мөмкин – һәм без дә күп мәгълүмат алабыз. Кайбер хикәяләрдә Советлар чорында кертелгән күңелгә авыр тәртипләр, гамәлләр турында сүз бара. Кайберләрендә Россия Федерациясе чорында күренгәләгән сәерлекләр тасвирлана. Мөселманлыкның һәм исламы гореф-гадәтләрнең татар җәмгыятендә, аның иң бак тамырларына кадәр үтеп кергән булуын, көчле нигез тәшкил иткәнен әледән-әле хис итәсең. Бу фикерләремә аерым-аерым үрнәкләр бирә башласам, таныштыру язмасыннан гыйбарәт бу мәкаләмнең чиге булмас иде.

Тәүбә итүче рәссам

Җыентыкның беренче хикәясе – Рабит Батулланың 2010 елда, Биектау районының Чыршы авылында язып тәмамлаган әсәре. Хикәя «Җаныңны ярып бир» дип атала. Автобиографик булуы уйга килгән бу әсәрендә язучы «дулый торган ат кебек ярсу, кайнар канлы» яшьлек дусты рәссам Дулатның тормыш вакыйгаларын хикәяли.

Совет режимы таләпләре буенча да рәсемнәр иҗат иткән Дулат шулай берчак «Алдынгы дуңгыз караучылар» рәсемен сукрана-сукрана ясап, «ярым шаяру, ярым канәгатьсезлек иләү»: «Дуңгызлар ясый-ясый үзем дә дуңгызга әйләнеп беттем инде!» – ди. «Алдынгы дуңгыз караучылар» рәсеме өчен ул дәүләттән шактый акча ала. Дулат бу хәлләргә риза түгел. Үз-үзен сөймәвен, көзгегә карап, үз чыраена үзе төкерүен әйтә. Агымга каршы торуның беренче күрсәткече – ул үзенең Мәскәүдә бер күргәзмәгә куелачак «Әлмәт балкышы» исемле картинасын, инде сайлап алынганнан һәм Мәскәүгә җибәрергә дип тапшырылганнан соң, урлап диярлек кире алып, тураклап юк итә. Дулатның уенча, ул әлеге әсәре белән, Әлмәтте нефть чыгарылу аркасында барлыкка килгән чатаклыкларны, анда яшәүче кешеләрнең, андагы табигатьнең тигез һәм тыныч яшәү рәвешенең юк ителүен «мактаган» булып чыга: «Әлмәт балкышы» итеп ул үз вөҗданын саткан».

Өч елга ирегеннән мәхрүм ителгән Дулат, яхшыра бара дигән карар белән, шартлы рәвештә вакытыннан элек азат ителә; мәхкәмә, ягъни суд чыгымнарын түли, Рәссамнар берлегеннән чыгарыла, остаханәсеннән куыла. Шактый вакытлар рәссам үз юлын таба алмый, югалып кала. Ниһаять, XVI гасырның беренче яртысында Казан ханлыгы белән идарә иткән Сөембикә ханбикәнең рәсемен иҗат итеп, яңа юлга кергән булып чыга. «Каһарман» исемле рәсемендә 1552 елда Казанны саклаганда шәһит булган Япанча баһадирны сурәтли. Бу рәсемнәр Дулатның, үлгәч тә, ярдәмчесе, яклаучысы, саклаучысы, догачысы булачак.

Казан сөлгесе

Ләис Зөлкарнәйнең «Хушлашу сүзе» исемле хикәясенә бирелгән беренче искәрмәне биредә тулысынча китерәм:

«Казан сөлгесе: мең еллык тарихы булган бу сөлге, башта, әле сөлге туку җәйләнмалары кулланыла башлаганчы ук, ефәк тукымага көмеш җепләр белән чигеп эшләнгән. Соңрак кул җәйланмасында тукыла башлаган һәм якынча озынлыгы ике метр, киңлеге кырык сантиметр булган ак төстәге сөлгенең ике башы кызыл бизәкләр белән чигелгән. Сабантуйларда батыр калган көрәшчегә, ат ярышында беренче килгән һәм иң соңыннан килгән (юату билгесе итеп, ат муенына әбекәйләр бәйли) бәйгедә катнашучыларга бирелә торган сөлге – татар мәдәниятенең зур әһәмияткә ия символларының берсе».

Бәйгедә иң арттa килгән атны юату өчен ул атка сөлге бәйләгән, шул рәвешле аны беренче килгән ат белән бер дәрәҗәгә куйган әбекәйләре булган мондый җәмгыять – бөек һәм киң күңелле җәмгыять түгелме!? Бөтен халкыгы белән шулай!

Хикәясенең башына «Утыз яшендә тол калып, биш баласын аякка бастыра алган Заһидә әбием рухына» дигән багышлау куйган Зөлкарнәй, Казан сөлгесенең тора-бара көнкүрештән югалуына, аның урынын «кибеттән алынган кәләм, пәрдә, кием-салым»-кебек нәрсәләрнең алуына борчыла һәм әсәрен, бер татар халык җырында җырланган «чибәр сеңел»гә эндәшеп, болай тәмамлый: «Кайда син, матур сеңел? Ашык әле, матурлыгыңны сөлгеләреңә чигеп калдырырга ашык әле».

Авыл-калалардан, үткәннәр һәм бүгенгедән алынган төрле каһарманнарның мажараларына шаһит була-була, китапны укыганда, изгелекнең гүзәллеген, аның көчен, игелекнең җавапсыз калмаячагына һәм явызлыкның никадәр шыксыз, никадәр иләмсез булуына кабат ышанасың.

Тагын шуны да әйтәсем килә, «Хәзерге татар хикәясе»ндәге әсәрләрнең күбесен укыганда мин аларның кинематографик булуына игътибар иттем, алар нигезендә бик шәп нәфис фильмнар төшереп булыр иде.

Ибраһим ДЕМИРҖИ.

(Ахыры. Башы 35-37 нче саннарда).

Репрессияләр дәһшәте

Гомере фаҗигале өзелүгә карамастан, Һ.Маликов җитәкчелегендә Кытайга хәрби буруч үтәргә барган тагын бер командир, татар милләтенең кадерле улы Миңнегали Шәйморатов та хәрби өлкәдә шактый зур уңышларга ирешә. 1936 елдан – майор, 1938 елдан полковник дәрәҗәсенә күтәрелгән Миңнегали Минһаҗетдин улын, генерал-майор Лев Доваторның 2 нче гвардия кавалерия корпусы составындагы кавалерия полкы белән

Миңнегали Шәйморатов.

Федор Полынин.

Миргазиян Крыймов.

командалык иткән җиреннән, сугышның беренче елы тәмамланып килгән көннәрнең берсендә, Көньяк Урал хәрби округына кайтаралар. 25 декабрьдә ул Уфага кайтып төшә һәм Башкортстанда оешып килүче 112 нче кавалерия дивизиясе командиры вазифасына керешә. Дивизия 1942 елның яз ахырларында фронт полосасына килеп туплана һәм җәй башларында яуга керә. Ворошиловград һәм Сталинград өчен барган канлы бәрелешләрдә зур югалтулар кичергән дивизия 1943 елның 14 февраленнән 16 нчы гвардия Чернигов кавалерия дивизиясе итеп үзгәртелә. Тагын 9 көннән, төгәлрәге, 23 февральдә, дошман тылына ясалган рейдтан чыккан чагында, 1942 елның 10 ноябрендә генерал-майор чины алган Миңнегали Шәйморатов батырларча һәлак була. Әмма, "хәбәрсез югалганнар" исемлегенә кертелүе сәбәпле, татар каһарманының батырлыклары тиешенчә бәяләнми. Фәкать 2020 елда гына аңа Россия Герое исеме бирелү шул гаделсезлекләрне күпмедер дәрәҗәдә бетерү мөмкинлеге бирә.

Шинҗан провинциясендә кытай армиясен төзүдә һәм аны өйрәтүдә зур булышлык күрсәткән Һади Маликовның тагын бер ярдәмчесе – хәрби очучы Федор Петрович Полынин да (Финь По) репрессияләр дәһшәтенә эләкми һәм Бөек Ватан сугышында зур хәрби дәрәҗәләргә ирешә. 1938 елда Алтын Йолдыз белән бүләкләнгән һәм тагын ике елдан авиация генерал-майоры званиесе алган Федор Полынин сугыш башланганда – 13 нче бомбага тотучы авиация дивизиясе командиры. 1941 елның август аеннан – Брянск фронтының Хәрби-һава көчләре командующие вазифасында. 1942 елда Брянск фронтының – 2 нче һава һәм Төньяк-Көнбатыш фронтның 6 нчы һава армияләре командующиеләре урынбасары булып хезмәтен дәвам иттерә. 1943 елда 6 нчы һава армиясе белән 2 нче һәм 1 нче Белоруссия фронтлары гаскәрләрен көчәйтә. 1944 елның октябреннән авиация генерал-лейтенанты Ф.Полынин Поляк армиясе гаскәрләренең Хәрби-һава көчләре командующие вазифасына керешә һәм сугыштан соң тагын ике ел дәвамында шул вазифаны башкара. 1946 елдан – авиация генерал-полковнигы.

* * *

Кызыл Байраклы Кавказ армиясе штабында Разведка бүлеге белән җитәкчелек иткән дүрт татар хәрби разведчигының берсе, Ленино-горск районының Мөэмин-Каратай авылы егете Миргазиян Галиулла улы Крыймов та – Сталин репрессияләреннән җык күргән татар баласы. Кечкенәдән белемгә омтылучы, татар мохитендә тәрбияләнгән япь-яшь егетнең 1916 елда Тифлис каласында прапорщиклар мәктәбен тәмамлавы үзе батырлыкка тиң. Гәрчә мулла малаеның Октябрь революциясендә большевикларны яклавы һәм Гражданнар сугышында кызыллар ягында яу тотуы шулай ук үзгә бер күренеш, әлбәттә. Патша армиясе офицерының кыска гына вакытта 1 нче аерым Идел буе Татар бригадасы командиры булуы, 175 нче һәм 103 нче бригадаларның штаб башлыклары вазифаларын вакытлыча башкаруы мәгълүм. М.Фрунзе исемендәге Хәрби академиянең төп курс (1921-1924) һәм көнчыгыш (1924-1926) факультетларында хәрби белемен камилләштергәннән соң – РККА штабының разведка идарәсе карамагында: 1931 елның мартыннан алып ноябренә кадәр Кызыл Байраклы Кавказ армиясе штабының Разведка бүлеге башлыгы Минзакир Әпсәләмовның ярдәмчесе булып тора, ә инде 1932 елның мартына кадәр бүлекне үзе җитәкли. 1933-1934 елларда үзе укыган академиянең оператив факультетында хәрби белемен камилләштерә һәм ике ел дәвамында 1 нче Казан укчы дивизиясенең штаб башлыгы вазифасында практика үтә. 1935 елның 16 февралендә полковник Крыймов 19 нчы укчы корпусның штаб башлыгы итеп билгеләнә, әмма бу вазифага керешеп өлгерми – Фрунзе исемендәге Хәрби академиянең гомуми тактика кафедрасы җитәкчесе итеп расланa. Кызганыч, илдә башланып киткән коточкыч репрессияләр дулкыны киләчәк хәрби карьерасы шактый саллы буласы шик уятмаган татар баласын әйләнеп үтми: Дзержинский шәкертләре Миргазиян Крыймовның нинди социаль катламнан икәнен "ачыклый" һәм мулла малаен 1938 елның 1 августында 43 нче маддәнең "б" пункты буенча армиядән кудыртуга ирешә.

Әмма үҗәт М.Крыймов үз хокуклары өчен көрәшен туктатмый. Нәтиҗәдә, Бөек Ватан сугышы башлануга полковник Крыймовны кабат Кызыл Армия сафларына кайтаралар.1942 елның октябреннән фронтта – җиде ай буена 98 нче укчы дивизия командиры урынбасары булып хезмәтен дәвам итә. Аннары 387 нче, 232 нче, 206 нчы укчы дивизияләрнең командирлары урынбасары һәм 387 нче, 127 нче, 38 нче укчы дивизияләрнең командиры вазифаларын башкара. Милләттәшебез Австриянең Альп тауларындагы бәрелешләр вакытында, 1945 елның 15 апрелендә һәлак була. Кылган батырлыклары өчен Ленин, ике Кызыл Байрак һәм II дәрәҗә Богдан Хмельницкий орденнары белән бүләкләнгән гвардия полковнигы Миргазиян Крыймовның исеме Сербиянең Воеводина автономияле краена керүче Сомбор каласындагы совет офицерларының туганнар каберлегенә куелган обелискка уеп язылган. Әлбәттә, күп чыганакларда, шул исәптән Татар энциклопедиясендә, хаталанып, милләттәшебезнең Чехословакиянең Самбор, каласында (гәрчә ни Чехиядә, ни Словакиядә андый кала юк) җирләнүе турында язуларын искәртми ярамас. Әле җитмәсә, ул каланы "Самборе" дип атаучылар да бар. Соңгы вакытта тагын бер ачыш: янәсе, ул "Словениянең Сомбор каласын азат иткәндә һәлак була һәм шул шәһәрнең чиркәве янында җирләнә". Ни аяныч, ул ил территориясендә дә андый кала юк.

...Менә-менә комбриг чинына үрләтелергә торган һәм сугышта тагын да югарырак хәрби үрләр яуларга сәләтле бер гаепсез Һади Маликовның хәрби һәм дипломатик карьерасын югалтып кына калмыйча, дистә ярым ел дәвамында җәбер-золым, михнәт күреп һәм ирексә сусап яшәргә мәҗбүр ителүе соң дәрәҗәдә кызганыч. Бөек Ватан сугышында Кызыл Армиягә, хәрби разведкага әллә никадәр файда китерәчәге шик уятмаган полковник Мәүлитов атып үтерелә, полковник Маликов дистә ярым елдан артыграк гомерен тоткынлыкта үткәрә, ә генерал-майор Әпсәләмов белән полковник Крыймов җәбер күрә. Соңыннан ачыкланганча, аларның берсенең дә гаебе булмый.

Нәтиҗә һәм хакыйкать шул: андый акланмаган репрессияләр коточкыч кайгы-хәсрәттән, күз яшьләреннән, рәнҗеш-каргышлардан башка ни илгә, ни Кызыл Армиягә, ни хәрби разведкага бернинди дә файда китерми. Бу – бер төркем татар хәрбиләре мисалында – Сталин хакимиятне тулысынча үз кулларына алу белән башланып киткән һәм 1937-1939 елларда үзенең апогеена җиткән җинаятьчел канлы репрессияләрне яклаучыларга һәм акларга маташучыларга җавап.

Рәис ЗАРИПОВ.

Колачлы дини җыен

Уфада Идел буе Болгар дәүләтендә ислам динен кабул итүнең 1100 еллыгы; Шәйхелислам Тәлгать Сафа Таҗетдинның Баш мөфти, Россиянең Үзәк Диния нәзарәте рәисе вазифасында эшләвенә 40 ел тулу, Россия мөселманнары Үзәк Диния нәзарәте карамагында эшләүче Россия ислам университетының яңа корпусларын ачуга багышланган тантаналар узды.

Башкортстан башкаласына Россиянең дин әһелләре, дәүләт һәм җәмәгать эшлеклеләре, дин галимнәре һәм тарихчылар, Төркия, ДХР, ЛХР, Әфганстан, Согыд Гарәбстаны, Болгария, Мисыр, Һиндстан, Иордания, Марокко, Берләшкән Гарәп Әмирлекләре, Сербия, Сүрия, Тунис, Ливан, Беларусь, Кыргызстан, Таҗикстан, Казахстан, Үзбәкстан дини идарәләреннән делегатлар килде.

Шәрәфле кунаклар арасында – Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин, республиканың баш казые Җәлил хәзрәт Фазлыев, РИИ һәм КИУ ректоры Рәфыйк хәзрәт Мөхәммәтшин, Ислам динен кабул итүгә 1000 ел исемендәге мәдрәсә җитәкчесе Ильяс хәзрәт Җиһаншин да булды.

Көннең беренче яртысында Уфада Идел буе Болгар дәүләтендә ислам дине кабул ителүнең 1100 еллыгы уңаеннан катнаш форматта пленар утырыш узды. Аннары төп диннәрнең уртак идеаллары һәм кыйммәтләренә, динара хезмәттәшлеккә багышланган халыкара фәнни-гамәли конференция үз эшен башлады.

Кич белән Ислам мәгарифенә ярдәм итү буенча Евразия ассоциациясе Советы утырышы, шулай ук Россиянең югары ислам дини белем бирү оешмалары ректорлары очрашуы оештырылды.

Икенче көнне халыкара фәнни-гамәли конференция үз эшен секцияләрдә дәвам итте. "Теологик һәм дини белем бирүне үстерүнең актуаль мәсьәләләре" секциясе эшендә шулай ук Болгар ислам академиясе хезмәткәрләре дә катнашты. Уфадагы тантаналы чаралар җәмгыятьтә татулыкны саклау һәм ныгыту темасына багышланган түгәрәк өстәл белән тәмамланды.

Нигә уң, нигә сул?

Ни өчен ир-атлар киемендәге төймәләр уң якта, ә хатын-кызларныкында сул якта урнашкан? Моның сәбәбен тарихтан эзләргә кирәк. Беренче сәдәфләр бик кыйммәт торган һәм аларны бик мул тормышлы кешеләр генә тактыра алган. Бай ирләр үзләре киенгән, ә хатын-кызларны хезмәтчеләре киендергән. Халыкның күпчелек өлеше сулагай түгел, шунлыктан тегүчеләр ирләр киеменә төймәне уң кул белән каптырганда, җайлырак якка – уң якка таккан. Хатын-кызны киендергән хезмәтчегә исә, киресенчә, сул якка тагылган төймәләрне каптыру ансатрак булган. Билгеле, хәзер гүзәл затларыбызның барысы да диярлек үзе киенә, әмма гасырлар буена күнегелгән тәртипне беркемнең дә үзгәртәсе килми – хатын-кыз киеменә сәдәфләр һаман сул якка тегелә.

(“The Mirror”).

Сәламәтлек сере

Гасырлар буена һәр халыкның үзенә генә хас сәламәтлек саклау серләре формалашкан. Мәсәлән, Кытайда хатын-кызлар 90 яшькә җиткәнче дөге плантациясендә эшли һәм кычкырып җырлый. Нәкъ менә җыр аларның кәефен күтәрә һәм иммунитетын ныгыта. Финляндиядә халыкның 70 проценты спорт белән шөгыльләнә, һәр икенче хатын-кыз эшкә җәяү яки велосипедта йөри, көннәр суыткач та, финнәр балык тотудан һәм походка йөрүдән туктамый. Һиндстанда Альцгеймер авыруы белән чирләүчеләр саны Көнбатыш илләрендәгедән күпкә азрак, моның сере төрле тәмләткечләрне, бигрәк тә куркумны күп кулланудан: куркум ревматизмнан саклый, имбир ашкайнатуны җайга сала, дарчин канны сыегайта һәм диабеттан дәвалый. Яңа Зеландиядә чәй агачыннан алынган бал, Исландиядә майлы балык, Аргентинада атнасына берничә тапкыр 1-2 бокал кызыл шәраб куллану сәламәтлекне ныгыта, дип саныйлар. Япониядә гомерне озайту өчен дөге, балык, соя һәм яшелчә күп ашыйлар, болай туклану йөрәк-кан тамырлары авыруларыннан, яман шештән саклый, сөякләрне ныгыта. Японнар яратып эчә торган яшел чәй исә инсульт булу, ашказаны һәм ашказаны асты бизендә онкология башлану ихтималын киметә, кандагы холестерин микъдарын һәм кан басымын җайга сала, инсулинның активлыгын арттыра. Франциядә, күп итеп ит, май, сыр, сөт өсте ашасалар да, симезләр юк, гомерләре дә озын. Сере гади: французлар сарымсак һәм кызыл шәраб ярата, ризыкның файдасы яки зыяны хакында түгел, тәме турында гына уйлый.

(“Nation Geographik”).

Даһи булу җиңелме?

Даһилык еш кына каты авыру яки иртә үлем белән тәгәлләнә. Мәсәлән, Николай Гоголь, Исаак Ньютон һәм Иммануил Кант шизофрениядән, Александр Македонский, Юлий Цезарь, Наполеон Бонапарт һәм Федор Достоевский эпилепсиядән интеккән. Болар – дөньякүләм танылган даһилар. Галимнәр фикеренчә, табигать сәләтле кешеләрне аеруча кырыс сыный. Даһилык та үзенә бер төрле чир икән: аутизмның үзгә бер формасыннан интегүчеләрнең, социаль күнекмәләре булмаса да, интеллектуаль үсеше башкаларны хәйран калдыра, шул күренеш Аспергер синдромы дип атала. Даһилык сәләте нәселдән килгән чирләргә дә бәйле. Мәсәлән, Иоганн Гете, Александр Пушкин, Михаил Лермонтов еш кына маниакаль-депрессив халәткә төшкән. Талантлы кешеләрдә психик чирләр гади кешегә караганда 7-8 тапкырга ешрак очрый. Ганс Христиан Андерсен, Шарль де Голль, Корней Чуковскийда Марфан синдромы күзәтелгән – аларның гәүдәсе кыска, ә аяк-куллары килбәтсез озын булган.

(“Die Presse”).

Биш күл сихәте

Омск һәм Новосибирск өлкәләре чигендә бер-берсенә якын гына 4 сулык урнашкан – Чуртан (Щучье), Карабалык (Линево), Данилино, Шайтан (яки Урман) күлләре, аларның суы да, ләме дә сихәтле. Легенда буенча, алар метеорит төшкәннән соң пәйда булган һәм җир астында бер-берсе белән тоташкан. Бишенчесе исә – Яшерен (Потаённое), анысын табуы бик кыен. Әмма борынгы ышану буенча әлеге биш күлнең барысының да суын эчкән кеше генә сихәтләнә ала. Галимнәр бишенче күлне эзләп хәлдән тайган, җирле халык исә аның серен ачмый. Геофизиклар фикеренчә, дүрт күлне җир астында тоташтырган сулык – бишенче күл ул. Нәкъ менә шул сулык җир өстендәге күлләрне көмеш ионнары һәм микроэлементлар белән баета, шунлыктан әлеге “тереклек” суы озак еллар буе бозылмыйча саклана һәм искиткеч шифага ия. Ул эренле җәрәхәтләрне бик тиз җыя, экзема һәм псориаздан, бавыр циррозыннан һәм хәтта яман шештән дәвалый. Шайтан күле уртасындагы таш кыяга кагылсаң, төзәлмәс чирдән дә сихәтләнәсең, дигән инану да яши. Әмма таш янына саф күңелле, ачык йөрәкле, игелекле кеше генә йөзеп барып җитә ала. Кыяга юнәлгән әллә ничә моторлы көймә, аның янына барып җитә алмыйча, әйләнеп капланган инде.

(“Интересно.cc”).

Нәрсә бирәләр – шуны ашыйсың

Япониядәге Касива шәһәрендәге бер бик популяр ресторанда официантның үзенә нинди ризык китерәсен бер клиент та белми. Эш шунда: яңа кунак өчен сый-хөрмәтне аңа кадәр килгән кеше сайлап калдыра. Кызыксыну бик көчле булганга, халык бирегә агыла гына, барысының да “сюрприз-ризык” белән сыйланасы килә.

(“Лента.ру”).

Җилләткечле кием

Япониядә быел җәй бик эссе булып, Токиода температура ун көн рәттән 35 градустан түбән төшмәгән. Шунлыктан эт һәм песиләрне эсседән саклый торган җилләткечле киемнәр сатуга чыгарылган. Аны йөкле хатыннар өчен кием бренды президенты Рей Удзава башта үзенең кызудан интегүче чихуахуасы өчен уйлап тапкан. Челтәрсыман киҗе-мамык тукымадан тегелгән комбинезонга батарейкасы белән бергә 80 грамм авырлыктагы җилләткеч беркетелгән. Ул эшләгәндә, салкынча һава хайванның бөтен тәнен урап ала һәм суыта. Удзавага тиз арада йөздән артык кеше шундый киемгә заказ биргән. Комбинезон биш үлчәмдә тегелә, 9,9 иена (4,5 мең сум чамасы) тора.

(“Reuters”).

Тоборочи агачы

Тоборочи яки чоризия агачы Боливия тропикларында үсә. Аның кәүсәсе бик кызыклы – шешәгә охшаган, уртага таба юаная да, аннары тагын тарая. Кайрысы эре чәнечкеләр белән капланган. Җимешләре шартлагач, анда пәйда булган йомшак мамыксыман матдәне җирле халык мендәр һәм юрган эченә тутыра.

(“Вокруг света”).

Газета өчен Алсу ЗӘЙДУЛЛИНА әзерләде.

Дүшәмбе

3 октябрь

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»
5.35, 14.45 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
5.50, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 12+
6.00, 7.10 «Манзара». 6+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 12+
8.10 «Здравствуйте!» 12+
9.00, 17.00 «КИТӘМ, ДИМӘ». 12+
10.00, 23.00 «ГОСПОДА - ТОВАРИЩИ». 16+
11.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 12+
11.30, 21.00 «Заман көзгесе». 6+
12.00, 22.10 «ШУЛЕР». 16+
13.00 «Семь дней». 12+
14.00 «Закон. Парламент. Общество». 12+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә».
16.00 «Переведи!» 6+
16.30 «Татарлар». 12+
18.00 «Әдәби хәзинә». 6+
19.00, 20.00, 0.15 «Таяну ноктасы». 16+
22.00 «Вызов 112». 16+
23.50 «Соотечественники». 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА
5.35 «Шаян хәлләр». 12+
6.00, 13.05 «Манзара». 6+
8.00, 17.00 «Үткәннәр сагындыра». 6+
8.40, 23.05 «Башваткыч». 12+
9.50 «Семь дней». 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 12+
11.30 «Заман көзгесе». 6+
12.05 «Кояш яшерән малай». Нуретдин Нәҗмиев турында телеочерк. 6+
15.30, 0.15 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 12+
16.00 «Әдәби хәзинә». 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
18.20 «СИҢА КАЙТАМ». 12+
19.10, 21.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
20.00 «Таяну ноктасы». 16+
22.20 «Татар теле дәресләре». 6+

«ЭФИР»
5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «ЧУЖОЕ ГНЕЗДО». 12+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30 «ПРИТВОРЩИКИ». 12+
11.30 «ЛЕСТНИЦА В НЕБЕСА». 16+
12.30, 18.40 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.45 «УМНИК». 16+
15.00 «Еда здорового человека». 12+
15.30 «Мечтатели». 12+
16.30 «ПОКА СТАНИЦА СПИТ». 12+
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+
20.00 «ИСЧЕЗНУВШАЯ». 16+
21.00 «ВЕРНИ МОЮ ЛЮБОВЬ». 12+

«1 НЧЕ КАНАЛ»
5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
9.55 «Жить здорово!» 16+
10.45, 12.15, 15.15, 18.20, 23.45 Информационный канал. 16+
21.00 «Время».
21.45 «СОБОР». 16+
22.45 «Большая игра». 16+

«РОССИЯ»
5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
16.30 «Малахов». 16+
21.20 «ЧАЙКИ». 12+
22.20 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»
6.30, 7.00, 7.30, 8.30, 10.00, 15.00, 19.30, 23.50 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.05 Невский ковчег. Теория невозможного. Евгений Боткин.
7.35 Черные дыры. Белые пятна.
8.15 Дороги старых мастеров. «Лики неба и земли».
8.35 «ВРЕМЯ ОТДЫХА С СУББОТЫ ДО ПОНЕДЕЛЬНИКА».
10.15 «Наблюдатель».
11.10 «Майя Плисецкая. Знакомая и незнакомая».
12.10 «Планета Михаила Аникушина».
12.55, 22.00 «СПРУТ-3».
14.05 Линия жизни. Александр Митрошенков.
15.05 Новости. Подробно. АРТ.
15.20 «Агора».
16.20 «Испания. Теруэль».
16.50 «НАШЕ ПРИЗВАНИЕ».
18.05 Музыка эпохи барокко. Ансамбль I Gemelli. «Вечерня Пресвятой Богородицы».
19.00 Уроки русского. Чтения. Антон Чехов. «Крыжовник». Читает Виктор Добронравов.
19.45 Главная роль.
20.05 «Правила жизни».
20.30 «Лев Зильбер. Ангел счастья - ангел несчастья».
21.20 «Сати. Нескучная классика...»
23.05 «ЦСДФ: Точка отсчета».

«НТВ»
4.55 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня».
8.25, 10.35 «ЛЕСНИК». 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «Место встречи».
16.45 «За гранью». 16+
17.50 «ДНК». 16+
20.00 «ЛИХАЧ». 16+
22.00, 0.00 «БАЛАБОЛ». 16+

Сишәмбе

4 октябрь

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»
5.35, 14.45 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
5.50, 7.00 Татарстан хәбәрләре. 12+
6.00, 7.10 «Манзара». 6+
8.00, 14.30, 18.30, 19.00 Новости Татарстана. 12+
8.10 «Здравствуйте!» 12+
9.00, 17.00 «КИТӘМ, ДИМӘ». 12+
10.00, 23.00 «ГОСПОДА - ТОВАРИЩИ». 16+
11.00 «Фолиант в столетнем переплёте». 12+
11.15 «Память сердца». 12+
11.30, 16.30 «Татарлар». 12+
12.00, 22.10 «ШУЛЕР». 16+
13.00 «Туган җир». 12+
13.30 «Юлчы». 6+
14.00 «Путь». 12+
14.15 «Не от мира сего...» 12+
15.15 «Тәймә».
16.00 «Казаннан - казанга». 12+
18.00 «Таяну ноктасы». 16+
19.30 Хоккей. «Ак Барс» - «Автомобилист». 6+
22.00 «Вызов 112». 16+
23.50 «Видеоспорт». 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА
5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
6.00, 13.05 «Манзара». 6+
8.00, 17.00 «Үткәннәр сагындыра». 6+
8.40, 23.05 «Җырлыйк әле!» 6+
9.40 «Туган җир». 12+
10.30, 20.30 «Халкым минем». 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 12+
11.30, 17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
12.05, 20.00 «Таяну ноктасы». 16+
15.30 «Ватандашлар». 6+
16.00 «Әдәби хәзинә». 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
18.20 «СИҢА КАЙТАМ». 12+
19.10, 21.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
22.20 «Татар теле дәресләре». 6+

«ЭФИР»
5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «ЧУЖОЕ ГНЕЗДО». 12+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «ИСЧЕЗНУВШАЯ». 16+
10.30, 21.00 «ВЕРНИ МОЮ ЛЮБОВЬ». 12+
11.30 «ЛЕСТНИЦА В НЕБЕСА». 16+
12.30, 18.40 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.45 «УМНИК». 16+
15.00 «Без химии». 12+
15.30 «Мечтатели». 12+
16.30 «ПОКА СТАНИЦА СПИТ». 12+
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»
5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
9.55 «Жить здорово!» 16+
10.45, 12.15, 15.15, 18.20, 23.45 Информационный канал. 16+
21.00 «Время».
21.45 «СОБОР». 16+
22.45 «Большая игра». 16+

«РОССИЯ»
5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
16.30 «Малахов». 16+
21.20 «ЧАЙКИ». 12+
22.20 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»
6.30, 7.00, 7.30, 8.30, 10.00, 15.00, 19.30, 23.50 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.05 Легенды мирового кино.
7.35 «Величайшая победа Цезаря. Осада Алезии».
8.35 Цвет времени. Ван Дейк.
8.45, 16.50 «НАШЕ ПРИЗВАНИЕ».
10.15 «Наблюдатель».
11.10 «Королев».
12.15, 16.35 «Забытое ремесло».
12.35, 22.00 «СПРУТ-3».
13.35 Цвет времени. Надя Рушева.
13.45 «История русской еды».
14.15, 23.05 «ЦСДФ: Точка отсчета».
15.05 Новости. Подробно. Книги.
15.20 «Передвижники. Алексей Боголюбов».
15.50 «Сати. Нескучная классика...»
18.05 Музыка эпохи барокко. «Ночь королей». Жорди Саваль, Оркестр Le Concert des Nations и Королевская капелла Каталонии.
19.00 Уроки русского. Чтения. Марина Цветаева. «Мой Пушкин». Читает Юлия Снигирь.
19.45 Главная роль.
20.05 «Правила жизни».
20.30 Дневники конкурса «Учитель года».
21.20 «Белая студия».

«НТВ»
4.55 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня».
8.25, 10.35 «ЛЕСНИК». 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «Место встречи».
16.45 «За гранью». 16+
17.50 «ДНК». 16+
20.00 «ЛИХАЧ». 16+
22.00, 0.00 «БАЛАБОЛ». 16+

Чәршәмбе

5 октябрь

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»
5.35, 14.45 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
5.50, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 12+
6.00, 7.10 «Манзара». 6+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 12+
8.10 «Здравствуйте!» 12+
9.00, 17.00 «КИТӘМ, ДИМӘ». 12+
10.00, 23.00 «ГОСПОДА - ТОВАРИЩИ». 16+
11.00 «Каравай». 6+
11.30, 16.30 «Татарлар». 12+
12.00, 22.10 «ШУЛЕР». 16+
13.00 «Җырлыйк әле!» 6+
14.00 «Азбука долголетия». 6+
14.15 «Если хочешь быть здоровым...» 12+
15.15 «Бергәләп өйрәник».
16.00 «Переведи!» 6+
18.00, 0.40 «Халкым минем...» 12+
19.00 «Таяну ноктасы». 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112». 16+
20.15 «Туган авылым». 6+
21.00 Документальный фильм. 12+
23.50 «Соотечественники». 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА
5.05, 8.35, 23.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
6.00, 13.05 «Манзара». 6+
8.00, 17.00 «Үткәннәр сагындыра». 6+
9.35 «Ачыктан - ачык». 12+
10.40 «Туган авылым». 6+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 12+
11.30, 17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
12.05, 20.00 «Таяну ноктасы». 16+
12.35 «Ватандашлар». 6+
15.30, 0.15 «Яшьләр тукталышы». 12+
16.00 «Әдәби хәзинә». 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
18.20 «СИҢА КАЙТАМ». 12+
19.10, 21.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
20.30 «Юлчы». 6+
22.20 «Татар теле дәресләре». 6+

«ЭФИР»
5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «ЧУЖОЕ ГНЕЗДО». 12+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «ИСЧЕЗНУВШАЯ». 16+
10.30, 21.00 «ВЕРНИ МОЮ ЛЮБОВЬ». 12+
11.30 «ЛЕСТНИЦА В НЕБЕСА». 16+
12.30, 18.40 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.45 «УМНИК». 16+
15.00 «Еда здорового человека». 12+
15.30 «Мечтатели». 12+
16.30 «ПОКА СТАНИЦА СПИТ». 12+
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»
5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
9.55 «Жить здорово!» 16+
10.45, 12.15, 15.15, 18.20, 23.45 Информационный канал. 16+
21.00 «Время».
21.45 «СОБОР». 16+
22.45 «Большая игра». 16+

«РОССИЯ»
5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
16.30 «Малахов». 16+
21.20 «ЧАЙКИ». 12+
22.20 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»
6.30, 7.00, 7.30, 8.30, 10.00, 15.00, 19.30, 23.50 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.05 Легенды мирового кино.
7.35 «Скитания капитана армады».
8.35 Цвет времени. Камера-обскура.
8.45, 16.50 «НАШЕ ПРИЗВАНИЕ».
10.15 «Наблюдатель».
11.10 «Королев».
12.15, 16.35 «Забытое ремесло».
12.35, 22.00 «СПРУТ-3».
13.45 «История русской еды».
14.15, 23.05 «ЦСДФ: Точка отсчета».
15.05 Новости. Подробно. Кино.
15.20 «Библейский сюжет».
15.50 «Белая студия».
17.55 Музыка эпохи барокко. Соня Йончева и ансамбль Cappella Mediterranea. Арии из опер.
19.00 Уроки русского. Чтения. Александр Грин. «Зелёная лампа», «Любимый». Читает Анатолий Лобоцкий.
19.45 Главная роль.
20.05 «Правила жизни».
20.30 Абсолютный слух.
21.15 Власть факта. «Макиавелли: политика и мораль».

«НТВ»
4.55 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня».
8.25, 10.35 «ЛЕСНИК». 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «Место встречи».
16.45 «За гранью». 16+
17.50 «ДНК». 16+
20.00 «ЛИХАЧ». 16+
22.00, 0.00 «БАЛАБОЛ». 16+

Пәнҗешәмбе

6 октябрь

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»
5.35, 14.45 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
5.50, 7.00, 18.30 Татарстан хәбәрләре. 12+
6.00, 7.10 «Манзара». 6+
8.00, 14.30, 19.00 Новости Татарстана. 12+
8.10 «Здравствуйте!» 12+
9.00, 17.00 «КИТӘМ, ДИМӘ». 12+
10.00, 23.00 «ГОСПОДА - ТОВАРИЩИ». 16+
11.00 «Каравай». 6+
11.30, 16.30 «Татарлар». 12+
12.00, 22.10 «ШУЛЕР». 16+
13.00 «Кәмит Җәвит». 16+
14.00 «Туган авылым». 6+
14.15 «Фолиант в столетнем переплёте». 12+
15.15 «Шома бас» һәм «Алты хәреф». 12+
16.00 «Казаннан - казанга». 12+
18.00 «Юлчы». 6+
19.30 Хоккей. «Ак Барс» - «Автомобилист». 6+
22.00 «Вызов 112». 16+
23.50 «Видеоспорт». 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА
5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
6.00, 13.05 «Манзара». 6+
8.00, 17.00 «Үткәннәр сагындыра». 6+
8.40, 23.05 «Кәмит Җәвит». 16+
9.40 «Кунак БИТ Шоу». 12+
10.40 «Туган авылым». 6+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 12+
11.30, 17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
12.05 «Таяну ноктасы». 16+
12.35 «Ватандашлар». 6+
15.30, 0.15 «Халкым минем». 12+
16.00 «Әдәби хәзинә». 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
18.20 «СИҢА КАЙТАМ». 12+
19.10, 20.00, 21.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
22.20 «Татар теле дәресләре». 6+

«ЭФИР»
5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «ЧУЖОЕ ГНЕЗДО». 12+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «ИСЧЕЗНУВШАЯ». 16+
10.30, 21.00 «ВЕРНИ МОЮ ЛЮБОВЬ». 12+
11.30 «ЛЕСТНИЦА В НЕБЕСА». 16+
12.30, 18.40 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.45 «УМНИК». 16+
15.00 «Клинический случай». 12+
15.30 «Мечтатели». 12+
16.30 «ПОКА СТАНИЦА СПИТ». 12+
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»
5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
9.55 «Жить здорово!» 16+
10.45, 12.15, 15.15, 18.20, 23.55 Информационный канал. 16+
21.00 «Время».
21.45 «СОБОР». 16+
22.55 «Большая игра». 16+

«РОССИЯ»
5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+

11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
16.30 «Малахов». 16+
21.20 «ЧАЙКИ». 12+
22.20 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»
6.30, 7.00, 7.30, 8.30, 10.00, 15.00, 19.30, 23.50 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.05 Легенды мирового кино.
7.35 «Парящий каменный лес Китая».
8.35 «Забытое ремесло».
8.50 «НАШЕ ПРИЗВАНИЕ».
10.15 «Наблюдатель».
11.10 XX век. «В гостях у Николая Озерова».
12.35, 22.00 «СПРУТ-3».
13.45 «История русской еды».
14.15, 23.05 «ЦСДФ: Точка отсчета».
15.05 Новости. Подробно. Театр.
15.20 Пряничный домик. «Мастера Самарского края».
15.50 «Первые в мире».
16.05 Спектакль «Лунев сегодня и завтра».
17.15 Большие и маленькие.
19.45 Главная роль.
20.05 Открытая книга. Анна Бабяшкина. «И это взойдет».
20.30 «Любовь и голуби». Что характерно! Любили друг друга!»
21.15 «Энигма. Франгиз Ализаде».

«НТВ»
4.55 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня».
8.25, 10.35 «ЛЕСНИК». 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «Место встречи».
16.45 «За гранью». 16+
17.50 «ДНК». 16+
20.00 «ЛИХАЧ». 16+
22.00, 0.00 «БАЛАБОЛ». 16+

Җомга

7 октябрь

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»
5.35, 14.45 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
5.50, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 12+
6.00, 7.10 «Манзара». 6+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 12+
8.10 «Здравствуйте!» 12+
9.00, 17.00 «КИТӘМ, ДИМӘ». 12+
10.00 «Йөрәктән - йөрәккә». 6+
11.00 «Нәсыйхәт». 6+
11.30 «Татарлар». 12+
12.00, 23.10 «ШУЛЕР». 16+
13.00 «Башваткыч». 12+
14.00 «Актуальный ислам». 6+
14.15 «Классный час». 12+
15.15 «Тизрәк! Алга! Җитезрәк!» һәм «Алты хәреф».
16.00 «Аулак өй». 6+
16.30 «Әдәби хәзинә». 6+
18.00 «Туган җир». 12+
19.00, 20.00 «Точка опоры». 16+
21.00 «Юлчы». 6+
22.00 «Вызов 112». 16+
22.10 «КВН РТ-2022». 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА
5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
6.00, 13.05 «Манзара». 6+
8.00, 17.00 «Үткәннәр сагындыра». 6+
8.40, 23.05 «Ком сәгате». 12+
9.40, 15.30, 0.15 «Нәсыйхәт». 6+
10.30 «Казаннан казанга». 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 12+
11.30 «Татарлар». 12+
12.05 «Йөрәктән-йөрәккә». Харис Мусин турында телеочерк. 6+
16.00 «Әдәби хәзинә». 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
17.30, 0.40 «Калеб». 6+
18.20 «СИҢА КАЙТАМ». 12+
19.15 «Туган җир». 12+
19.40 «Заман көзгесе». 6+
20.10, 21.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
22.20 «Татар теле дәресләре». 6+

«ЭФИР»
5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «ЧУЖОЕ ГНЕЗДО». 12+
9.25, 11.25, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «ИСЧЕЗНУВШАЯ». 16+
10.30, 21.00 «ВЕРНИ МОЮ ЛЮБОВЬ». 12+
11.30 «ЛЕСТНИЦА В НЕБЕСА». 16+
12.30 «Обыкновенные рецепты здоровья». 16+
13.00, 23.45 «ГОРОД АНГЕЛОВ». 12+
15.00 «Без химии». 12+
15.30 «Мировой рынок». 12+
16.30 «ПОКА СТАНИЦА СПИТ». 12+
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+
18.30 «Fam TV». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»
5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
9.55 «Жить здорово!» 16+
10.45, 12.15, 15.15 Информационный канал. 16+
18.40 «Человек и закон». 16+
19.45 «Поле чудес».
21.00 «Время».
21.45 Фантастика. 12+

«РОССИЯ»
5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.15 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
16.30 «Малахов». 16+
21.30 «Ну-ка, все вместе!» 12+
23.45 «Улыбка на ночь». 16+

«КУЛЬТУРА»
6.30, 7.00, 7.30, 10.00, 15.00, 19.30, 23.20 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.05 Легенды мирового кино.
7.35 «Десять колец Марины Цветаевой».
8.25 «Я - ВОЖАТЫЙ ФОРПОСТА».
10.20 «ГРОЗА».
12.00 Открытая книга. Анна Бабяшкина. «И это взойдет».
12.30, 22.15 «СПРУТ-3».
13.30, 17.25 «Первые в мире».
13.45 «История русской еды».
14.15 «ЦСДФ: Точка отсчета».
15.05 Письма из провинции.
15.35 «Энигма. Франгиз Ализаде».
16.20 Спектакль «Лунев сегодня и завтра».
17.40 Музыка эпохи барокко. «Пёрселл-гала». Жан Тюбери и ансамбль La Fenice.
19.00 «Смехоностальгия».
19.45 «ПО ГЛАВНОЙ УЛИЦЕ С ОРКЕСТРОМ».
21.20 Линия жизни. Александр Аузан.
23.40 «2 Верник 2».

«НТВ»
4.55 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00 «Сегодня».
8.25 «Мои университеты. Будущее за настоящим». 6+
9.25, 10.35 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ». 16+
11.05 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. СЕВЕРНЫЕ РУБЕЖИ». 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие».
14.00 «Место встречи».
16.45 «ДНК». 16+
17.55 «Жди меня». 12+
20.00 «ЛИХАЧ». 16+
22.00 «БАЛАБОЛ». 16+
23.55 «Своя правда». 16+

Шимбә

8 октябрь

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»
5.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
6.00 «Йөрәктән - йөрәккә». 6+
7.00 «Сиңа Миннән Сәлам». 6+
9.00 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
10.00 «Кайнар хит». 12+
11.00 «Туган авылым». 6+
11.30 «Казаннан - казанга». 12+
12.00 «Каравай». 6+
12.30 «Видеоспорт». 12+
13.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 12+
13.30 «ТУЗГАН ТОРАКТАН КҮЧКӘНДӘ». 12+
17.00 Хоккей. «Ак Барс» - «Барыс». 6+
19.30, 21.30 Новости в субботу. 12+
20.00 «Адымнар». 12+
20.30 «Җырлыйк әле!» 6+
22.00 «КунакБит- шоу». 12+
23.15 «ОН И ОНА». 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА
5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
6.00 «Йөрәктән-йөрәккә». Дамир Сираҗиев турында телеочерк. 6+
7.00, 15.00 «Сиңа Миннән Сәлам». 6+
9.00 «Кәмит Җәвит». 16+
10.00 «Кайнар хит». 12+
11.00, 18.15 «Башваткыч». 12+
12.05, 19.05 «Җырлыйк әле!» 6+
13.00 «Туган авылым». 6+
13.20 Спектакль «Кияү белән кәләш». 12+
17.10 «Казаннан казанга». 12+
17.45 «Халкым минем». 12+
20.00 «Адымнар». 12+
20.30 «Гомер бик сизгер икән». Ринат Мөслимов җырларыннан концерт. 12+
23.10 Спектакль «Мәхәббәт кошлары». 12+

«ЭФИР»
5.00 «Фронтовая Москва. История победы». 12+
5.30, 14.30 «Россия. Связь времен». 12+
6.00 «Десять месяцев, которые потрясли мир». 12+
6.30 «Клинический случай». 12+
7.00 «Катя и Эф. Куда-Угодно-Дверь».
7.30 «Лео и Тиг».
8.00 «Россия. Вне зоны доступа». 12+
8.45 «ПАРФЮМЕРША». 12+
12.00, 20.00 «Fam TV». 16+
12.30, 20.30 «Обыкновенные рецепты здоровья». 16+
13.00 «КАК ВОСПИТАТЬ МУЖА». 16+
15.00 «Клятва Гиппократа». 12+
15.30 «СЕМЕЙНЫЙ БИЗНЕС». 12+
19.00 «Город». 16+
21.00 «ХОТЕЛ БЫ Я БЫТЬ ЗДЕСЬ». 12+
22.50 «ХИМИК». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»
6.00 «Доброе утро. Суббота».
9.00 «Умницы и умники». 12+
9.45 «Слово пастыря».
10.00, 12.00, 18.00 Новости.
10.15 «ПроУют».
11.10 «Поехали!» 12+
12.15 «Видели видео?»
14.45 «Космическая Одиссея. Портал в будущее».
15.50 «А У НАС ВО ДВОРЕ...» 12+
18.20 «Сегодня вечером». 16+
21.00 «Время».
21.35 «КВН». 16+
23.40 «Мой друг Жванецкий». 12+

«РОССИЯ»
5.00 «Утро России. Суббота».
8.00 Вести. Местное время.
8.20 Местное время. Суббота.
8.35 «По секрету всему свету».
9.00 «Формула еды». 12+
9.25 «Пятеро на одного».
10.10 «Сто к одному».
11.00, 17.00, 20.00 Вести.
12.00 «Доктор Мясников». 12+
13.05 «СЕРДЦЕ МАТЕРИ». 16+
18.00 «Привет, Андрей!» 12+
21.00 «ДОЧЕНЬКИ». 12+

«КУЛЬТУРА»
6.30 «Сергий Радонежский. Путь подвижника».
7.05 Мультфильмы.
7.50 «Я ТЕБЯ НЕНАВИЖУ».
9.10 «Мы - грамотеи!»
9.50 Неизвестные маршруты России. «Тверская область. Из Торжка в Калязин».
10.30 «ПО ГЛАВНОЙ УЛИЦЕ С ОРКЕСТРОМ».
12.00 Земля людей. «Саамы. Олени красивей всех!»
12.30 Черные дыры. Белые пятна.
13.10 «Великие мифы. Одиссея».
13.40 «Путешествие к спасительным берегам Мексики».
14.35 «Рассказы из русской истории». Владимир Мединский.
16.00 «Забытое ремесло».
16.15 Больше, чем любовь.
16.55 «В ОГНЕ БРОДА НЕТ».
18.30 «Видеть невидимое».
19.10 «Энциклопедия загадок».
19.40 «СКАЗАНИЕ О РУСТАМЕ».
22.00 «Агора».
23.00 Клуб «Шаболовка, 37».

«НТВ»
5.10 «Спето в СССР». 12+
5.55 «ИНСПЕКТОР КУПЕР». 16+
7.30 «Смотр».
8.00, 10.00, 16.00 «Сегодня».
8.20 «Поедем, поедим!»
9.20 «Едим дома».
10.20 «Главная дорога». 16+
11.00 «Живая еда». 12+
12.00 «Квартирный вопрос».
13.00 «Секрет на миллион». 16+
15.00 «Своя игра».
16.20 «ЧП. Расследование». 16+
17.00 «Следствие вели...» 16+
19.00 «Центральное телевидение».
20.10 «Шоу Аватар». 12+
22.50 «Ты не поверишь!» 16+
23.50 «Международная пилорама». 16+

Якшәмбе

9 октябрь

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»
5.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 16+
6.00 «Саф хисле мәхәббәт». Филүс Каһиров концерты. 6+
8.00, 13.00 «Адымнар». 12+
8.30 Мультфильм. 6+
8.45 «Әти һәм мин».
9.15 «Тамчы- шоу».
9.45 «Яшьләр тукталышы». 12+
10.15 «Ачыктан - ачык». 12+
11.00 «Туган авылым». 6+
11.20 «Пар алма». Илназ Баһ. 6+
12.00 «Каравай». 6+
12.30 «Закон. Парламент. Общество». 12+
13.30 «Наша Республика - наше дело». 12+
14.30 «Күңелемдә бер моң». Рөстәм Асаев концерты. 6+
16.00 «Ком сәгате». 12+
17.00 «Видеоспорт». 12+
17.30 «Соотечественники». 12+
18.00 «Башваткыч». 12+
19.00, 22.00 «Семь дней». 12+
20.00 «Заман көзгесе». 6+
20.30 «Болгар радиосы» концерты. 6+
21.00 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
23.00 «ПОКА СВАДЬБА НЕ РАЗЛУЧИТ НАС». 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА
5.05, 12.35 «Халкым минем». 12+
5.30 «Нәсыйхәт». 6+
6.00 «Заман көзгесе». 6+
6.30 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 12+
7.00 «БИЧАРАКАЙ». 12+
9.30 «Йөрәктән-йөрәккә». Харис Мусин турында телеочерк. 6+
10.30 «Калеб». 6+
11.10 «Тамчы-шоу». 6+
11.45 «Бергәләп өйрәник». 6+
12.05, 0.40 «Яшьләр тукталышы». 12+
13.00 «Туган авылым». 6+
13.20 «Йөрәктән-йөрәккә». Празат Исәнбәт турында телеочерк. 6+
13.50 Спектакль «Курчак туе». 12+
17.15 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
18.10 «Кәмит Җәвит». 16+
19.05, 23.45 «Ком сәгате». 12+
20.00 «Семь дней». 12+
21.10 «Безнең җыр». 6+
23.20 «Шаян хәлләр». 12+

«ЭФИР»
5.00 «Фронтовая Москва. История победы». 12+
5.30, 22.30 «Россия. Связь времен». 12+
6.00 «Десять месяцев, которые потрясли мир». 12+
6.30 «Без химии». 12+
7.00 «Катя и Эф. Куда-Угодно-Дверь».
7.30 «Лео и Тиг».
8.00 «Один день в городе». 12+
8.30 «СЕМЕЙНЫЙ БИЗНЕС». 12+
12.00, 20.00 «Fam TV». 16+
12.30, 20.30 «Обыкновенные рецепты здоровья». 16+
13.00 «ХОТЕЛ БЫ Я БЫТЬ ЗДЕСЬ». 12+
14.50 «Рейс в один конец. Прокуроры». 16+
15.45 «ПАРФЮМЕРША». 12+
19.00 «Город». 16+
21.00 «КАК ВОСПИТАТЬ МУЖА». 16+
23.00 «КОМНАТА». 18+

«1 НЧЕ КАНАЛ»
5.05, 6.10 «ЕГЕРЬ». 12+
6.00, 10.00, 12.00 Новости.
7.00 «Играй, гармонь любимая!» 12+
7.40 «Часовой». 12+
8.15 «Здоровье». 16+
9.20 «Мечталлион». 12+
9.40 «Непутевые заметки». 12+
10.15 Жанна Бадоева в проекте-путешествии «Жизнь других». 12+
11.10 «Повара на колесах». 12+
12.15 «Видели видео?»
14.40 «УБОЙНАЯ СИЛА». 16+
16.45, 23.45 «Романовы». 12+
18.50 «Поем на кухне всей страной». 12+
21.00 «Время».
22.35 «Что? Где? Когда?»

«РОССИЯ»
5.35 «КУЗНЕЦ МОЕГО СЧАСТЬЯ». 12+
7.15 «Устами младенца».
8.00 Местное время. Воскресенье.
8.35 «Когда все дома с Тимуром Кизяковым».
9.25 «Утренняя почта с Николаем Басковым».
10.10 «Сто к одному».
11.00, 17.00 Вести.
12.00 «Большие перемены».
13.05 «СЕРДЦЕ МАТЕРИ». 16+
18.00 «Песни от всей души». 12+
20.00 Вести недели.
22.00 Москва. Кремль. Путин.
22.40 «Воскресный вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»
6.30 «Энциклопедия загадок».
7.05 «Оранжевое горлышко».
7.25 «ДОЖДЬ В ЧУЖОМ ГОРОДЕ».
9.40 «Обыкновенный концерт».
10.10 Диалоги о животных.
10.50 Большие и маленькие.
13.05 Невский ковчег. Теория невозможного. Карл Булла.
13.35 «Игра в бисер» «Гайто Газданов. «Вечер у Клэр».
14.15 «Элементы» с Ильёй Доронченковым».
14.45 «ЖАЛЬ, ЧТО ТЫ КАНАЛЬЯ».
16.30 «Картина мира с Михаилом Ковальчуком».
17.10 «Пешком...»
17.45 Передача знаний.
18.35 «Романтика романса».
19.30 Новости культуры.
20.10 Спектакль «Женитьба».
22.10 «Белоруссия. Коссовский замок».
22.40 «Майерлинг».

«НТВ»
5.15 «ИНСПЕКТОР КУПЕР». 16+
6.45 «Центральное телевидение». 16+
8.00, 10.00, 16.00 «Сегодня».
8.20 «У нас выигрывают!» 12+
10.20 «Первая передача». 16+
11.00 «Чудо техники». 12+
11.55 «Дачный ответ».
13.00 «НашПотребНадзор». 16+
14.05 «Однажды...» 16+
15.00 «Своя игра».
16.20 «Следствие вели...» 16+
18.00 «Новые русские сенсации». 16+
19.00 Итоги недели.
20.20 «Ты супер!» 6+
23.00 «Звезды сошлись». 16+

Исерек ахмаклыклар

Ел саен республикада дистәләрчә кеше үтерелә. Алар арасында аек баштан кылынган җинаять корбаннары санаулы гына. Исерекләр исә ата-анасын да, туганны һәм дусларны да аямый.

42 яшьлек Роза Насыйбуллина, эчкече, әфьюн һәм башка наркотик матдәләр кулланучы буларак, 2010 елда ук исәпкә куелган. 2013 елда наркоманнар притоны оештырган, наркотиклар саткан өчен, ике мәртәбә хөкем ителеп өч ел утырып та кайткан. Акылга утырмаган, билгеле. Үзе кибетләрдә идән юып акча эшләм дисә дә, аның 1957 елгы инвалид әнисе Надежда пенсиясенә яшәве мәгълүм. Кыйммәтле наркотиклар алу мөмкинлеге булмагач, нәфесен хәмер белән баса ул.

Надежда Насыйбуллина 1989 елдан бирле «шизофрения» дигән диагноз белән Әлмәттәге психиатрия диспансерында исәптә тора. Әлеге дәваханә табибе А.Сәйфуллин аның чиренең көчле булмавын, ай саен үзе генә килеп йөрүен, мөстәкыйль яшәргә сәләтле икәнен әйтә, шуңа күрә опекун да билгеләнмәде, ди. Туганнары һәм күрше-күлән дә карчыкны тәртипле, тыныч, пөхтә, бигрәк тә эчми торган икәнен белдереп уңай бәялиләр. Якындагы кибет сатучысы башкалардан аерылмый иде, аралаштык, бары тик кайчак сөйләмендә кыска тоткарлыклар булгалый иде, ди. Шулай ук эчми-тартмый торган өлкән кешенең сыра, сигарет алуын да искә төшерә ул. Ошбу әйберләрнең кем өчен икәнлеге аңлашыла торгандыр.

Күргән-белгәннәр арасында Роза турында уңай сөйләүчеләр юк. Иң әүвәл, һәрдаим эчеп йөрүче ханымның әнисенә җикеренеп кычкыруларын, кул астына эләккән әйберләрне ыргытуларын һәм башка начарлыкларын әйтәләр. Әлбәттә, бу өйдә вәзгыять кискенләшү өчен сәбәпкә мөмкинлекләр күп була. Әни кеше исерек кызына эндәшми калмый яисә махмырдан интеккәндә акча бирми һәм башкалар. Роза исә боларны телгә алмый, әнисен тиктомалдан холыксызлана торган, әйтик, пешергән ашын яманлап теңкәгә тиючән кеше итеп сурәтли. Бу хакта сөйләгәндә: «Кайчан да булса минем түземлегем соңгы чиккә җитәргә мөмкин иде», – дип үзен бик тә иза чигүче кеше итеп күрсәтергә тырыша. Хәер, моны күбрәк кылган явызлыгын аклау йөзеннән еш-еш кабатлый ул. Чөнки быелгы Яңа ел бәйрәмнәре арасында, үзе әйтмешли, аның түземлеге төкәнә.

6 гыйнвар кичендә Р.Насыйбуллина янына Мамадыш районындагы колония–поселениедә танышкан сөйгәне Егор (исем үзгәртелә) килеп керә. Бер-берсен «сожитель» дип атасалар да, даими рәвештә бергә тормый алар. Әйтүләренчә, бергәләп сыйлангач вә гашыйклар арасында була торган гамәлләрне кылгач, Егор өенә кайтып китә. Бу юлы да хәмерле кичә шул рәвешле башланып китә, әмма кухняда салып утырганнан соң, кунак зал идәнендәге матраста яткан карчыкны күрә, кызы аның күлмәк итәген күтәреп кендектән түбәнрәк булган бер җәрәхәтне күрсәтә һәм узган төндә кызып китеп пычак чәнчүен дә җиткерә, үзем дә сизми калдым дип, сәбәбен аңлата алмый. Егорның әйтүенә караганда, ул чакта ярадан кан саркымый, хак булса, Надежда әби ашыгыч ярдәм чакыртырга да теләми. Шул рәвешле, яшьләр йокы бүлмәсенә керә, иртә белән ир заты чыгып китә.

Ул вакытта, ягъни 7 гыйнвар иртәсендә Н.Насыйбуллина исән була әле, ләкин бернинди ярдәм күрсәтелмәгәч, газапланып үлә. Соңрак үткәрелгән суд-медицина экспертизасы аның, эчке әгъзалары киселү сәбәпле, корсак куышлыгына зур күләмдә кан җыелуын күрсәтә. Әнисенең җансыз икәнен сәрхуш хатын 8 гыйнвар иртәсендә күреп, кирәкле хезмәтләргә шалтырата. Ашыгыч ярдәм табибе 64 яшьлек Н.Насыйбуллинаның үле икәнен рәсмиләштерә.

Тикшерү комитетының Әлмәт бүлегеннән Алексей Сурчилов аңлы рәвештә кеше үтерү буенча җинаять эшен шул көнне үк кузгата. Анда билгесез кешегә карата диелсә дә, Р.Насыйбуллина рәсми рәвештә тоткарлана, ике көннән суд карары белән сак астына ябыла. Чөнки аның гаебе шик уятмый. Ул үзе дә явызлыгын таный, котырынып китүен әнисенең туктаусыз әрләшеп, кычкырышып торуы белән аклап азаплана. Тикшерү барышында тоткарлыклар да килеп чыга. Мәсәлән, Р.Насыйбуллина 8 гыйнварга каршы төндә кададым дип бара, ә бу экспертиза нәтиҗәләре белән чагышмый, чөнки ул яраның 3-4 көн элек ясалуын, димәк, мескен карчыкның шулкадәр азапланып ятуын белдерә. Әлеге мәсьәләгә ачыклык кертү өчен, Егорның кирәге чыга. Ул 6 гыйнвардагы безгә мәгълүм вакыйганы сөйләп бирә, моны Роза белән кара-каршы утыртып сорау алганда да кабатлый. Хатын-кыз ул араларда бик нык эчеп йөргәнгә фикере чуалу сәбәпле, көннәрне буташтыруын таный, әнисенә 5 гыйнварга каршы төн уртасында кадавын исенә төшерә. Шушы көннәрдә Әлмәт шәһәр суды 1979 елгы Р.Насыйбуллинаны 7 елга ирегеннән мәхрүм итәргә фәрман бирде.

* * *

Күршедәге Азнакай шәһәре судында да шундый ук ике җинаять эше каралды. Пычак кадап абыйсын һәм дустын һәлак иткән ирләрнең икесе дә сигезәр елга кырыс режимлы колониягә хөкем ителде.

Руслан Гәрәев һәм Альберт Әхтәриев төрле аталардан тусалар да, кечкенәдән бер гаиләдә әниләре белән үсә. Соңгы вакытта инде ир уртасы кешеләр икесе дә эчү белән артыгын мавыга башлаган. Туган-тумача арасында ошбу хәлне 2020 ел азагында коронавирус чиреннән әниләре вафат булу белән бәйләүчеләр дә бар. Имеш, үлемне авыр кичергәннәр дә эчә башлаганнар. Әлбәттә, инде бишенче дистәне ваклаган Руслан, кырык яшенә якынлашып килүче Альбертның эчүгә сабышуын моның белән генә аклап булмастыр. Хәмер булгач агайнеләр арасында ызгыш-сугышлар ешая. Бусы инде эчүчелек нәтиҗәсе генә түгел.

Үзара мөнәсәбәтләр ата-анадан калган фатирны бүлешә алмау аркасында бозылганга охшый. Кайбер туганнары әйтүенчә, аларга мирас булып ике, шул исәптән, ерак төньяктагы фатирлары кала, әмма икесе дә Азнакайдагысын алырга теләгән, шул нияттән олы малай, әнисе үлгәч тә, гаиләсе белән шунда күченгән, еш кына Альбертны куып чыгарган, анысы күбрәк «мәгъшука»сы фатирында яшәгән. А.Әхтәриев узган елның 15 апрелендә хатын-кыз торагында була. Хуҗабикә Артурның берничә тапкыр шалтыратып энесенә сүгенүен, аның чыгымнарны киметү йөзеннән фатирындагы газ һәм утны өзүдә гаепләп җикеренүләрен әйтә. Шуннан соң исерек Әхтәриев абыйсы янына китә.

Сәрхуш бертуганнар очрашуы тыныч узмый, әлбәттә. Тиздән ызгыш, сугыш чыга. Альберт Әхтәриев исерек булганга әрләш-талаш, бәрелешнең сәбәбен дә, абыйсының ниләр әйтеп кимсетүләрен дә хәтерләми, бары тик үзен кыйнаган кешедән саклану өчен кул астына эләккән бер әйбер белән ике тапкыр күкрәгенә сугуын исенә китерә. Әйбер дигәне пычак була, билгеле. Аяныч ки, ошбу мәхшәр Русланның мәктәптә укучы улы алдында була. Малай, Альберт абыйсы чәнчегәч, әтисенең алдан тезләнүен, пычакны тартып алгач идәнгә егылуын, аңа ашыгыч ярдәм чакырырга кушуын әйтеп тора. Шуннан соң күршеләргә йөгерә ул, ләкин табибләр килеп кергәндә, әтисе үлгән була инде. Суд-медицина эксперты 1978 елгы А.Гәрәев язмышын йөрәккә зыян китергән бер җәрәхәт хәл иткән, икенче яра сәламәтлеккә җиңел дәрәҗәдәге зарар китергән дип белдерә.

Тикшерү комитетының Азнакай районара бүлеге җитәкчесе урынбасары Илмир Гәриев җинаять эшен аңлы рәвештә үтерү турындагы 105 нче маддә буенча кузгата. Зарар күрүче итеп мәрхүмнең Казанда укучы 18 яшьлек кызы билгеләнә. А.Әхтәриев гаебен өлешчә генә тануын белдерә, ягъни абыйсына ике тапкыр пычак кадавын кире какмый, әмма ошбу әйбернең пычак икәнен бары тик андагы канны сөрткәндә генә күрдем дип бара һәм үзен һөҗүмнән саклanучы дип белдерә. Әлбәттә, моның ише акланулар тикшерү барышында кире кагыла. Мисалга ул кулына очраклы рәвештә килеп эләккән дип санаучы пычак мәсьәләсен алыйк. Кухнядагы дүрт пычак магнитлы җайланмада эленеп тора һәм тартып алганда чыкылдаган тавыш чыгара. Магнит тавышын ишеттем, Альберт абыйның пычак алуын аңладым дип укучы малай да әйтеп бирә. Кыскасы, судта А.Әхтәриевның күрәләтә абыйсын үтерүе тулысынча раслана. Моңарчы хөкемгә тартылганы булмаган ир-ат сигез ел гомерен читлектә уздырачак.

* * *

Шул ук шәһәрдә яшәүче 1963 елгы Илдар Гыйльванов та олыгайган көнендә рәшәткә артына эләкте. Аның беренче хөкеме генә түгел бу. Ләкин моңа кадәр биш мәртәбә суд каршында җавап тотса да, мондый канлы җинаятьләр кылмаган ул. Беренчесендә кеше сәламәтлегенә зыян китереп 2 еллык шартлы хөкем алган, бер тапкыр урлап тотылып бер еллык төзәтү эшләренә йөргән, калган хөкемнәре барысы да кемгә дә булса үтерәм дип җикеренгән өчен бирелгән, бер мәртәбә ел ярымга колониягә дә озатылган. Боларга башлыча, эчү зәхмәте аркасында хатынынnan аерылган, рәтләп эшләмичә йөрүче икәнен дә өстик.

Аның кебекләр дусларны хәмер ярдәме белән таба, шул рәвешле шешәдәшләр төркемнәре оеша. Илдар агайның да Фирдәвес Яркәев дигән 1957 елгы әшнәсе, иң беренче чиратта бергәләп эчә торган ахирәте бар. Хәмернең дуслаштыру гына түгел, дошманлаштыра торган сәләте дә бар бит әле. Ошбу дуслар мисалы да ачык раслый моны.

Быелгы 19 март сәрхушләрнең гадәти көне булырга тиеш була. Көндез сәгать 11ләрдә Ф.Яркәевнең хәләл җефете танышлары янына чыгып китә, ялгыз калган ир кеше озак ямансулап утырмый, чөнки дусты Илдар пәйда була. Дуслар сырасыз, аракысыз гына утырмый, билгеле. Эчә торгач низаг чыгу өчен «җитди» сәбәп табыла, Гыйльвановның әйтүенә караганда, хуҗа аның улы турында начар фикер әйтеп ташлый да, аны пычак тотып һөҗүмгә күтәрелергә этәрә. Беренче карашка әллә ни хәтәр дә кыланмый ул, Фирдәвеснең җан җиренә түгел, бер-бер артлы ике ботына кадап ала. Илдар Гыйльвановның бу гамәле коточкыч нәтиҗәләргә китерә, яралардан кан ургый, бигрәк тә, сул аяктагысыннан сиптерә. Шүрли калган кунак күршеләргә ашыгыч ярдәм, полиция чакыртырга куша.

Кичке сәгать 7 тулганда, өенә кайтып килүче хуҗабикә йортлары янында торган полиция, ашыгыч ярдәм машиналарын күрә, подъездга кергәч андагы кан таплары күзгә ташлана, аларның 5 нче, ягъни аның фатирыннан башлангыч алуы да аңлашыла. Табибләр кайнашкан торагына керә алмый ул. Тиздән яралы, әмма әле исән булган ирен алып чыгып китәләр, ләкин абзый сырхауханәгә барып җиткәнче, машинада дөнья куя. Экспертиза аның, кыскача гына әйткәндә, сул боттагы төп кан тамыры киселү һәм күп кан югалту сәбәпле җан бирүен күрсәтә.

И.Гыйльванов гаебен таный. Тикшерүче Раил Газетдинов анда үтерү теләге – нияте булмаган дип саный. Чыннан да, үтерәм дигән кеше аякка кадамый бит инде. Шуңа күрә аңа аңлы рәвештә сәламәтлеккә авыр зыян китереп, саксызлык белән үтерү дигән рәсми гаепләү белдерә. Ошбу җинаять җиңелрәк саналса да, аны да 8 елга колониягә озатырга карар кылына.

Наил ВАХИТОВ.

Тынлык моңы

Ә.Мәҗитов галереясендә Чаллы рәссамы, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, Бакый Урманче премиясе иясе Рият Мөхәммәтдиновның картиналар күргәзмәсе ачылды. Анда пастель белән иҗат ителгән кырыклап иҗат эше урын алган.

Караңгы зәңгәр, күк төсләрдән гыйбарәт символизм рухындагы картиналар борынгы чорлардан калган мәгарә рәсемнәрен хәтерләтә, шуңа күрә галереягә килеп керүгә күңелне серлелек биләп ала. Рәсемнәрдә композициянең бөтенлеге соклану уята. Рәссам гүя кылкаләмен кәгазь битеннән аерып та тормыйча, аларны бер утыруда иҗат иткән. Мондый виртуозлык күп еллык тәҗрибә белән генә килә. Түгәрәкләп корылган композицияләрнең байтак булуы бу рәссамның иҗатына фәлсәфи яңгыраш өсти. Түгәрәк – яшьлекне һәм картлыкны, яшәүне һәм үлемне үз эченә алган тормыш символы. Түгәрәкләп корылган рәсемнәрдә тормышта һәр көн очраган әйберләр дә яңа яктан ачыла, әллә нинди серле булып күренә.

Р.Мөхәммәтдинов күпләргә «Тамга» иҗат берләшмәсе аша да яхшы таныш. 1990 елларда барлыкка килгән һәм ерак үткәннәргә караш ташлап иҗат итүче Зиннур Миннәхмәтов, Рабис Сәлахов, Хәмзә Шәрипов, Мадияр Хаҗиев, Сәгыйдә Сираҗиева, Хәмит Латыйпов, Рания Хәйруллина һ.б. рәссамнарны берләштергән «Тамга» оешмасының күргәзмәләре, республикабызда гөрләп узу өстенә, Мәскәүдә, Йошкар-Ола, Ижау, Уфа, Төркиянең Анкара, Казахстанның Уральск шәһәрләрендә сәнгать сөючеләрдә зур кызыксыну уяткан иде. Аннан соң байтак еллар үтсә дә, «Тамга»чыларның осталыгы камилләшә генә барды.

Шунысы әһәмиятле, рәссам Р.Мөхәммәтдинов үзе иҗат итеп кенә калмый, Чаллы шәһәренең 1 нче сәнгать мәктәбендә балаларга иҗат күнекмәләре бирә. Яшь буынның Р.Мөхәммәтдиновта укуы аеруча сөенечле, чөнки тышкы кыяфәте белән мәһабәт чегән бароннарына охшаса да, чын милли рәссамыбыз ул. 70 яше уңаеннан оештырылган бу экспозициядә Рият әфәндене кыйбласы дөрес, калебе ак булуына тагын бер кат инандык.

Миләүшә ГАЛИУЛЛИНА.

● «Каз канаты».

● «Утырган хатын-кыз портреты».

● «Никах».

● «Чигүче».

● «Кара-каршы утырып сөйләшү».



Мәдәни җомга

ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ – «ТАТМЕДИА» АКЦИОНЕРЛЫК ҖӘМГЫЯТЕ

«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы директоры – баш мөхәррир

Вахит Шәих улы ИМАМОВ

Җаваплы сәркатип Илгизәр ЗӘКИЕВ

Шылтыратыгыз:

222-09-83 (1562) – кабул итү бүлмәсе;

222-05-47 (1560) – җаваплы сәркатип, компьютер үзәге;

222-05-47 (1561) – иҗтимагый-сәяси тормыш, мәгариф һәм фән, сәнгать бүлекләре; хатлар һәм социаль көнкүреш, тәрҗемә бүлекләре;

222-09-84 (1266) – бухгалтерия.

Реклама хезмәте телефоны: (843)222-05-47 (1560)

Газета Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм гаммәви коммуникацияләр өлкәсенә күзәтчелек итү федераль хезмәтендә (Роскомнадзор) 2019 елның 9 октябрендә ПИ №ФС 77–76961 нче санлы теркәү таныклыгы алды

Индекс П2355

Авторлар фикере редакция фикере белән аваздаш булмаска да мөмкин

Редакциянең рәсми оешмаларда юллаучы булып йөрү мөмкинлеге юк

Хатлар, кулъязмалар, фотографияләр, рәсемнәргә бәяләмә бирелми һәм алар кире кайтарылмый

© Газетада чыккан материалларны күчереп бастырганда редакциядән язмача рөхсәт алу мәҗбүри

Реклама һәм белдерүләрнең төгәллеге өчен реклама бирүчеләр үзләре җаваплы

Безгә иганәлек ярдәме күрсәтергә теләүчеләр өчен редакциянең исәп-хисап счеты:

ИНН 1655144950 КПП 165802012
ПАО «АК БАРС» банк,
г. Казань
р/с 40702810600020010312
к/с 30101810000000000805
БИК 049205805 ОГРН 1021600000124

НӘШЕР ИТҮЧЕ – «ТАТМЕДИА» АҖ

420097, Казан, Академия урамы, 2

Редакция, гамәлгә куючы һәм басмаханәнең адресы:

420066, Казан, Декабристлар урамы, 2

E-mail: m-jomga@mail.ru

«Мәдәни җомга» газетасы Интернетта: www.madanizhomga.ru

Басмаханә гаебе белән җибәрелгән сыйфат җитешсезлекләре хакында 562-10-61 номерлы телефон буенча шылтыратырга

Газета һәр атнаның җомга көнендә чыга. Бу санның чыгу көне 30.09.2022

График буенча бу санга 15 сәгатьтә кул куелырга тиеш. Кул куелды – 14 сәгать 30 минутта.

«Татмедиа» АҖ филиалы – «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды

Газетаның сатудагы бәясе ирекле

Тираж – 2600 данә

Заказ 2772

16+